ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕНЕҢ
Г. ИБРАҺИМОВ исем.
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

**Ф. С. БАЯЗИТОВА**

# ХАЛЫК ТРАДИЦИЯЛӘРЕ ЛЕКСИКАСЫ: БИШЕК ТУЕ

(йола һәм фольклор текстлары яссылыгында)

Казан
2011

**УДК**
**ББК**
**Б34**

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
Гыйльми советы карары нигезендә басыла

**Фәнни редактор:**

филология фәннәре докторы, академик **М. З. Зәкиев**

**Рецензентлар:**

филология фәннәре докторы, проф. **И. Б. Бәширова,**
филология фәннәре докторы, проф. **Ф. Ш. Нуриева**

**Б34** **Баязитова Ф. С.** Халык тардицияләре лексикасы: бишек туе (йола һәм фольклор текстлары яссылыгында). – Казан, 2011. – 331 б.
ISBN

Бу китапта гаилә йолаларының бик үзенчәлекле бер тармагы булган бала туу йолалары лексикасы туплап бирелде. Материаллар Татарстанда һәм Рәсәйнең төрле төбәкләрендә диалектологик экспедицияләр вакытында җыйналды, тематик яктан системага салынды. Халык хәтерендә сакланып килгән тел, фольклор һәм этнографиягә караган мәгълүматлар этнолингвистика һәм культура белгечләре, студентлар һәм киң катлау укучылар өчен дә кызыклы һәм файдалы булыр дип уйлыйбыз.

**ISBN**

© Баязитова Ф.С., 2011

## Кереш

## БИШЕК ТУЕ ЛЕКСИКАСЫ — РУХИ БАЙЛЫГЫБЫЗ

Иң элек бу тел белән
Әнкәм бишектә көйләгән
Аннары төннәр буе
Әбкәм хикәят сөйләгән.
Г. Тукай «Туган тел».

Сүзебезне Г. Тукайның «Туган тел» җыры сүзләре белән башлап китүебез тикмәгә түгел. Татар халкы яшәгән барлык төбәкләрдә беләләр ул җырларны. Бала туу йолаларын сорашкан вакытта әбиләр һәм аналар иң алдап шул җырларны көйләп җырлап алалар.

Бала туу белән бәйле булган борынгы йолалар һәм аларга караган сүзләр буыннардан-буынга күчеп безнең көннәргә кадәр килеп җиткәннәр. Без аларны бик кадерле җәүһәрләр итеп санап, тел байлыгы белән бергә бөртекләп туплап барырга тырыштык.

Татар телендә бала туу белән бәйле булган йолаларның лексикасы фәнни әдәбиятта чагыштырмача азрак өйрәнелгән тема булып тора. Һәрхәлдә, махсус бу темага карата мәкаләләр һәм монографияләр язылмаган диярлек. Бу бик борынгы катламны күтәрү татар халкы яшәгән барлык төбәкләргә экспедицияләргә чыгып, бик күп авылларда булып, өлкән буын кешеләренең хәтерендә, телендә сакланган рухи байлыкны барлап, өйрәнеп чыгу юлы белән генә хәл ителергә мөмкин. Без моны беренче чиратта башкарылырга тиешле әһәмиятле мәсьәлә дип саныйбыз.

Шуңа күрә без, традицион культураны өйрәнүдә җирле сөйләшләрне төп таяныч итеп алырга булдык. Татарстанда гына түгел, көнбатышта Рязань өлкәсеннән алып, көнчыгышта Том, Кемерово өлкәләрендәге татар сөйләшләре, төньяктагы Нократтан алып көньяктагы Әстерхан, Волгоград өлкәсе сөйләшләреннән дә этнолингвистик материаллар туплап кайту насыйп булды.

Билгеле булганча, халык йолалары лекикасын йоладан аерып карап булмый. Өлкән буын кешеләренең хәтерендә, телендә әле борынгы йолаларыбыз турында бик күп истәлекләр саклана, кайберләре исә бүгенге көндә дә йола булып үтәлеп киләләр.

Бала тугач гаиләнең бәхетен, туганнарының шатлыгын уртаклашу бик борынгыдан килгән йола. Авылларда сакланып килгән җирле сөйләшләрдә бала тудыру үзе дә төрлечә аталып йөртелә. Мәсәлән, мишәр диалекты сөйләшләрендә — **бала түрәү,** Әстерхан, Пермь һәм Башкортстандагы татарлар сөйләшендә — **бала асрау** сүзләре дә кулланыла. **Бала биләү** — балалы булып гомер итү. «Балалар биләп, бәхетле гомер иттем», — дип сөйләшәләр.

Элекке вакытларда, беренче бала тугач, сөенче хәбәрне халыкка ирештерү өчен, берәр кешене авыл буйлап чыгарып җибәрә торган булганнар. Иң беренче сөенчене, гадәттә, каенанадан алганнар. Сөенче хәбәр белән килгән кешегә, борынгы йола буенча: «Бала йомырка кебек тәгәрәп үссен», — дип йомырка биргәннәр.

Бала тапкан хатын, ягъни бәби анасы, әлеге гаиләнең һәм күрше-күләннең иң кадерле кешесенә әйләнгән, аңа сый-хөрмәт күрсәткәннәр, аның урыны түрдә булган.

«Бала тапкан хатынның өенә кереп хәлен белә алмасаң, морҗасына кара. Төтен чыкканын күрсәң дә бик зур савап», — дигәннәр.

Әстерхан өлкәсе татарлары болай сөйлиләр:

— Бала асраган (тудырган) хатынны, баланың кырыгы тулганчы, аш-суга якын җибәрмиләр, авыр эшләр эшләтмиләр. Каберстанның авызы ачык торыр, ди; бала табу җиңел эш түгел шул, кырыгыннан чыкканчы казан-аяк астырырга ярамый.

Бала тапкан хатынга туган-тумача да, күрше-күлән дә «бәби ашы» илткән. Гадәттә, өйдә пешкән әлбә, чәкчәк, бавырсак, бәлеш, коймак кебек милли ризыклар матур савытларда кызыл

ашъяулыклар белән төреп китерелгән. Казан арты төбәкләрендә бәби ашына дип, борынгыча әлбә пешергәннәр.

— Әлбә пешереп алып килә хәл белә килгән кеше; май белән, шикәр белән тугылап, әлбә пешерәләр.

Мишәр диалекты сөйләшләрендә бәби ашына **чумар** пешерүне дә истәлек итеп сөйлиләр:

— Бездә бала тугач, чумар китерәләр. Чумарга катык, каймак каталар. Шул чумарны ашаталар балага сөт булсын, ана хәл алсын, дип.

Шулай ук **сөтләш** (ягъни сөттә пешкән ботка) тә бәби анасын зурлап пешерелә торган булган:

— Сөтләш китерәләр. Аның уртасына күз ясап, май салып алып киләләр. Китерелгән көенә, җылы көенә бәби анасына ашаталар.

Әстерхан өлкәсе татарлары бала тапкан хатынга **майбоper ламык** (майга он болгатып пешерелгән боламык) ашаталар:

— Биш бала таптым, бишәвенә дә боламык пешертте әни.

Билгеле булганча, элекке вакытларда хатыннар баланы өйдә, кендек әбиләр булышлыгы белән тудырганнар. Бала туу билгеләре, тулгак тоту (мишәр диалектында кисү алу, диләр) башлангач та кендек әбине алып килгәннәр. Кендек әбиләрне авылларда зурлап, олылап йөрткәннәр.

Атамалары да һәр якта үзенчә: **кендек әби, кендекәй, олан әбисе, бәбәй әбисе, түти әби, әби тәтә, әби әңкә, инәлек корткаяк, мамай, авыл әбисе** һ.б.

Себердә яшәүче татарлар болай дип әйтәләр:

— Балага авырып китсә, инәлек корткайакны алып киләләр. Инәлек — зур кеше, аны бик кадерлиләр. Инәлек өйгә килеп керсә, өйдәге аркалык (матча) иелеп китәр, диләр.

Кендек әби баланы һәм ананы караган, тәрбияләгән, мунча керткән. Ул өенә кайтып китәсе көнне «әби озату» дип атаганнар һәм аны күрше-күләнне чакырып, чәй мәҗлесе ясап, озатканнар.

Кендек әбинең вазифалары күп. Мәсәлән, ул баланы салават (изге, мактаулы догалар дигән сүз) әйтеп авызландыра.

Ата-ана йоласы,
Пәйгамбәрләр догасы.

Бәхетле бул,
Тәүфиклы бул, —

дип кабатлый-кабатлый, баланың авызына бал тидерә.

Халыкта шундый ышану да бар: «Кем авызландырса, бала шуңа охшап үсә», янәсе.

Кендек әбисе бәбинең кендеген кисә һәм җыеп куя. Әстерхан өлкәсе татарлары бу турыда болай дип сөйлиләр:

— Кендеген кисә, юындыра. Кендекне ак чүпрәккә бәйләп, бишекнең почмагына югарыга элеп куя: «Бала үскәндә өйдә булсын, каңгырып йөрмәсен, өйдән чыкмасын», янәсе.

Себер татарлары баланың кендеген әйбәтләп төреп, аркалыкка (ягъни матчага) кыстырып куялар. Яз көне, иген чәчкәндә, аны җиргә күмәләр:

«Ашымның (игенемнең) уңышын бир», — диләр. Кендек әбиләр бәбине дә, бәби тудырган хатынны да мунча кертәләр, ана белән баланы юындыралар.

— Иң алдан баланы юалар.

«Әйдәгез, бәбәй мунчасы», — дип, әбиләрне дә дәшәләр. Бәбәй мунчасын котлап, йомырка, сабын, коймак китерәләр.

Беренче мунчада бәбәйне юындырганда кендек әбиләре төрле ырым сүзләре әйтеп баланы чабындыралар. Менә Пермь өлкәсе татарларыннан язып алынган ырым такмаклары:

Аю баласын чабам,
Бүре баласын чабам.
Аю кебек симез бул,
Бүре кебек җитез бул,
Көндез уйна, кич йокла,
Бәхетле бул, тәүфиклы бул.
Әйшә-Батман (Гәйшә-Фатыйма) куллары —
Име-йомы шул булсын, —

дип, бәхет сорап чапканнар баланы.

«Олан чапкан яфракны өч юл аермага ыргытабыз», — диләр. Монысы — тау ягы (Апас районы) сөйләшеннән язып алынган ырым сүзләре:

Әби-бабай мунчасы
Җан тынычы бирсен,

Көн тынычы бирсен,
Яфрак кебек ярпайсын.
Коймак кебек кабарсын,
Борчак кебек тәгәрәп йөрсен,
Куян кебек сикереп йөрсен,
Каен кебек үссен.

Бала тугач, берникадәр вакыт үткәннән соң, туганнарын, дусларын, күршеләрен чакырып, бала котлап, зур мәҗлес үткәрәләр. Ул мәҗлесләр татар сөйләшләрендә түбәндәгечә атала.
**Бәби мае** — казан арты, мишәр диалекты сөйләшләрендә:

— Бәби маена җыялар. Бәби маена дип бүләк сала, аш, бәлеш, бал-май куялар. Бәби маена бардым әле, — дип сөйлиләр.

**Бәби туе, бәби боткасы** — тау ягы сөйләшендә:

— Аш-боткалар пешереп барганнар бәби боткасына, бәби туена. Түр башында олан әбисе утырган.

**Бәби чәе** — касыйм, сергач сөйләшләрендә:

— Күрше хатыннары бөтен бәлеш белән киләләр бәби чәенә.

«Бәлеш белән киләм, каршы да чыкмыйсыз», — диләр.

— Бәбәй чәенә ястык, мендәр китерә. Мендәр китерсә, почмагына көмеш тәңкә бәйли.

«Көмеш кебек ялтырап торсыннар».

Бәби туена килгән кунаклар бала котлап бүләкләр дә алып киләләр.

Себер диалектларында бала котлап бирелгән бүләкләрне **савын** дип әйтәләр:

— Бала котлокка савын алып барасың хәлеңнән килгәнче: күлмәкләр, юрган. Олы кызыбыз бәбәйләгәндә сыерыбыз бозаулаганые. «Бозау үсеп мал булса — кызыбызга», — дип ниятләдек.

Татар телендә бишек атамалары, бишек йолалары бик кызыклы.

«Тал бишек» дигән шигырендә Р. Миңнуллин болай дип яза:

Бездә бишек әллә ничек —
Талдан, җырдан үрелә.
Җырлы бишек, җылы бишек
Эленә өй түренә.

«Татар өендә бишек, гадәттә, түр башында тирбәлә, өй эчендәгеләрнең бөтен игътибары шул бишектә — якты өмет-хыяллар да, гасырлардан килгән җыр-моң да, елмаюлар да, күз яшьләре дә... Бишекле өйнең эче нурлы, бишекле өйдә җыр-моң өзелми. Бишекле өйнең киләчәге бар! Ә бишек янында — Ана! Шул моңнарның, җырларның чыганагы, бетмәс-төкәнмәс чишмәсе — ана күңелендә. Ана! Бала! Бишек! Менә шушы өч изге сүзгә җыр-моңның узганы, бүгенгесе һәм киләчәге сыеп беткән түгелме?!» (Миңнулин Р., 2004. — 399).

**Бишек бирнәсе** — нократ сөйләшендә: бала котлап китерелгән бүләкләр.

— Беренче бала тугач, кыз анасы, кызның дуслары бишек бирнәсе китерәләр. Бәбәйгә күлмәк, юрган, чыбылдык, көрпә, мендәр китерәләр.

**Бишек җыры** — халыкның рухи байлыгының иң якты чагылышы, шул ук вакытта ул һәр ананың үз баласы өчен генә көйләгән йөрәк җыры.

Сабый баланы йоклатканда бишек җырын әби дә, бабай да, әти-әни дә, апа-абыйлар да җырлыйлар. Ләкин ул җыр эчендә яшеренеп яткан тирән серләрне беләләр микән? Бишек җырына бала изрәп йоклап китә. Чөнки йөрәктән чыккан назлы моңда тылсымлы көч бар. Ул йоклату чарасы гына түгел, дога кебек, баланы шифалы аура белән урап ала, тынычландыра, күз тиюдән, тискәре дулкыннардан саклый, көй белән яңгыраган теләкләрнең баланың киләчәгендә гамәлгә ашуына ышаныч бар. Халыклар, үз тәҗрибәләренә, күзәтүләренә таянып, бишек җырының аерым ритмик шигъри төзелеш барлыкка китергәннәр.

Тирән мәгънә саклаган бишек җырларын хәзерге галимнәр дә өйрәнәләр. Төмән дәүләт университетының гуманитар эзләнүләр институты филология кафедрасының мөдире, филология фәннәре докторы Ирина Карабулатова бишек җырларын фәнни нигездә өйрәнеп, аларның бала организмы ритмнарын җайга салу сәләтен ачкан. Аның «Төмән өлкәсендә яшәүче төрки халыкларның бишек җырлары» («Колыбельные песни тюркских народов Тюменской области») дигән китапчыгы да дөньяга чыкты (Карабулатова, 2003, 23). «Бишек җыры, — ди ул, — фольклорның гади көнкүрешебез белән югары сәнгатьне тоташтыра торган уникаль жанры».

Сөекле шагыйребез Г. Тукайның «Бишек җыры» да бик күптән инде барлык төбәкләрдә татар халкының үзенеке булып, балага изгелек, яхшылык, гыйлемлек теләү булып сеңеп калган:

Әлли-бәлли итәр бу,
Мәдрәсәгә китәр бу.
Тырышып сабак укыгач,
Галим булып җитәр бу.

Әстерхан татарларында безгә бигрәк тә үзенчәлекле итеп үткәрелә торган бишек туйларын күрү насыйп булды. Кундрау авылында яшәүче Гыйләҗева Фатыйма апа сөйли:

— Бишек туена кыз анасы үзенең бөтен булган туган-токымын җыеп килә. Бәбәйгә кием алып киләләр, пылау пешерәләр, бүләк өләшәләр. Әстерхан сөйләшендә кендек әбисен «мамай» дип әйтәләр, баланы бишеккә салып, мамайдан такмак әйттерәләр. Ул баланың атасын, анасын, әбисен мактый. Ефәктән чыбылдык корып, такмак әйтәләр.

«Бәхетле бала туды, батыр булып үс, матур булып үс, атасы йохшы, анасы йохшы», — диләр.

Баланың бишегенә манит (тәңкә) салалар. Түрдә утырган хатын бишекнең тишегеннән кунакларга бавырсак өләшә.

— Бишек туенда тагын баланың өстенә якалы кием ябалар, җиде кешенең якалы җиде киемен ябалар.

«Яхшы булсын, ару булсын, яхшы кешеләрдән үрнәк алсын, сау булсын», — дип.

Бишек туенда халык таралыр алдыннан кендек әбисе баланы тирбәтеп көйләп куя:

Иөгерә-йегерә йөргәндә
Тәбәнәк курай кермәсен.
Кечкентәй генә кызыма
Халыкның күзе тимәсен.

Балага исем кушу да үзенчәлекле. Элегрәк заманнарда «бала исемсез торырга тиеш түгел», — дип, мулла чакырып исем куштырганчы, вакытлыча гына исем дә куеп торганнар. Ул **кендек** аты дип йөртелгән. Исем кушу йоласы һәр якта үзенчә атала: **ат атау, ат кушар туй, ат салу, исем** атау, исем **бирү, исем кушу, исем салу** һ. б.

**Пермь өлкәсенең** Куян авылында исем кушучы Хәсәнгали абзый сөйли.

— Кыйблага каршы ак мендәр, мендәр өстенә баланы куеп исем ататтым. Исем атаганда Аятелкөрси укыйм, колагына исемен әйтеп кычкырам. Йегерме тиен акча бирең, дип сорап алам. Көмеш тәңкә бирергә кушкан:

«Көмеш кебек нык булсын», — дип.

Табын күрке — бал-май була исем кушканда.

**Себер татарларында** исем кушу:

— Ат атагалы пешеренәсең. Мулла атый исем. Колагына өч тапкыр кычкыра, синең исемең шул, дип. Әти-әнисенең исемен дә колагына кычкыра. Кычкырмаса, бала үлеп китеп, теге дөньяда әти-әнисенең исемен белми, имеш.

**Әстерхан татарларында** исем кушу:

— Баланың битен ябып, мендәргә салып китерәләр. Кийездә баланың ата-анасы, мулла утыра, авыл картларын чакыралар. Мулла баланы алып, утырып азан әйтә, исемен атый. Исемен әйтеп, уң колагына да, сул колагына да кычкыра.

Исем кушу белән бәйле тылсымлы йолалар да күп. Мәсәлән, бала авырса яки аңа миң чыкса, икенче исем биреп караганнар. Ул йола **исем авыштыру, исем алмаштыру, исем бозу** дип атала.

**Лаеш районы Атабай авылында** менә мондый мисал язып алганбыз:

— Менә бала сырхау, күзен дә ача алмый. Тары боткасы пешердек тә, шуны мич алдына куйдык тәлинкә белән. Чормага менеп, морҗадан кашык төшердем.

«Исемен авыштырам, Миңнегөл булсын, саулыгын бирсен», — дип. Тары боткасын ишегалдына чыгарып кошларга салдым. Аны вакыт белән алмаштыралар, йә кар беткәнче, йә йаз җиткәнче, дип. Балада миң булса — Миңнәхмәт, Миңсылу исемнәре кушканнар.

**Ир баланы сөннәтләү.** Бу йоланы мишәр диалекты сөйләшләрендә пике (пәке) келәве дип әйтәләр. «Исем йолалары» дигән китапта: «ир балаларның җенес әгъзасын сөннәтләү Ибраһим галәйһиссәламнән үк калган». «Сөннәт — пакьлек һәм сафлык билгесе булганлыктан, мөселманнар өчен фарыз, әмма каттый мәҗбүри түгел», — дип язылган анда.

Әстерхан һәм Себер якларында, Урта Азия халыкларындагы кебек, бу йоланы күп итеп кунаклар чакырып, төрле уеннар, көрәш, ат чабышлары үткәреп, зурлап бәйрәм итәләр. Бу сөйләшләрдә аны **сөннәт туй, сөннәт хатеме** дип атыйлар.

— Сөннәт туйда көрәш, ат чабышы була. Сөннәт туйга өлкән үгез суеп, атлар суеп, итен турап кунакларга куялар. Сөннәт туйда баланы сөннәтләгәнче бер кабат яңа кием кигезеп, халык алдына чыгарып биетәләр, ике якның да кардәшләре акча ташлыйлар. Сөннәтләгәндә тәрәзәгә күрше балалар килә, алар тәрәзә кагып, тавыш чыгарып тора. Бала аларга карап, сөннәтләгәнне сизми дә кала.

Себер диалектларында сөннәткә утыртучы бабайны Аптал (гарәп теленнән кергән сүз) дип атыйлар. Аптал үзе белән барабанга охшаган, сугып тавыш чыгара торган әйбер йөрткән. Шуның белән баланың игътибарын әлеге уенчыкка юнәлткән.

— Бөтен авылны кунакка чакырып, Коръән укыткан, сөннәт хатеме дигән. Кадерләп йөрткәннәр Аптал бабайны, мендәргә утыртканнар. Кунакларны озаткач, малайны сөннәтләгәннәр.

**Баланың кырык көне** һәртөрле серле, тылсымлы йолалар белән үткәрелгән. Гомумән, кырыгы тулганчы баланы ялгыз калдырырга кушмаганнар (төрки халыкларда кырык саны тылсымлы сан булган).

«Кырыгы тулганчы баланы ялгыз калдырма, янына пычакмы, кайчымы куй, җен алыштырмасын, усаллар, шайтаннар тимәсен», — диләр.

Әстерхан сөйләшендә «кырыкламасын кою» турында түбәндәге мисалларны язып алганбыз:

— Кырыкламасын коя балаларына, кырык кашык су белән коендыра. Яңа аяктан коя суны кырыкламасына, кырык кат коя. «Кырыкламасын койган аяк яхшы аяк, үземә торсын, үзем үлгәндә ул аяк белән су коярсыз өстемә», — дип алып куя кырыкламасын койган аякны.

— Кырыкламасын кырык көннән соң коябыз, алдан юындырып алабыз, аннан сон кырык кашык су белән баланың башын чайкандыра.

Себер диалектларында «кырыклау» — баланың кырык көнен үткәрү.

— Кырыклавы булган, кырык тукац (вак күмәч) пешергән, кырык щабала (кашык) әзерләгән, һәрбер нәрсә кырыгар. Барлык туганнары килә, кырыкка тулсын кеше. Кырыклауга кеше саен берәр итеп тукац пешерә, кырык шабала су белән баланы коендыра:

«Озын гомер булсын, киң дәүләтле булсын» дип, кырыклауга бүләк белән баралар.

Баланың кырыгы тулганчы кигән күлмәген Әстерхан сөйләшендә, себер диалектларында «эт күлмәге» дип атыйлар. Кырыгы тулган көнне ул күлмәкне салдырып, эт муенына тагып җибәрәләр.

— Кырыкламасын коя, юындыра. Шул юындырганда салган күлмәген, түгәрәк калакай (вак күмәч) пешереп, уртасын тишеп, шуларны эт муенына бәйләп җибәрәләр. Баланың начар, эт акылы, яман холыклары китә, имеш.

— Кырыгы чыкканчы кигезгән күлмәкне «эт күлмәге» дип, этнең башына элгән. Аннан соңгы күлмәкне кечерәйгәнче кигезгән дә юып куйган. Тагын бала тапкач кигезгән.

Бишектәге бала — гаилә бәхете, өмете һәм киләчәге. Бәхетле гаиләдә — бала да бәхетле. Г. Тукай язганча:

> Бәхетле нарасидә! Тар бишек тә киң әле аңар!
> Ике ат бер тиен, диңгез тубыктан тиң әле аңар!

Гомумән, бала туугa бәйле йолалар лексикасы гаҗәп бай һәм кызыклы. Ул халык иҗаты белән, борынгы мәҗүсилек чорларыннан ук калган ырымлау, им-том сүзләре белән дә үрелеп барган. Шулай итеп, халыкның рухи һәм матди тормышындагы үзенчәлекләрне үзенә сеңдерә-сеңдерә безнең көннәргә кадәр килен җиткән. Алар гасырлар тирәнлегеннән килгән рухи байлыкның бер чагылышы булып саналырга, фәнни яктан тирәнтен өйрәнелергә лаек.

## АВЫРГА УЗГАН, ЙӨКЛЕ ХАТЫН

### Аwырлы, йөкле, көмәнле

**Аwырлы хатын** — балага узган, йөкле, көмәнле хатын.

**Көмәнле** — авырлы. **Җилдән көмәнле булу** — кияүгә бармыйча, ирсез бала тудыру.

Әдәби телдәге *авырлы, йөкле, көмәнле* сүзләреннән тыш, җирле сөйләшләрдә бу мәгънәдә түбәндәге лексик-фонетик вариантлар да кулланыла.

### Аwыр

**Аwыр** *клд.* йөкле, авырлы.

— Йеденчегә хатыны аwыр. Зәйнәп аwыр wақыты.

### Буй аwыр

**Буй аwыр** *эстр.* авырлы, йөкле.

— Мин *буй аwыр*, балам төшә, димен.

### Аwырайақ//аwырайак

**Аwырайак** < аwыр+айақ *себ.* авырлы, йөкле (хатын).

— *Аwырайақ кеше* қыйналаты[1] туwар wахыт[2] йитсә — *туб.*

— *Аwырайақ кешегә* кентекче әбине[3] чақыралар туwар wахыт йитсә — *бараба.*

**Аwырайак** *миш.д.* авырлы.

— Әллә, мәйтәм, *аwырайакка* кечи[4] микән айагым, бернәрсә дә тыймый, дим. Килен *аwырайак*, йылкый алмыйм казларны, ди — *мәл. Аwырайак* катынга үлек багарга[5] йарамый диләр вит — *срг.*

---

[1] қыйналаты — азаплана

[2] туwар wахыт — бала тудырырга вакыт

[3] кентекче әби — кендек әбисе

[4] кечи — кычыта

[5] үлек багарга — үлгән кешегә карарга

### Аwырайақлы

**Аwырайақлы** *к.-уф.* авырлы.

— Инәм *аwырайақлы* булған, үзе йаланға[1] эшкә киткән. Йаланда мине тыуған[2].

### Буйында булу

**Буйында булу** *себ.* авырлы, йөкле булу.

— Кейәү бер йыл кейәүләгән. Қыс, китәр wахыт йетсә, *буйында булған.*

### Эстендә булу

**Эстендә булу** *нокр.* авырлы булу.

— *Эстендә булып* қалды, йегетне әрмийәгә алдылар. Қайтқанны көтеп утыра эстендә булғанда.

### Әйләнәсе тулганда

**Әйләнәсе тулганда** *глз.* авырлы булу.

— Киленебезнеке *әйләнәсе тулганда*, аwыр эш эшләтмибез, өйдә генә кизүлей.

## АШ ТЕЛӘҮ, АШ САЙЛАУ, АШ ТАЛЫМЛАУ

Авырлы хатынның үзенчә теләгән ашы **себер диалект-ларында** *йәрек ашы, ирег ашы* дип атала. **Йәрек булу** — аш сайлау, аш теләү.

### Йәрек булу

**Йәрек булу** *себ.* авырлы вакытта аш сайлау, аш теләү.

— Мин аwырайақ цақта аң итенә[3] йәрек пултым. Аwырайақ пицә ымсынаты.

### Йәрек аш

**Йәрек аш** *себ.* авырлы хатынның үзенчә теләгән ашы.

---

[1] йаланға — басуга
[2] тыуған — тудырган
[3] аң ите — болан ите

— Балаға узған хатында була. Ашыйсы килгән әйбере — *йәрек ашы* дип әйтелә. Минең карт әнинең[1] йиләк ашыйсы килгән.

— *Йәрек аш* тиделәр. Палықмы-ниме ашағың килсә, аны ашамасаң паланың пер йире йитлекмәй тиделәр. Аны ашау кәрәк ашағың килгәнне. Ашамасаң палаң кимтек пулаты.

— *Йәрек аш* тиделәр. *Йәрек ашын* табып ашны ашат, ашат син аны, бала кимчелекле булмасын, ашағы келәгәц.

«Ни нәстәгә *йәрек пултың*? — тип *йәрек аш* алып килеп ашататылар».

«Баланың пер йире дә кимтек[2] булмасын, таса булсын», — тип ашататылар.

— *Ирег аш* тиделәр. Ат ите ашағым киләте. Шол wақытта теләгән ашны ашай алмағаннар. *Ирег ашын* ашый алмаса, сәғип пала пулаты — *тара*.

— *Йиреғ ашына* менә тың[3] ашағым килгән ийе үсепес салған икмәк түгел, бикәрнидә[4] салған қара икмәкне ашағым килгән ийе. Песнең Қортигән (ав. ис.) арада ул бикәрниләр йуқ. Суң қартым минеке чаңғы белән китеп күрше аwылдан алып килеп ашатты. Шул бикәрнидә бешкән икмәккә *йиреғ булған* итем.

— Аwырайақлы пицә ашағы келәгән әйберне ашамаса, баласы кәмчелекле булаты. *Йәрек ашын* ашағалы тейеш, тиләр.

— Тослы табан балық ашағысы киләте, ашамаса баласы кәм булаты, йәрек аш тиделәр қартинәмнәр, қартайғанца йәшәде.

**Аш сайлау** — мишәр диалектының *хвл., срг.* сөйләшләрендә:

— Ник болай *аш сайлыйсың*, әллә кырсакка уздыңмы? — *хвл.* — Аш сайлаганда өрәткәннәр тоссыз ашарга — *срг.*

— Дары сөтләше пешерәм *аш сайлаганда*. Ул бик файдалы була иде дары сөтләше — *срг.*

### Сары булу

**Сары булу** *тара*. нәрсәне дә булса бик нык ашасы килү.

— Мин үсем кәртүккә[5] *сары булып* йатқаммын аwырайақ чақта.

---

[1] қарт әни — әби
[2] кимтек — кимчелек
[3] тың — бик
[4] бикәрни [< рус. пекарня] — пекарня
[5] кәртүк [< рус. картошка] — бәрәңге

**Авырлы хатынга ашарга ярамый торган әйбер:**

**Әстерхан сөйләшендә:** буйаwыр, ягъни авырлы хатынга дөя ите ашарга ярамый дигән ышану язып алынды.

— Кинчәкләр[1] буй аwыр булғанда[2] төйәнең итен ашаса унике ай йөриләр икән. Төйә унике ай қорсағында бала үстерә икән. Ире белән бергә ашаса йарый.

**Себернең тубыл-иртыш диалектында:**

**Сорағай балық** *туб.* чуртан балыкның кечкенәсе, аны авырлы хатынга ашатмаганнар.

— Аwырайақ пицәгә бала асыраған wақытта сорағай балықны[3] ашатмай торғаннар ите.

— «Сорағай балық — қырық төрле аwыруыңны қусғай[4]», — тип әйткәннәр ите. Шаның өчен балық ашатмай торғаннар ите.

## БАЛА ТУДЫРУ

Бала тудырырга вакыт җиткәч, *тулгак тоту, бала тудыру* сүзләренең җирле сөйләшләрдә түбәндәге лексик вариантлары кулланыла.

### Кисү

**Кисү** *миш.д.* тулгак. **Кисү алу, кисү кисүләү, кисүләү** *миш.д.* тулгак тоту.

— *Кисү ала* катынны, *кисүлей.* Шул арада бал каптырасын, баланы тизерәк түрәләсен[5] дип. Бал *кисүне* кузгый[6] — *срг.*

— *Кисү кисүләп* йатканда әбине чакырып китерделәр, әби килде, бисмилла әтеп керде, кулын йуwып, миңа теләкләр теләде — *тмн.*

— *Кису кискәндә* баланы ылатли кедек әбиләр. Бала су эчендә була, аны ылатли. *Кису кискәндә* аwызына чәчләрен каптыра, ул укшысын, бала тиз тусын — *влгг.*

---

[1] кинчәк — киленчәк

[2] буй аwыр булғанда — авырлы булганда

[3] сорағай балық — чуртан балыкның кечкенәсе

[4] қусғай — кузгата

[5] түрәләсен — тудырсын

[6] кузгый — тизләтә

— *Кисү* ала башлый авырлы катынны, әби чакырасын, әби түрәтә[1]. Биле аwырта, әби ышкып тыра түрәгенче[2] — *кузн.*

## Тулғақлау, тулғақ тоту

**Тулғақлау, тулғақ тоту** *әд.* балага авыру.

— *Тулғақлап* йатам, үзем киттем тайаққа тайанып әби дәшәргә — *т.я.-трх.*

## Бала асырау

**Бала асырау** *әстр., бөре., байк., перм., минз., трбс., к.-уф., себ.* бала табу, тудыру.

— Қырқыннан чыққанчы *бала асыраған* хатын-қызны аш-суға җибәрмиләр, қәберстанның[3] аwызы ачық торор ди, бала табу җиңел эш түгел, үлем белән бер ди, қырқыннан чыққанчы қазан-айақ астырма[4] җарамый, ди — *әстр.*

— *Бала асыраған* қатыннар қәдерле була, җиде бала асырадым үзем дә — *бөре.*

— Туғыз бәбәй *асырады* қызым, берәүсе Төмәндә тора — *трбс.*

— Унике бала *асырадым* — *байк.*

— Ике баланы эштән қайтқач қына *асырадым* — *перм.*

— Әни бэш бала *асыраған*, төп йортта қалған — *нокр.*

— Бала *асыраған* қатын қырық кене цыққанцы ашқа қатышмаған, аwыр эш эшләмәгән. Қабер аузы ачық торор ти, сақланғалы тейеш — төм.

— Мин ун бала *асыраған*. Бала күп кирәк ғуй. Алтын ашық тайын[5] балалар күп кирәк ғуй.

«Қарғатай қарындашым йоқ,
Торнатай тыуғаным йоқ», —

тип утырғалы йасмасын аллам — *төм.*

— Қартнәм[6], инәмнең инәсе[7] унтүрт пала асыраған — *себ.*

[1] түрәтә — бәбәйләтә
[2] түрәгенче — бәбәйләгәнче
[3] қәберстан — кабер
[4] қазан-айақ астырма — аш-су әзерләргә
[5] алтын ашық тайын — алтын ашык кебек
[6] қартнәм — әби
[7] инәмнең инәсе — әниемнең әнисе

— Мин алты бала *асыраған*. Қурац[1] булса да, таwық булса да муллаға пирәтеләр бала асырағац. «Таубиқлы, бәғытле, ырисықлы булсын, дәүләтле булсын», — дип — *төм*.

— Дүрт бала *асырадык*, өч кыз, бер ол. Тормошталар кызларым — *хвл*.

**Бала асырау** *к.-уф.* бала тудыру.

— Үзем *бала асырый* алмадым мин.

— Ә мин игез *балалар асырадым*. Мин сирләгәнмен *бала асырарға*. Мин эштән қайттым, сирлим. Қәйнәне[2] қырға җибәрергә кәрәк.

«Шомырт пешкән. Шомыртқа бармыйңмы, инәй», — тим. Ә ул китмей, мине белә имеш сирләгәнне.

Мин аныған башқа[3] ғына *бала асыраға* итәм шул. Шуннан қыстады, қыстады, бала тыуды. Мин тышқа сығып киттем. Минем кендек әбей Хәтирә әбей әйтә, кер, йат, дийә. Алар белә имеш минең икәү бала[4] туwарны. Эшләп йатайым, тағын берәү килеп тыуды. Икәү булып киттеләр.

— Ә мин белеки қызымны қырық йәштә *асырадым* қый.

— Мин өсәүне ир балалар асырадым.

**Асырау, малай асырау** *төм.* тудыру.

— Қартым белән мөкцийә[5] йийғалы бартық. Мин аwырайақлы. Менә тулғақ киләте, малай туғалы wақыт йиткән. Тулғақ килеп китә дә бетеп китә.

— Мөкцийәгә барып урманта малай[6] асыратым. Қайтып китеп қартым ат алып килте. Башымдағы йаулыққа урап қуйынға тықтым малайны. Суңғылығым төшкәц кенә иремә дәшәм:

«Асыранып қуйтым, өстендәге йомошақ күлмәгеңне салып бир», — мин әйтәм.

«Асырантың ти», — тийә ирем. «Апамнан, йеснәмнән ат алып кил», — тим. Әкертен генә барып утырам, түмгәккә утырдым, ат килте. Айағымда өр-йаңа ойоқ. Ойоқ қунычы белән

[1] қурац — этәч
[2] қәйнә — кайнана
[3] аныған башқа — аннан башка
[4] икәү бала — ике бала
[5] мөкцийә — мүк җиләге (клюква)
[6] малай — бала

кентекне бәйләдем. Йышып-йышып кистем[1] кентекне. Малайға имчәкне қаптырдым, малай имте.

### Бала асыраған йир

**Бала асыраған йиргә ченнәр килә** *төм.*

— Баланы урлағалы *ченнәр киләте бала асыраған йергә*. Йаман ченнәр булған.

«Қороп қуй мылтығыңны, йен-сәхмәт килә», — тиде шаның баласын урлағалы. Йуғарыға қарап атып та йибәрде. Күремце булған ул қарт.

— *Пала асыраған йергә чен-сәхмәт килә* икән паланы урлағалы. Күремце қарт күрепте, мылтық атып йибәрепте. Урлатмаған баланы.

### Олан асырау

**Олан асырау** *нокр.* бала тудыру.

— *Оланнарны асыраган* мин дә, үстергән мин дә, рәхәтен күрмәгән мин алай. Йылаймин дә, йырлаймин дә.

### Улан асыраған бичә

**Улан асыраған бичә** *к.-уф.* бала тудырган хатын

*Улан асыраған бичәне* кендек әби мунча индерә[2], тәннәрен сылый. Хәзер терелеп китә.

### Асыранған бичә

**Асыранған бичә** *себ.* бала тудырган хатын.

— *Асыранған бичәнең* хәлен белгәле тийеш — *төм.*

### Бабай күрү

**Бабай күрү** *нокр., глз.* бала тудыру, балалы булу.

— Икегә дә барды, *бабай күрмәде*.

### Бала табу

**Бала табу** *әстр.* бала тудыру.

---

[1] йышып-йышып кистем — ышкып-ышкып кистем

[2] мунча индерә — мунча кертә

— Минем мимәм[1] җиде *бала тапкан*, дүрт кыз, өч ул тапкан минем анам, мимәм. Мин үзем дә җиде ул таптым.

## Бала туу

**Бала туу, бала тыwу** *себ., к.-уф., влгг.* бала тудыру.

— Минем инәм бер баланы урып йөргәндә ураг өстендә *туган* иде. Соло урып йатканда, соло урып килде дә, дүрт саwым сыйыр саwа торган. Инәм ашыгып, сыйыр саwып бетерде дә көнлекчеләр[2] кайтып килде ашарга, алар ашарга утырды. Бу йакта көнлекчеләр аш йийып[3] йатады, инәм *бала туwып* йатады теге йакта. Мин пешереп әзерләдем көнлекчеләргә — *бараба.*

— Мин биш бала тыудым, бишесен дә өйдә тыудым — *к.-уф.*

— Мин ике рәт игезәк *туган*[4] хатын, минем иске ойоғым имгә йарый — *төм.*

—Кендек әбисе килде, идә тудым. Өч кыз тудым, ике малай тудым мин. Кендекне кисәргә, бәләргә белгәннәр.

— Кан'анам идә булганда тудым мин. «Әни, туам мин», — дим. Кан'анам йаткызды да тудым да.

«Кулыма туды, бала кисәгем,
Кулыма туды», —

дип кинәнеп йөри кан'анам.

Тудык тудыкам белән бергә тудык баланы.

Туган хатынга салма ашаталар — *влгг.*

## Бала түрәү

**Бала түрәү** *миш.д.* бала тудыру. Чагыштыр: алтай телләрендә торол туган як, туган ил, монгол: *төрех* — туу, тудыру (Ринчинэ, 1947). Бу сүзнең төрле фонетик вариантлары бурят-монгол телендә дә бар.

— *Бала түрәгәннән* сун мунчага илтәләр катынны, йывындыралар, бәбәйне дә чабалар. Дүрт *бала түрәдем* үзем — *кузн.*

---

[1] мимәм — әнием

[2] көнлекче — бер көнгә эшкә килүче

[3] аш йийып — ашап

[4] игезәк туган хатын — игезәк бала тудырган хатын

— Кан'игәцем бала түрәгәндә:

«Аллам, мәдәт бир,
Аллам, мәдәт бир», —

дип теләп тордык — *тмн.*

— Әнием *түри игезәкләрне*, ыланнары[1] эч кен тырып үләләр. Ни айыбым[2] булды, әтә әнийем. Нишләгең кели, сабыр итәргә кирәк, хасерәтне кычаклап булми — *кузн.*

**Түрәләп бала китерү** *минз.* барлык йолаларны саклап, кадерле булып бала тудыру.

— *Түрәләп* сигеd бала китердем, сигеdе дә исән-сау.

**Түри тырган катын** *хвл.* бала тудыручы хатын.

— *Түри тырган катынның* билен ыва кендек әби.

## Бәбәйләү, бәбәй китерү

**Бәбәйләү, бәбәй китерү** — әдәби телдә һәм урта диалектта:

— Кендек әбисен чақырдық, әwәле бәбәйләргә булса — *каз.ар.-блт.*

## Малайлау, малай китерү

**Малайлау, малай китерү** *т.я.-трх.* бәбәйләү, бәбәй китерү.

— Әби булучы йөридерийе малайлаған киленнәргә.

— *Малайлаған* хатыннарны мунча йағып йуwындыра кендек әбиләр. Мин унны *малайладым.*

## Малайлау

**Малайлау** *төм.* бәбәйләү.

— Малайлый башласа кендек инәгә барганнар ат йигеп. Кендек инә булышаты йөсләгән пицәгә малай таптырган кендек инәм.

## Қусы йару, күсе йару

**Қусы йару, күсе йару** *себ.* бәбәйләү, бәбәй китерү.

— Оллы қысым *қусы йарғацын* йақшы әтийәл[3] апардық, сыйырыбыс посаулаған ыйы, ул посауны ырыслатық[4] — *төм.*

---

[1] ыланнар — балалар

[2] айыб — гаеп

[3] әтийәл [рус. одеяло] — одеял

[4] ырыслатық — атадык

— *Күсе йарғалы* аwырсаң инәлек[1] цақыратылар. Пала тыуса инәлек йыwып, тасартып салаты паланы — *тевр*.

— Қортқайақлар пулған *күсе йарғанта*, кентек инәләр[2]. Йуғарыға қатақ қағып, мыш пау[3] бәйләп, пауға асылынып табалар ый. Қайсы шарып бәйлите.

### Нәнәй, нәнәйләү

**Нәнәй** *к.-уф.* бәбәй.

**Нәнәй китерү** *к.-уф.* бәбәйләү.

— Ә мин *нәнәй китерә* алмадым, йалғызмын.

**Нәнәйләү** *к.-уф.* бала тудыру.

— Бер хатын *нәнәйләргә* булған, ире әбей[4] китергән. Бер бала *нәнәйләгән* бу, ике бала *нәнәйләгән*. Өченчесе белеки генә бала тыуған. Ире әйтә дей, әбей утны сүндер, алар ут йақтыға чығалар, дип әйтә дей.

— Қызыу ураг өстөндә инәм аш бешереп торған. Менә ул *нәнәйләгән*. Эшкә әйтергә быригадир кергән икә, гөлбичкә[5] қачқан инәм.

«Беләм, беләм иркәкәйем, *нәнәйләп* йатқаныңны да беләм. Алай да қырда аш пешерегә барыға кәрәк», — дигән.

Минем инәйем шунан чыққан гөлбичтән. Инәйем иртәнгә әпәй бешергән, тоқмач кисеп аш бешергән, бөтөн нимәсен китереп биргәннәр инәйемә.

— Инәйем ике бидерәгә[6] салып, көйәнтәләп ашны күтәргән, кутумкаға[7] әпәйләрне салған, мине алйапқысына менә шулай итеп салған. Мин бик кечкенә тыуғанмын, шуңа да үсә алмағанмындыр. Киткән бу қырға. Көн дә йөргәнмен шулай алйапқыста. Қыр исен иснәп үскәнмен.

### Нәнәйләгән хатын

**Нәнәйләгән хатын** *к.-уф.* бала тудырган хатын.

— Ул *нәнәйләгән* кешене бик шәп қарадылар.

---

[1] инәлек — кендек әбисе
[2] кентек инә — кендек әбисе
[3] мыш пау — таза, юан бау
[4] әбей — кендек әби
[5] гөлбич — мич арасы
[6] бидерә — чиләк
[7] кутумка [рус. котомка] — котомка

«*Нәнәйләгән кешенекен* төтөне сыққанны қараса да саwабы зур», — диләр.

Элек бигерәк инде қоймағын да пешереп, сыwын ташып, шулай қарадылар.

— Элек *нәнәйләгән* хатынға шәңгәсен пешереп, йылы аш кертеп бирә торғаннар ыйы. Қоймақ пешереп, йылы қоймақ белән сәй эсең әле, дип кертәләр ийе. Мунса кертәләр ийе нәнәйләгән хатынны.

Сәйне гел сөтләп, қаймақлап эсерделәр.

— Дусым әйтә, чирләбрәк торам, дигән була. *Нәнәйләргә* wахыты йиткән. «Килийемме?» — тим. «Йуғ әле, тей, арта wахыт йиткәч, эндәшермен әле», — тей. Шул wахыт йеткән қый. Сыу қуйған бу йылытырға қазанға, баланы йуындырыға. Эндәште бу. Тыуды бала. Күршем Кәтей дә килеп йетте. Үзем кисәрем кендеген тейән була. Йуқ, йуқ, мин әйтәм, үзем кисәм, үземә әйтте, тейән булам[1].

Нәнәйләгән кешене урынға салалар инде. Нәнәйләгән кешене дә, уланны да қырық көнгә хәтле кендек әбей йыwа инде.

### Нәнәйләтү

**Нәнәйләтү** *к.-уф.* бәбәйләтү.

— Элеке кендек инәйләр күпне белделәр алар, алар ғына *нәнәйләтте* аwылда.

### Туған хатын

**Туған хатын** *төм.* бала тудырган хатын.

— Туған хатын пачутта[2], бер эш тә эшләмәгән. Туған хатынға әркем китерә қоймақ, пәрәмәч, қайнар аш. Саwабы бик зур була.

### Уландан қотылу

**Уландан қотылу** *к.-уф.* бала тудыру, баладан котылу.

— *Уландан қотылған* дигәннәр нәнәйләгән қатынны.

Қәйнәм бик қәдерләде *уландан қотылғас*. Қәйнәм килеп қоймағын да пешереп қәдерләде. «Аша, аша, ашай торған

[1] тейән булам — дигән булам

[2] пачутта [рус. почет+та] — кадер-хөрмәттә

сир[1]», — дийеп. Тороп йөрегә итәм, қәйнәм иремә ошақлый[2], йөретмә, өзлегә қый, тей. Тынығып[3] қына йатырға сийа тей.

### Җиңеләйү, йиңеләйү

**Җиңеләйү** *к.-уф.* бала тудыру.

— Мин бал'нискә барып җиңеләймәдем, гел әбиләр булды. Мунча индерәләр[4] әбиләр.

### Йиңеләйтү

**Йиңеләйтү** *тара.* Бала тудыру, баладан котылу.

— Йиңеләйгән пицәгә майшырцай[5] эцертәләр, инәлекләр аны беләтеләр. Йаңа бешкән майны қайнатып, он сибеп бешергәннәр. Пирбуй аны аны эцергәннәр, йиңеләйгән пицәгә. «Палаға сөт килер», — дигәннәр.

### Бала биләү

**Бала биләү, ул-кыз биләү** *миш.д.* балалы булу, балалар белән гомер итү.

— Олы быратым[6] *ул-кыз биләсен*[7], кече быратым[8] кыз да күрмәсен (җырдан) — *кузн.*

— *Балалар биләп* тора, қәзер сиксәннән артып килә торған қарт булды — *т.кам-крш.*

## БАЛА, БӘБИ, БӘБӘЙ, ОЛАН, УЛАН

Әдәби телдәге *бала, бәби, бәбәй* сүзләре белән беррәттән, түбәндәге лексик вариантлар да еш кулланыла.

---

[1] сир — чир
[2] ошақлый — әләкли
[3] тынығып — тынычлап
[4] мунча ндерәләр — мунча кертәләр
[5] майшырцай — майлы, онлы шулпа
[6] олы бырат — олы абый, олы ир туган
[7] ул-кыз биләү — уллы-кызлы булу
[8] кече бырат — кече ир туган, эне

## Бала

**Бала** *эстр.* ир бала.

— *Бала* дүртәү, қыз җуқ миндә.

## Бәбәй

**Бәбәй** *каз. ар., минз.* бәби, бала.

— *Бәбәй* туғач, бәбәйнең иң беренче айағын ғына күрсәткәннәр атасына, йөden кхрсәтмәгәннәр бәбәйнең. Йаңа туған бала матур булмый, кемгә ошағанын да белеп булмый — *минз.*

## Олан

**Олан** *миш.д., т.я., каз.ар., минз., перм., нокр., глз.* бала.

— *Оланнары* бер дә тормай дип утынлыққа салма қушқаннар бәбәйне — *глз.*

— *Оланны* йаратқалады қарты — *нокр.*

— Элке *оланны* кертеп йуwалар бәбәй мунчасы дип — *кузн.*

## Олан сақчы

**Олан сақчы, бәбәй сақчы** *нокр.* бала караучы.

— Эч оланнар иде, *олан сақчы* асырадым. Козомның олан сақчысы йуқ — *нокр.*

## Улан

**Улан** *себ., к.-уф., перм.* бала.

— Қатын-қыз *улан* китергән wақытта йөреп тораты албасты — *себ.*

— *Уланны* қырық көнгә хәтле кендек әби йыwа иде — *к.-уф.*

## Улан абай

**Улан абай** *перм.* аналык.

— *Улан абай* урнықмаса, бик шәп аwырта эч улан тапқач.

## Бабай

**Бабай** *нокр., глз.* бәбәй, бәби.

— Бишектә *бабай* йылай, эшик тептә песәй қычқыра.

## Малай

**Малай** *т.я., себ.-төм.* бәби, бала.

— Дүрт *малай* асырадым, икесе қыз *малай* булды.

## Пәпә

**Пәпә** *туб.* бала.

— *Пәпә* туған пицәгә[1] аwыр эш эшләтмәгәннәр.

— *Пәпә* туса пер нимә ошлап[2] керәтеләр, қоры қул кермиләр.

**Араместек пәпә** *туб.* ирсез, кияүгә бармыйча туган бала.

— Араместек пәпәне асыратым, пәпәм үсеп утыраты.

## ЙӨЗЛЕК БЕЛӘН ТУҒАН БАЛА

**Йөзлек белән туған бала** *минз.*;

**Йөзлек белән туган баланың йөзлеген җыеп кую:**

*Йөзлек белән туған баланың* йөзлеген дә киптереп китап арасына салып қуйғаннар.

«*Йөзлек белән туған бала* бәхетле була», — диләр. Йөзлекне алып урлаучылар буладырыййы кеше күзенә мәхәббәтле күренер өченгә.

— *Йөзлек белән туған балалар* була. Ул йөзлекне йуwып, киптереп, бөти йасап баланың бишегенә элеп қуйалар. «Бала озын ғомерле, бәхетле булсын», — дип.

Ул йөзлекне өшкерергә урлаучылар да була икән, әфентөфенгә, сихергә дә урлый икән қайсы кеше — *минз*.

**Йөзлекле бала** *төм.:*

— Йөзлекле бала туwа, бәхетле була диләр андый баланы.

— Минем өч бала да йөзлекле булып туды. Аны йөзлекне киптереп сақлыйлар.

**Мәхәббәткә кирәк** ди ул. Қыз белән җегеткә қаwышырға сәбәп итә ди — *каз.ар.-лш.*

## Күләк белән туған бала

**Күләк белән туған бала** *эстр.* йөзлек белән туган бала.

— Күләк мән туды балам. Шул күләкне җуып, киптереп, сандыққа салып қуйадылар. Атасы аwырлық күрмәй дип әйтәделәр.

---

[1] пәпә туған пицә — бала тудырган хатын

[2] пер нимә ошлап — бер нәрсә тотып

## Бөркәнчекле бала

**Бөркәнчекле бала** *каз.ар.-лш.* йөзлек белән туган бала.

— Қайсы *бала бөркәнчекле* булып туа. Аны кендек әбиләр үзләренә алалар икән. Им-томға йарый ди, мәхәббәт китерә ди ул.

## Пәрдәле бала

**Пәрдәле бала** *эстр.* йөзлек белән туган бала.

— Қайсы *бала пәрдәле* булып туады. *Пәрдәле* булып *туған бала* бәхетле булып чығады. Белгән кеше пәрдәсен ала, шул пәрдәнең бер кисәген киптереп қуйа. Йегет әрмийәгә киткәндә шуны төреп кесәсенә сала. Исән-сау қайта.

## Әҗемекле бала

**Әҗемекле бала** *к.-уф.* йөзлек белән туган бала.

— Бәхетле бала булыр, *әҗемекле бала,* әҗемеге бар, диләр.

## Цулбанлы бала, чулбанлы бала

**Цулбанлы бала, чулбанлы бала** *төм.* йөзлек белән туган бала.

— Қайсыбер бала пәрдәле булып туwаты, *чулбанлы* тип тә әйтәтләр. Ул тотыш булаты, пәрдә шикелле. Мин үсем тә *чулбанлы* туған. Оллы йастық тайы[1] булған. Аны бала тапмаған қатыннарға қайнатып эцергәннәр. Аны сорап алмағаннар, урлап киткәннәр. Минекен цәңгелцәк баштан[2] урлап киткәннәр.

Арғалықлар[3] йекле[4] була тоған. Арғалық йегенә[5] қыстырып қуйғаннар. Бер бала тапмаған қатын сорап кергән, инәм бирмәгән. Киптереп, таса цүперәккә урап, йеккә қыстырғаннар.

**Ақ цулбан белән туған бала** *төм.*:

— Пер *балам ақ цулбан белән туған.* Минең қәйнәм аны қоротты, йәйеп қуйтық аны пес. Аны пес ыспайлап[6], ақ түберәккә урап қуйтық, йуғалтмадық.

---

[1] йастық тайы — мендәр хәтле
[2] цәңгелцәк баш — бишек башы
[3] арғалық — матча
[4] йекле — ярыклы
[5] арғалық йеге — матча ярыгы
[6] ыспайлап — әйбәтләп

**Цомбат ман туған бала** *тара.* йөзлек белән туган бала.

— Цомбат тип әйтәтеләр, пала *цомбат ман* туwаты, тоташ пәрдә шикелле, тың булаты. Цомбатны ташламаған, қоротып қуйған.

### КЕЧКЕНӘ БАЛА, БЕР ГЕНӘ БАЛА

#### Т'ит'ик бала

**Титик бала** *нокр.* имчәк баласы.

— *Титик бала* нәкәс[1] йылақ булғалады. Йеде айға чақлы йылады. Тенне унике сәттә айға чығардым. «Ай қайта, кен қайта», — дип әйтеп.

#### Пер күс бала, бергенәкәй бала

**Пер күс бала** *төм., туб.* бер генә бала.

— *Пер күс балам* өйтә — *туб.*

— *Пер генә күс малайым* (балам) бар — *төм.*

**Бергенәкәй бала** *әстр.* бердәнбер бала.

— *Бергенәкәй баланы* үстереп, чатыр қорып, туй узғырып кийәүгә бирдем.

#### Үлем саркыт бала

**Үлем саркыт бала** *миш.д.* бердәнбер бала.

**Сарқыт** сүзе себер диалектларында һәм әстерхан сөйләшендә хөрмәтле, олы кешеләр утырган табында калган ашамлыкны белдерә. Аны тылсымлы, серле көчкә ия дип, балаларга ашатырга тырышканнар, янәсе, картлар кебек акыллы булсын, озын гомерле булсын.

— Мин бер кыз әнинең *улем саркыт* кына, теләп алганнар мине.

#### Сабый

**Сабый** — кечкенә бала.

**Сабый** — гарәп теленнән кергән сүз: кечкенә ир бала.

**Сабыя** — *гар. сабый* сүзенең күплек саны.

И, *сабыйлар*, эшләгез сез,
Иң мөкатдәс нәрсә эш! (Г. Тукай)

[1] нәкәс — бик

### Нарасита

**Нарасита** *себ.* нәни бала.

— Кецкенә *нараситаны* «пы нарасита очмақ қошы» тип сөйгәннәр — *төм.*

— Менә қысцығацларны йуwындырып сәңгелцәккә йатқысған идем. «Йоқлап йаталар *нараситалар*», — тиде бер кеше кереп. Йарамайты игесәкләрне қарағалы, алар әле бер айлық қына, тимен. Берсе шул қараған көнне йан бирде, күздән үлделәр — *туб.*

**Нараситалай** *себ.-төм.* сабый көенчә.

— Берәүнең баласы тормый, *нараситалай* үлеп китә.

## ЯҢА ТУГАН БАЛА ТАВЫШ БИРМӘГӘНДӘ КУЛЛАНЫЛА ТОРГАН ЫРЫМНАР

Дөньяга яңа гына туган бала кычкырып елап җибәрергә, тавыш бирергә тиеш. Әгәр бала тавыш бирмәсә, түбәндәгечә итеп, төрле әйберләргә сугып, тавыш чыгарып им иткәннәр.

### Таба қағалар

**Таба қағалар** *каз.ар.:*

— «Тиз генә таба китерегез, қалақ китерегез», — диләр. *Шаңғыртатып суғалар табаға.* Бала қычқырып җылап җибәрә — *каз.ар.-блт.*

### Тасайақ суғалар

**Тасайақ суғалар** *себ.-туб.* табак сугалар.

— «Бала таwыш бирми, *тасайақ суғың*», — тиделәр. Тасайақ суғатоғаннар шаңғыртатып. Таwыш биреп қуйаты бала.

### Цүмец тыңғыртата

**Цүмец тыңғыртата** *туб.* чүмеч кагалар.

— Таwыш бирмәде бу балам. Қортқайақ[1] айақтан ошлап[2] тотаты баштүбән, артына суғаты. Перәwе *цүмецне*

---

[1] қортқайақ — карчык

[2] ошлап — учлап

*тыңғыртататы* төмбер-төмбер. Ул бала қычқырып сықтап йибәрде[1], терелеп китте.

### Мөрҗәне ачалар

**Мөрҗәне ачалар** *к.-уф.* морҗаны ачалар.

— Қайсы бала таwыш бирми, үле тыwа. Кендек әбей мөрҗәне ачарға қуша: Баланың таwышы керсен, дип. Мөрҗәне ачып қычқырып қарый қый исемен әйтеп.

«Исенә керт, исенә керт», — дип қычқыра.

## БАЛА ТУГАЧ СӨЕНЧЕ АЛУ

Бала тугач сөенечле хәбәр әйтеп кешене шатландыру, хәбәрне әйткән өчен бүләк бирү йолалары түбәндәге лексик-фонетик варианттагы сүзләр белән белдереләләр.

### Сөйөнче, сөйөнце

**Сөйөнце** *төм.*— сөенче.

— Алдағы палаға *сөйөнцегә* йеритегән

«Күсе йарты[2], палалы пулты», —

тип кергән сөйөнцегә. Әбәмнең[3] минең белән пер йәшлек қысы, икәүпес йөргән аwыл буйлап. Берәр тәңкә ақца биргән.

### Сөйөнче қабу

**Сөйөнче қабу** *нокр.* сөенче алу.

— *Сөйөнче қабарға* килгән бабай туғач.

— Киленнең әйләнәсе тулғанда[4]. *Сөйөнче қабарға* үзем барам дип тора Фатыйма абыстай.

### Севенче, сүwенце

**Севенче алу** *хвл.*, **сүwенце алу** *срг.* сөенче алу.

---

[1] сықтап йибәрде — елап җибәрде

[2] күсе йарты — бала туды

[3] әбәмнең — апамның

[4] әйләнәсе тулғанда — авырлы, корсаклы булган

— Кендек әби зәрә алдыннан[1] бездән *севенче алырга* килде — *хвл.*

— Бала тугач кан' әнидән *сүвенце алалар.* Кыз әнисеннән дә алалар, малай әнисеннән дә алалар. Йомырка бирәләр *сүвенцегә — срг.*

### Севенче әтү

**Севенче әтү** *тмн.* сөенче әйтү.

— Беренче баласы тугач кан'анасы авыл буйлата *севенче әтә* йөри, анарга хайыр бирәләр, йымырка. «Бала йомырка кебек каталасын[2]», — дип.

## БАЛА ТУГАЧ СӘДАКА БИРҮ

### Сәдәқә, сәтәқә

**Арыслан сәтәқәсе** *төм.* баланың исәнлеге өчен дип бирелә торган сәдака.

— Умбиш тин көмөшне *арыслан сәтәқәсе* тип, башыннан әйләндереп бер әбигә бирә. Шул умбиш тин көмеш бирелсә, *арыслан* да һөжүм қыла алмыйты, кеше тә тийә алмыйты. Үтерәм тип килгән пыцақ та төшеп китәр ти.

### Кентек сәтәқәсе

**Кентек сәтәқәсе** *себ.* бала тугач икмәкләтә бирелә торган хәер.

— *Кентек сәтәқәсенә* ипи пирәте. Эце аwырулы булмыйты.

### Төн сәдәкәсе

**Төн сәдәкәсе** *мәл.* бала яхшы йокласын өчен бирелә торган сәдака.

— Бала йыласа, йокламаса, кичкырын төн сәдәкәсе кертәләр, йәшми-тынмый бирәләр дә чыгып китәләр.

---

[1] зәрә алдыннан — таң алдыннан
[2] каталасын — тәгәрәсен

## БӘБӘЙ ТУДЫРГАН ХАТЫННЫҢ ХӘЛЕН БЕЛҮ

— Бәбәй туған өйгә, бәбәй тудырған анаға кереп хәлен белергә бер дә wақытың булмаса, әғузе-бисмилла әйтеп, өй почмағына қарап булса да китәргә қушқаннар.

— Бер дә кереп күрә алмасаң, өй почмағына айағыңны тигезеп булса да китәргә қушқаннар бәбәй туған өйгә — *минз.*

### Асыранған хатынның хәлен белгәле

**Асыранған қатынның хәлен белгәле керү** *себ.:*

— *Асыранған қатынның хәлен белгәле* кергәле булмаса, өй түбәсенә морҗасына қарағалы бойорған. Ул да саwап, имеш. Гүрше-ғара[1] *хәл белгәле* керсә, потқа йә қоймақ пешереп, аш ошлап[2] керә.

— Қырық кенгә чике бала туған кешенең *хәлен белгәле* керәләр. Қырық кенгә чике[3] бала туған қатын йиргә йалан айақ басмасын, мунчаға керсә дә айағына чүпрәк урап йөрсен.

— *Хәл белгәле* керсә қоймақ қойоп, саwытны баланың кентеге төшкәнче апчықмаған, соңыннан кереп алған.

— Күсе йарған бицәләрне[4] тәрбийә қылабыс. Қырық көнгәцә гүр аузы ачық тораты.

**Бәбәй тапкан хатынның хәлен белү** *чст.:*

— Элгәре әтәләр иде, «кырык кенгә хатле гүр аузы ачык тырыр» дип *бәбәй тапкан кешегә*. Кырык кенгә хатле үлем белән тартышыр *ди бәбәй тапкан кеше*.

Бала әтер ди мин туам, ананың йаны әтер ди мин цыгам дип.

*Бәбәй тапкан хатынның хален белсәң*, изгеләрдән саналасың ди.

**Бала тудырган хатынны кадерләү** *эстр.:*

— Қырқыннан чыққанчы бәбәй туған хатын-қызны аш-суға да җибәртмиләр. Қаберстанның аwызы ачық торор ди. Бала табу җиңел эш түгел, үлем белән бер ди. Қырқыннан чыққанчы қазан-айақ астырма җарамайды.

---

[1] гүрше-ғара — күрше-күлән
[2] аш ошлап — ашамлык тотып
[3] чике — хәтле
[4] күсе йарған бицә — бала тудырган хатын

Қырық көнгә тийен[1] қабер ишеге ачық булыр диде, анасы киләме, баласымы. Қырық көнгә тийен бала тапқан қатынны урамға чығармаға йарамый диде, җәннәт ишеге ачық тора диде, ике дөнйа уртасында тора икән анасы да, баласы да.

## ХӘЛ БЕЛЕРГӘ КЕРГӘН КЕШЕЛӘРГӘ ҖЕП ӨЛӘШҮ

### Қорсақ йеп, қотлоқ йеп

**Қорсақ йеп, қотлоқ йеп** *туб.* бала тудырган хатынның хәлен белергә кергән күршеләренә, туганнарына өләшү өчен дип алдан ук әзерләп куелган җепләр.

— Йетеннән йеп йереп[2] аны төрле буйауларға буйайтылар. Пала тапқан сун[3] кеше кергән сайын перәр йеп биреп қуйатылар ите, *«қорсақ йеп»* тип әйтептеләр.

«Әйдә, кереп цығайық әле *қорсақ йеп* алғалы», — тип әйтептеләр.

— *Қорсақ йепне* мин үсем тә өләшеп йөргән, инәм әсерләп қуйаты. Йетен йеп ите әwәле.

— *Қотлоқ йеп* тигәннәр, аны өләшеп қуйалар. Менә күсе йараты. Кем керсә дә шул буйаған йепне биреп цығара торғаннар иде. Аңа масайышып[4] цыға торғаннар иде. Үсе йергән йеп, аны өләшкән. Ул бүләк булған, қортқайақлар аңа масайғаннар. Қара цай, бер самаwыр цай эцә тоғаннар иде. Қайа китә икән бу қортқайақларның цайлары, бишәр-алтышар йоморо[5] цай эцәтеләр, иш-тусларын[6] цағырып цай эцәтеләр.

— *Қорсақ йебен* урцық[7] белән йерлиләр. Йерләп аны төрле сырға[8] маналар. Төреп алалар да сескә тә өләшә, пескә тә өләшә бала туған сун.

«Осон ғомерле булсын,
Ырцықлы, бәғытле бала булсын», — тип.

---

[1] қырық көнгә тийен — кырык көнгә кадәр
[2] йеп йереп — җеп эрләп
[3] пала тапқан сун — бала тапканнан соң
[4] масайышып — шатланып, мактанышып
[5] йоморо — чынаяк
[6] иш-тус — дус-иш
[7] урцық — орчык
[8] сыр — буяу

### Қорсақ йепне ишек тотқасына бәйләү

— Пирвайғы кешегә *қорсақ йепне* ишекнеке тотқасына бәйләп қуйғаннар. Аны шишеп ачқан кешегә пүләк бирә тегәннәр, йаулық ошлата[1] тығаннар, ақца бирәтегәннәр. Перенце баланықы қорсақ йебе, сырлап қуйатылар. Ағы, сарысы, қысылы. Икешәр йепне пергә төйәтегәннәр[2] ите. Йеп алғалы киләтләр, йүргәклек[3], ашамлық ошлап киләтеләр.

Шал *қорсақ йебе* белән йаманасың[4], йыртылған йиреңне тегәсең. Элек йеп қәтерле булған.

Ишекнеке тотқасына бәйләп қуйатылар йепне. Йергән йеп[5] нықлы булаты.

### Пәпә йеп

**Пәпә йеп** *туб.* бала тугач өләшү өчен әзерләнгән җеп.

— Инәлек қортқайақ[6]:

«Бу пәпәнең ғөмере осон булсын», — тип *пәпә йебе* биреп утырған. Энә белән йепне. Өй ийәсе алған алдан әсерләп қуйған сабақлы йеп белән энәне. Бу қортқайаққа көмеш ақца салғаннар.

— *Ақ йепне* таратып йийатылар. Ат ататқалы[7], хәл белгәле кергән кешеләргә бирәтеләр *«пәпә йеп»* тип.

— Йеп бирәтеләр пәпә туса. Йепне йереп алатғаннар ите урцық белән. Аны буйайтылар төрле сырға, аннан аны ыспайлап төйәтеләр. Ул йепне пәпә тапқан бицәнең[8] баш астына қыстыратылар. Ул кем керсә дә йепне алып өләшеп утыраты. Ул йеп қәтерле булған, йуқ булған ул йеп.

«Осон гомерле булсын», — тип өләшкән.

Йетеннән йеп булған, аны йергән, сыйратқан[9] аны энәнең күсенә сыйғылық[10] итеп.

---

[1] йаулық ошлата — яулык тоттыра
[2] төйәтегәннәр — төенлиләр
[3] йүргәклек — бала төрү өчен чүпрәк
[4] йамана — ямау ямый
[5] йергән йеп — эрләгән җеп
[6] инәлек қортқайақ — кендек әбисе
[7] ат ататқалы — исем кушарга
[8] пәпә тапқан бицә — бала тудырган хатын
[9] сыйратқан — чыйраткан
[10] сыйғылық — сыярлык

«*Пәпә йебе* алғалы керәйек» тип йөгерешеп йөрителәр балалар, масайып цығатылар. Оста гешеләр алай йеп йергән. Тик биреп утыратылар ите *пәпә йепне.*

— Менә күсе йартым[1], мулинә йепләрдән икешәр-өчәр күс[2] өләшеп чықты инәлек нәнәм[3]. Кергән пала-пақраларға[4] да өләшеп бирәтеләр:

«Менә сиңә, қысым, *пәпә йеп*».

### Нәнә йеп, нәнә қотлоқ

**Нәнә йеп** *төм.* бала тугач өләшү өчен әзерләп куелган җеп.

**Нәнә қотлоқ** *төм.* бала туу белән котлау.

— Йетеннән йергән дә аны күккә, қысылға буйап, кәләпләп, кәләпне кисеп, дүрт-биш йепне буйап қуйатылар.

*Нәнә қотлоққа* кергән кешеләргә биреп цығарып утыратылар.

«*Нәнә йебем* бетте инде, ақца ғына пирәйен».

«Мин ақца белән нишләйен, йеп кәрәк миңа», — тип әйтәтеләр.

Йеп кәрәк булған тегенгәле. Шантай төнйалар булған.

«Мә, *нәнә йеп* сиңа. Нәнәм минең йақшы булсын, тыңлаулы булсын, ақыллы палацық булсын. Менә синең шикелле минең дә балам тыңлаулы булсын. Шалай тип телә».

Инте масайып цығып китәтеләр «*нәнә йеп* алтық» тип. Тегенәләр ул йеп белән — *туб.*

— Лүннән йергән йепләр пулаты. Балацықлар керсә, аларға йеп биреп цығарғаннар. Төрле йепләрне: қысыл, ақ, қара, йәшел йепләрне сабақлап қуйатылар та оцона бер **энәне асып қуйатылар:**

«Тошман сүсләреннән, тел-тештән сақлағалы», — тип **энә асып йеп бирәтеләр** — *тара.*

— Әwәле йескә генә йеп булған йетеннән йергән. Инәкиләр үсләре йергәннәр. Шуны малай қотлоққа кергән кешеләргә биреп цығарғаннар *«нәнә йеп»* дип.

---

[1] күсе йартым — бала тудырдым

[2] икешәр-өчәр күс — икешәр-бөртек

[3] инәлек нәнәм — кендек әбием

[4] пала-пақра — бала-чага

### Йеп сатақа

**Йеп сатақа** *төм.* бала тугач өләшү өчен әзерләнгән җеп.

— Йете йепне айаққа тубыққа үлцәп кәләпләйсең. Аны кисәсең дә *сатақаға* өләшәсең.

«Осон ғумер бирә».

— Йеп биргән әwәле, иц ақца бирмәгән хәл белгәле кергән гешегә. Оста йеренәләр ите әwәле. Йетеннән нечкә генә йереп, йепне төрле сырларға сырлап әсерләп қуйалар ите аwырайақлы пицәләр.

Хәл белгәле кергән кешеләргә шал йепләрне өләшәләр ите.

*Йеп сатақағаца* гәпләштек әле менә.

— Бала қотлоққа кергән кешегә йеп бирсәң, ул ултырып теләк теләйте, уғыйды исәнлеккә-саулыққа осон өмергә.

Ниндәй булса да йеп бирәтеләр.

«Йеп осон өмер бирә» тип әйтәтеләр. Йеп биреп чығарабыс, пәйшәмбе, йома көннәрендә бирәбес.

— Йеп бирәтегән итек пала қотлоққа керсәләр. Осон кәләпле йеп бирәтегән ителәр:

«Өмере осон булсын», — тип.

Йергән йеп, йескә генә йергән йеп булған. Пыйас қабығына қайнатып шаңа буйаған.

## БАЛА ТУДЫРГАН ХАТЫНГА АШАТА ТОРГАН АШАМЛЫКЛАР

### Әлбә

**Әлбә** — казан арты сөйләшләрендә: хәл белергә килгән кешеләр әлбә пешереп алып килгәннәр.

**Әлбә** *каз.ар.-дөб.* май, шикәр комы, он белән болгатып пешерелгән боламык.

— *Әлбә* пешереп алып килә хәл белә килгән кеше, писүк белән, май белән туғылап *әлбә* пешерә.

### Сетләш

**Сетләш** *срг.* тары, дөге һ. б. ярмадан сөткә пешерелә торган ботка.

— Кас'ы *сетләш* китерә. Күз салып ук китерә сирлылар (күз салу — ботканың уртасына чокыр ясап май салу).

— *Сетләш* китерәләр, чашкы эсте[1] белән май куйалар, күз ясап салмыйлар. Китерелгән күwенә киленгә каптыралар.

## Цумар, чумара

**Цумар** *срг.*, **чумар, чумара** *миш. д., баст.* чумар.

— Бездә бала тугац китерәләр *цумар*. *Цумарны* катык белән, каймак белән каталар. Шул *цумарны* ашаталар балага сөт булсын хал' алсын дип — *срг.*

— Бала тугач хатын-кызга *чумар* ашаталар. *Чумарны* катыкка салып, шуны болгап ашаталар. Күршеләр тужы *чумар* китерә — *баст.*

— *Чумара* пешерәләр, катыкка салып ашаталар бала тапкан хатынга. Күршеләре дә *чумара* китерә — *баст.*

## Бәбәй кимагы

**Бәбәй кимагы** *чст.* бәбәй тапкан хатынга күршеләре яки туганнары пешереп алып килә торган коймак.

— Элгәре бәбәй кимагы пешереп килү ийе бәбәй туган кешегә, кимаг алып килеш ийе. Киленгә *бәбәй кимагы — цеце кимак*[2] пешергәннәр инде. Аннан сың бәбәйнең хален белергә килгән кешегә цәй эцергәннәр.

## Нәнә аш

**Нәнә аш** *төм.* бала тудырган хатынның хәлен белергә килгәндә «нәнә аш» дип ашамлыклар алып кергәннәр.

— Бер кеше малай асыраса, аңа ашағалы алып керәсең *нәнә аш* дип. Табаққа салып бутқамы, ашмы, қоймақмы алып керәсең.

**Нәнә аш табағы** *төм.* бала тудырган хатынга ашамлыклар салып бирелгән табак. Ул табакны баланың кырыгы тулгач кына хуҗасына кайтарып бирәләр.

---

[1] чашкы [рус. чашка] эсте — чынаяк

[2] цеце кимак — төче коймак

— *Нәнә аш* дип *табақны* алып керәсең бала туған пичәгә. Ул *табақта* қоймақ йә бутқа инде. Ул *табақны* баланың қырығы тулғанчы сақлайдылар, биреп чығармайдылар. Аннары ғына биреп чығарадылар ул *табақны*.

## Қоймақ

**Қоймақ қойып әпкерү** *төм., туб.* коймак пешереп алып керү.

— Күсе йарғацын[1] *қоймақ* қойоп әпкерәтегән. Ул *қоймақны* әрғайсы ашайтығын.

«Пескә тә йылышсын[2]», — тип.

Туған-қәрдәшләр[3] бөтенесе ашайтығын.

## Шәңкә

**Шәңкә** *төм., тара* шәңгә, бәрәңге пәрәмәче.

— Күрше-ғаралар[4] *шәңкә* салып, қоймақ қойып апкерәте бала асыранған бичәгә[5] — *төм.*

— Туған-тоғомнары, күрешеләре *шәңкәләр* мән киләтеләр йиңеләйгән пицәнең хәлен пелгәле — *тара.*

## Майболамық

**Майболамық ашату** *эстр.* бала тудырган хатынга боламык пешереп ашату.

— *Майболамық* пешереп ашата бала туғанда. Майға су қойа, болғап пешереп ашата. Биш бала таптым, бишәwенә дә *майболамық* пешертте әни.

## Онаш

**Онаш < он+аш** *төм.* токмачлы аш.

— Йыwық туғаннары[6] *онаш* салып, қатық қатып ашататылар.

---

[1] күсе йарғацын — бала тудыргач

[2] пескә тә йылышсын — безгә дә насыйп булсын

[3] туған-қәрдәш — туган-тумача

[4] күрше-ғара — күрше-кара

[5] бала асыранған бичә — бала тудырган хатын

[6] йыwық-туғаннары — якын туганнары

## Эссе тамак̧

**Эссе тамак̧ бирү** *эстр.* кайнар аш, кайнар чәй бирү.

— Бала туғаннан сун *эссе тамак̧* бирәделәр. Ул инде ике сагат, өч сагат к̧ыйналған кеше[1] булады. Ару итеп[2] сөтле чайын эчсен, ашатып тирләтеп йатк̧ызаты.

— Баладан бушанған[3] кимпергә[4] к̧уй суйады, к̧уйның шулпасын эчерәде, *эссе тамак̧* дип.

## Исү шулпа

**Исү шулпа** *том.* эссе шулпа.

— Элеке *исү шулпа* ашатк̧аннар бала туған хатынға. Алты малай булған мамамнык̧ы[5], бер к̧ыз булған. Ул к̧ызны умбиш йәшендә йәрәшеп алғаннар, элек йәрәшү булған.

## Шырцай, майшырцай

**Шырцай** *төм.* май белән онны кыздырып, аңа су кушып кайнатып ясалган аш-шулпа.

— *Шырцай* эцерәтләр йаңа туған к̧атынға. Борынғыда *шырцай* пешерәтләр. Май белән онны к̧уырып алғаннан суң, су к̧ойоп к̧айнатып аласың. Сары май да йарай, к̧уй май да йарай, бешем май[6] да йарай. Йаңа туған к̧атынға порон[7] эчергәннәр. Онно көйдереп шулпа к̧ойоп эцергәле.

— Беренце урынға йату ман *шырцай* эцерәтләр йеңеләйгән к̧атынға[8]. Майны ғайнатып он туғыйтылар, ул шырцай әйтеләте.

**Майшырцай** *тара.* май белән онны кыздырып, аңа су кушып кайнатылган аш-шулпа.

— *Майшырцай* ашатк̧аннар йиңеләйгән пицәгә. Майны к̧ысдырған, аңа сыу к̧ойғаннар, тос, онаш салғаннар. Алай шулба

---

[1] к̧ыйналған кеше — азапланган кеше
[2] ару итеп — яхшы, әйбәт итеп
[3] баладан бушанған — баладан котылган
[4] кимпер — хатын
[5] мама — әби
[6] бешем май — ак май
[7] порон — элек, борынгы заманда
[8] йиңеләйгән к̧атын — бала тудырган хатын

қылып йиңеләйгән пицәгә эцергәннәр. *Майшырцай* тип эцәтеләр йиңеләйгән пицәләр.

### Чәй, қуй майы

**Қара чәй, қуй майы** *әстр.* бала тудырган хатынга эчертәләр.

— Сөтнең өстен генә қатқан *қара чәй* эчерәделәр бала тудырған хатынға, *қуй майы* эчерәделәр. Сөт күп ул wақытта.

### Чәй, шулпа

**Чәй, шулпа** *минз.* бала тудырган хатынга эчертәләр.

— Бала туғач, ана кешегә тәмле итеп *чәй, шулпа* бирәләр.

«Сөт булсын», — дип. Бала имчәк имә бит.

### Айран

**Айран** *том.* әйрән

— *Айранны* қайнатып, айран эчерә тоған бала туған қатынға.

### Пуча

**Пуча** *бараба* май язганнан калган әйрәнне кайнатып ясалган эчемлек, буза.

— Бала туған пичәгә[1] *пуча* дип қайнатып эчерәделәр. Майны пешеп алған әйрәннән қайнатып йасайлар ул *пучаны*. Бала тушып йатқан пичәгә ул *пучаны* ашатқалы кәрәк. Ә майнықы, сызғырған сары май ашаттылар пичәгә.

### Күже

**Күже** *әстр.* ярма салып, итсез пешерелгән аш.

### Тары күже, төй күже

**Тары, төй күжесе** *әстр.* тары ярмасы салып пешерелгән итсез аш.

— Тары, қабақ турап салаты. Төй[2] диде тарыны. Суға қайнатады. Сыйыры бар кеше сөт қойоп пешерәде. Қабақны

[1] бала туған пичә — бала тудырган хатын

[2] төй — тары

арчып, турап саламыз, сары төй саламыз бер тустаķ[1]. *Күже* димез боронғыча, сары *төй күже* булады бик тәмне.

## Ķомаршыķ күже

**Ķомаршыķ күже** *эстр.* кырда, далада үскән кыргый икмәк орлыгыннан пешерелгән аш.

— *Ķомаршыķ күже* дә булды. Ķырда аны җыйнайдылар. Алаша[2] дип җептән туķыған җабуға[3] җәйеп *ķомаршыķны* суғадылар ағач мынан, ул ķойолады. Укроп симечкәседәй булады *ķомаршыķ*. Ул инде беренче аш. Аны ķул тирмәндә[4] төйәделәр. Аны ķуwырадылар ķазанда, сөткә болғап, чәйгә болғап ашайдылар. Ķул тирмәнгә ķойоп айландырып кал'акай[5] пешерәде, *ķомаршыķ* кал'акай дип.

*Ķомаршыķ күже* ул инде бик тәмле тамаķ[6] булды. Аны буй аwыр киленчәккә[7] дә, бала туған киленчәккә[8] дә ашатадылар боронғылар.

## Ашымал, ашымал күже

**Ашымал, ашымал күжесе, жугырт** пешкән дөге белән әйрәннән ясалган ашамлык, бала тудырган хатынга эчерткәннәр.

— *Ашымал* йасағанда көрөсне[9] пешерәмез, өстенә сөт ķойамыз.

Суытамыз да чиләккә ķойоп ķуйамыз. Ул ачый, өстенә үтпик[10] салып ķуйамыз, өстенә тағын бер айаķтай сөт ķойамыз. *Ашымал күжесе* булады ачы айрандай. Әwәлдә шул айранды *жугырт* дип әйтәделәр, ķарағым[11].

Күжене көрөстән сөт салып, кәртүк турап пешерәде, ит булмады.

---

[1] тустаķ — чынаяк
[2] алаша — алача
[3] җабу — җәймә
[4] ķул тирмән — кул тегермәне
[5] кал'акай — күмәч
[6] тәмле тамаķ — тәмле ашамлык
[7] буй аwыр киленчәк — авырлы килен
[8] бала туған киленчәк — бала тудырган килен
[9] көрөс — дөге
[10] үтпик — икмәк
[11] ķарағым — иркәләп әйтү сүзе

## КЕНДЕК ӘБИЛӘР

**Кендек** — кеше яки хайван яралгысын ана организмы белән тоташтыра һәм яралгыны тукландыру каналы булып хезмәт итә торган көпшә.

**Кендек әбисе** — бала тудыру вакытында ярдәм күрсәтүче, бала кабул итүче карчык.

— Кендек әбие булмаган Минем туган чагымда. Ә. Ерикәй. Кендек әбиләр гасырлар буена изге эш эшләгәннәр — йөкле хатыннарга булышлык күрсәтә килгәннәр. Н. Фәттах.

Бала туганда ярдәм итүче кендек әбиләрнең әдәби телдә һәм җирле сөйләшләрдә түбәндәге атамалары бар.

### Әби

**Әби** сүзе туганлык термины буларак кына түгел, бала туганда ярдәм итүче, кендек әби буларак та кулланыла.

[Бәдри], кап-караңгы төндә урам этләрен өрдереп барып, әбине [кендек әбисен] уятты. М. Гафури. — Болай булмый, барып килергә кирәк, дидем дә Нәфига әбигә [кендек әбисенә] йөгердем. М. Әмир. **Әби булу** — бала тудыручыга ярдәм итү. [Хатын], сагызланган үтмәс урак алып, Үзе «әби» булды үзенә. Ф. Кәрим.

### Әби

**Әби** *урт. д., миш. д.* бала тудырганда ярдәм итүче, кендек әби.

— Бала түрәтүче бер *әби* була, *әбине* бала түрәтергә йәшәләр, *әби* килә инде бала түрәтергә — *кузн.*

— *Әби* түрәтә баланы, чыкканда тирәзәдән бага, бала кәркеш ишеп утыра. Эстәл айагына бәләгән, сыгылып кәркеш[1] ишә *(экияттән)* — *кузн.*

— Улан туғанда *әбине* чақыралар, әбигә күлмәк алып бирәләр — *перм.*

— Бала туғач кендеген кискән *әби*. *Әбиләр* белгән әwәле бала тудыру эшләрен.

---

[1] кәркеш — чабата киндерәсе

— Өч тапқыр мунчаға алып кергән, бөтен тәнен сылаған. Баланы җуwадырайы мунчаға алып кереп — *т.кам.-крш.*

## Әби булучы

**Әби булучы** *т.я.-нрл., т.я.-к.т.* кендек әбисе.

— *Әби булучы* бар ыйы аwылда. Ул йөридерийе малайлаған (бәбәйләгән) киленнәргә. *Әби булучы* ул тулғақны да белгән, булышқан.

— *Әби булучы* диләр ий. Кем әби булған, кем кендеген кискән, диләр ийе. Шул әби булучы қарчық бала туғач кендеген кисә дә баланы қойондырырға килеп йөри — *т.я.-к.т.*

— *Әби булучы* Саҗидә әбийем мунчаны бик җаратқан. Бәби мунчасына керә икән. Икенче кеше килеп чақырса мунчаға:

«Хәзер, хәзер, бер генә чабынып төшәм дә барам» дип ул кешегә дә барып мунча керә икән.

— *Әби булучы* билне уwып:

> «Хәйерле сәғәттә, раббым,
> җиңгеллекләр бир шушы бәндәгә»

дип теләп торған инде. Ул *әби булучы* кемгә бақа чыққан, кемгә бүре уwы булған, им-томны да белгән, өшкергән дә — *т.я.-к.т.*

**Аwыл әбийе** *каз. ар.-дөб.* кендек әби

— *Аwыл әбийе* йуғ инде хәзер, бул'нискә[1] баралар қатыннар.

## Бала түрәтүче әби

**Әби, бала түрәтүче әби** *миш.д.* бала тудырганда ярдәм итүче, кендек әби.

— *Бала түрәтүче* бер *әби* була, элек бит бал'ничалар[2] булмаган, *әбине* бала түрәтергә йәшәләр. *Әби* килә инде бала түрәтергә.

Бер бабай була, ул әтә: «Кызым, син чыккач тирәзәдән бак, ни күрерсең». *Әби* килә *түрәтеп*, бабай сыри: «Ни, бактыңмы тирәзәдән?» «Бактым, ди, бит бабакай бик интирисни хал', минем йаңы *түрәткән бала* ләгәнгә утырган да чыпырдап-

[1] бул'нис [рус. больница] — больница
[2] бал'нича [рус. больница] — больница

чыпырдап йывына». Йари йывына бирсен, балам». Тагы икенче кенне чакыралар мыны *бала түрәтергә*. Икенчесе *түри*. Бабай әйтә: «Балам, тирәзәдән бак, ни күресең». *Әби түрәтә* дә тирәзәдән бага. Йаңы *түрәгән бала* акча сани, йезәрлек тә меңәрлек. «Бабай, бу нинди хикмәт?» Эченче кенне йәнә йәшәләр әбине: «Ад'а инде, *катным түри*[1]». Бабай инде әтә, тирәзәдән багарга ынытма. *Әби түрәтә*, чыкканда тирәзәдән бага, бала кәркеш ишә, креват айагына бәләп, сыгылып-сыгылып кәркеш ишә. «Ник сун ул ыланнар былай эшлиләр?» Бабай әтә, берсе суда йезүче, диңгездә йезүче булыр, су белән кен күрер, икенчесе мал кувар, малдар[2] булыр, бай булыр, эченчесе йул йерүче, ил гизүче булыр, мосафирлыкта йерер, әткән бабай (әкияттән, Кикино ав.).

## Бәбәй әбисе

**Бәбәй әбисе** *чст.* кендек әби.

— Бик күп кешегә *бәбәй әбисе* булган үземнең әни. Атаулы[3] бәбәй әбисе булган.

«Кызым, ди, йә, килендәшем», — ди, «бәбәйләмисеңме әле», — ди. Кулы да йиңел булган. Ул килеп сыйпаса да йиңел була, диләр ийе. Әле дә «син бит минем кендек әбийем», — дип садака биреп китәләр. Бырачка бик баргы keләмәгәннәр ул wакытта.

Зәйтүнә астай[4] килде миңа *бәбәй әбисе* булып. «Бәбәйең борылган бит», — дийә. «Йуктыр», — дийәм. Бәбәйне монда тудым. Үктәбер айы, кырпаклар тешкән ийе.

— Намаз укыганда, йасин укыганда *бәбәй әбийенә* атап дога кылалар, хайер биргәндә дә искә алалар. Эцәр-дүртәр мунца керткән сипап-сипап. Кимак белән цәй булган *бәбәй әбисенә*.

**Бәбәй әбисе** *чпр.* кендек әби.

— *Бәбәй әбисе* була үдә ылан тапса, аwылда бер-ике генә кеше *иде бәбәй әбисе*.

---

[1] катным түри — хатыным бәбәйли

[2] малдар — байлык йаратучы

[3] атаулы — атаклы

[4] астай — абыстай, апа

— *Бәбәй әбисе* булган ул, ул булышкан бәбәй тудырырга. Элек бырачка бару булмаган.

**Бәбәй әбисе** *срг.* кендек әби.

— *Бәбәй әбисе* шылай ылан таптырып йери булган, эрәнгән инде ул. Кас'ы куш күлмәклек[1] бирә, кас'ы берне.

— *Бәбәй әбисе* кендеген кисә, цәпе[2] белән бәли, баланы йывындыра, ананы йывындыра мунцада

### Инәкә әби

**Инәкә әби** *эстр.* кендек әби.

— *Инәкә әби* булды аwылда, электә мамайлар арасында белгән кешеләр булған, алар йөргән бала туwайак җирдә[3].

### Инәлек әби

**Инәлек әби** *себ.* кендек әби.

— Бала туған сун *инәлек әбине* көйләк[4] биреп қәтерлиләр. Оста қортқайақ була.

### Олан әбисе

**Олан әбисе** *т.я.-крш.* кендек әби.

— *Олан әбисен* йәшеп китерә, олан әбисе баланы җуа. Түр башында утырталар *олан әбисен.*

### Түти әби

**Түти әби** *кас.* кендек әби.

— *Түти әбине* ча'кыра, ул 'арай була түри' инде.

### Әби тәтә

**Әби тәтә** *т.я.-трх.* кендек әби.

— *Әби тәтә* дип җөрттеләр минем әнине, башқаwылға җөрттеләр. Әби тәтә бәбине қулына алған, җуындырған.

---

[1] куш күлмәклек — парлы, ике күлмәклек
[2] цәпе — чүпрәк
[3] бала туwайақ җир — бала туа торган җир
[4] көйләк — күлмәк

## Әби зату

**Әби зату** *каз.ар.-лш.* кендек әбисен озату хөрмәтенә оештырылган чәй мәҗлесе.

— *Әби затабыз* дип оло кешеләрне чақырып, аш-су хәзерләп, қунақ итеп заталар.Әби китә инде аннары өч мунча керткәч.

## Әбилек

**Әбилек** *том.* кендек әби.

— Бәбәйли башласа аwырлы хатын, *әбилек* инде чәчләрен сүтә, ишекләрен ачып қуйа. Бикле булмасын. Изүләрен чишә, булафкыларын, сәғәт, йөзекләрен салдыра.

— Шул *әбилеккә* теләкләр теләп йатам, хәйер бирәм, көйнәк[1] алып бирәм.

**Әбилек** *каз.ар.-блт.* кендек әбисе.

— *Әбилекне* алып килделәр. Әбилек килеп кергәндә тулғақлап йатадырыйым.

— Ситдиқа тәтә *әбилек* булды. Ишектән кергәндә қычқырып сөйләп килеп керде:

«Менә, Миңлебикә, урамнан барадырыйым, Шәйхетдин абзый бер ат йөге печән алып қайтып килә. Сезнең турыға килеп җиткәч, бер ат печән йөге урталай йарылды да китте», — ди. Мин аңа шаққатып ышанып қарап торам. Ә ул мине тизрәк бәбәйләсен дип әйтә имеш.

## Кендек әби

**Кендек әби** *к.-уф.*:

— *Кендек әбиләр* нәнәйләргә[2] wахыт йиткәнен белеп торалар. Минең *кендек әбийем* булды. Ул әйтә торған ыйы, аwыр табасың, дип. Мине *кендек әбийем* нәнәйләтте.

**Кендек әби** *хвл.*, *влгг.:*

— *Кендек әбиләр* килә. *Кендек әби* күп сүләп тормый, үз эшен белә, түри тырган катынның[3] билен ыва — *хвл.*

---

[1] көйнәк — күлмәк

[2] нәнәйләргә — бәбәйләргә

[3] түри тырган катын — бәбәйли торган хатын

— *Кендек әби* зәрә алдыннан[1] бездән севенче[2] алырга килде — *хвл.*

— *Кендек әбине* чакырдылар мин бәбәй туганда. Үлгенчек шыл Ләтифә әби кендек әбисе булды, үмердән-үмер ул булды. Өшкерә дә иде.

«Үзе бәләгән тевенне
Ходай тәлә үзе тишсен,
Ходайга аманат,
Аллага тәвәккәл»

дип йаткызды да тудым да оланны. Минем кыругымны йалт иттереп иштырып алды *кендек әби* — *влгг.*

**Кендек әбийе** *бараба.*:

— *Кендек әбийе* хақлы. Пирбуй хәйерне анарға бирергә кирәк.

### Кендек әбисе, кендек әби

**Кендек әбисе** *минз.* ананы да, баланы да мунча кертә.

— *Кендек әбисе* бик дәрәҗәле кеше булған. Минем *кендек әбийем* Хәдичә әби. Мин аны хәзер дә доғадан қалдырмыйм. Қайда бала туа, барып кендеген кисә. Биш көнгә қадәр қарап, мунча кертеп, әниләрен дә, баланы да җуындырып йөргәннәр *кендек әбиләре*. Алар өшкерүне дә белгәннәр. *Кендек әбисе* бөтен тәнне сылый-сылый мунча кертә торғаныйы, менә шуның белән тереләдерийе.

— *Кендек әбисе* белгәнен уқып керә өйгә.

Бала табарға чирли башладым. Кендек әбисе килде. Қартлар, бийатай-бийанайлар чығып киттеләр өйдән.

«Көчән, бәпкәйем», — диде. Көчәнергә дә хәл йуқ. Матчаға бер бау тақты.

«Менә шуны көчәнеп тарт», — диде. Шуны тартқач, көчәнкелек килеп баланы таптым.

«Бәбәй тапқан хатынның қырық тамыры өзелер», — дигәннәр.

[1] зәрә алды — таң алды
[2] севенче — сөенче

*Кендек әби* бөтен җирен сылый. Бармақ очоннан башлап, буыннардан башлап, бөтен тәнен сылар ыйы. Бер атна муча йағып кертер ийе, бөтен җиреме сабын белән сылар ыйы, эчеме сылар ыйы.

«Җөрмә, қыdым, җатып қына тор», — дип.

Шулай қарайлар кендек әбиләр.

— Кендек әби баланы сөйә-сөйә ала инде қулына:

> «Тигезлек белән қарап үстерегез,
> Бәхетле, тәүфиқле, изге сабый булсын» —

дип әйтәләр кендек әбиләр.

— Элгәре бала табучы күб ийе, һәркемнең үзенә *кендек әбисе* айырым ыйы ул. *Кендег әбисе* сыпырғалый, теге итә, бу итә. *Кендек әбисенә* йақшы кешмир йаулық бирәләр, камзул бирәләр қызыл бәрхеттән — *минз*.

**Кендек әбисен «җеннәр алып китә»** *минз.:*

— Кендек әби җөздән артық бала таптырса, кендек әбине җеннәр алып китә үdләренә бәбәй таптырырға дип әйтә торғаннар ыйы.

«Қуркам, бармыйм», — дидерийем.

## Кендек абасы

**Кендек абасы** *эстр.* кендек әби.

— *Кендек абасын* белергә тийеш бала үскәндә.

> «Чарылдап җиргә төшкәндә,
> Кендегеңне кискәндә», — диде.

Өйдә туwа да, *кендеген кисә* дә, йуwындыра *кендек абасы*.

## Кендек атасы, кендек чичи

**Кендек атасы, кендек чичи, кендек чичәсе** *эстр.* исем кушканда билгеләп куелган кешеләр, кендек ата, кендек әни.

— Ат қушарда[1] кендек ата, кендек чичи дип йөри. Үзенең йақын қардәшен қуйа, туған-тохомыннан[2]. Ул йақшы бүләк алып киләде балаға.

---

[1] ат қушар — балага исем кушу мәҗлесе
[2] туған-тохом — нәсел-нәсәп, туган-токым

### Кендек инә

**Кендек инә** *к.-уф.:*

— Минем баламныкъы *кендек инәсе* килдейе.

### Кентек инә

**Кентек инә** *бараба.:*

— *Кентек инәм* тип әйтәмен.

### Кендек мамам

**Кендек мамам** *әстр.* кендек әби.

— Кендек мамам баланы көн дә килеп йуwындырды, қырық көнгә хәтле йуwындырды.

### Кендек балам, кендек қызым

**Кендек балам, кендек қызым, кендек малайым** *к.-уф.:*

— *Кендек әби* үзе әбилек булған балаларны шулай атап йөртә.

— Қайсыбер *кендек әбиләр* бигерәк йақын күрәләр балаларны. *Кендек балам* дип, *кендек қызым, кендек малайым* дип әйтәләр.

— *Кендек малайларым* күп минең.

### Кендегәц, кендегәч

**Кендегәц, кендегәч** *том.* кендек әби.

— Мин малайымны өйдә тыудым, аугус айында. Әбилек килде, *кендегәц* инде.

— *Кендегәцләр* кендеген кисәйләр, урап салайлар. Әбилек булған. *Кендегәч* чақырып керткәннәр. Ул йөри тегән без күргәндә.

— Олу қызыма Мөслимә мамай *кендегәч* булды, ә икенчесенә Гөлзәминә мамай *кендегәч* булды.

### Кендегәч қарчық

**Кендегәч қарчық** *том.* кендек әби.

— *Кендегәч қарчық* дийә торғаннар ыйы. Мин дүрт баламны да *кендегәч қарчық* белән тудым. *Кендегәч қарчық* баланы туwа, өтөреп сала.

## Кендекче, кентекче

**Кендекче, кентекче** *бараба.* кендек әби.

— *Кендекче* самақлап-самақлап[1] чапқан баланы мунчада:

«Әтилү бул, әнилү бул,
Тәүфиқле бул,
Йақшы теллү, йақшы сүзлү бул», — дигән.

— *Кендекче* йуwа бәбәйне дә, қатынны да қарый.

**Кентекче әби ишектән кергәндә [ырым]:**

— *Кентекче әбине* чақыралар. Аwырайақ кеше[2] қыйналаты[3] туwар wахыт йитсә. *Кентекче әби* ишекне ачып қычқыраты:

«Қысылтым, қысылтым,
алла пушат қысылтым», — тип.

Әшкәрә йиңел[4] генә бушанаты аwырайақ қатын.

— Туwырмақ кеше, пер пашлық[5] бала туwырып йөри тегән. Туғалы булса чақыратылар өннәмне[6]. *Кентекче* тип әйтәтеләр.

— Бала арқылы килсә дә, торқылы килсә дә, барыбер таптыра *кентекче*. Чит аwылға да алып киткәннәр *кендекчене*. *Кендекчегә* түләгәннәр, тере хайwан биргәннәр.

## Кендекче әби

**Кендекче әби** *эстр.* кендек әби.

— Өйдә туwа да йуwындыра, кендеген кисә *кендекче әби.* Төшкән кендекне җыйып қуйдылар кендекче әбиләр.

## Кентекләгән әби, кентекләгән мамай

**Кентекләгән әби** *тара.* кендек әби.

— *Кентекләгән әбийеңә* көйләк, шәл бирәтләр, кентек ипийе дә бирәтләр.

---

[1] самақлап-самақлап — тапмаклап-тапмаклап
[2] аwырайақ кеше — авырлы хатын
[3] қыйналаты — азаплана
[4] әшкәрә йиңел — бик җиңел
[5] пашлық — өлкән яшьтәге хатын-кыз
[6] өннә — әби

**Кентеклəгəн мамай** *төм.* кендек əби.

— *Кентеклəгəн мамайлар* кентекне ташламағаннар. Туwалығын əйтеп, қоротып, əрү[1] цеберəккə бөреп[2] қуйатылар йуғарыға.

### Кендегəйе

**Кендегəйе** *əстр.* кендек əби.

— *Кендегəйе* булған. Кендеген кисəде, баланың йесен[3] йуwып, ақ чүперəккə урап əрү җиргə күмəделəр кендегəйлəр.

### Кендекəй

**Кендекəй** *к.-уф., перм.* кендек əби.

— *Кендекəй* мунча кертə олан тапқан катынны, кендеген кисə — *к.-уф.*

— *Кендекəйем* əле дə исəн, аныңа күлмəк бирəм йыл да — *перм.*

### Мама, мамай

Əстерхан сөйлəшендə һəм себер диалектларында **мама, мамай** сүзлəре дə кендек əбине белдерəлəр.

### Инəкə мама

**Инəкə мама** *əстр.* кендек əби.

— *Инəкə мама* тудыра баланы аwылда бырач булмаса.

### Кендек мамам

**Кендек мамам** *əстр.* кендек əби.

— Кендек мамам баланы көн дə килеп йуwындырды, қырық көнгə хəтле йуwындырды.

### Мамай

**Мамай** *əстр.* кендек əби.

— *Мамайлар* йуwыртақлап[4] йөрилəр бала туып йатқанда.

---

[1] əрү — ару
[2] бөреп — төреп
[3] йес — соңгылык
[4] йуwыртақлап — йөгергəлəп

— *Мамай* булышады бала тудырғанда, бетен туған-тохом ни зат бирә инде, сөйөнче алалар.

— *Мамай* була торған ыйы, менә минем Зөһрә мамам булды. *Мамайға* мунча йаға торғаннар ыйы, мунчаға төшә[1] торғаннар ыйы. *Мамай* баланы йуwа торған ыйы.

— Тулғақ килгән wақытта *мамайны* чақырып апкиләделәр. *Мамай* киләде, пычағын әкиләде, кендек кисмәгә кирәк. *Мамай* қырқына хәтле киләде, баланы көн дә йуwады.

— Мине *мамай* қараған. Мин йатаққа[2] сыйарлық қына булғанмын, кечкенә булғанмын, җиде айдан туғанмын.

**Мамай** *төм.* кендек әби.

— Мин аwырый пашлатым. «*Мамайға* барайынмы?» — ти. «Бар», — тидем. *Мамай* тораты аwылта. Бала асыранып беткәч мине йыwып салды мамай. Баладан суң[3] булаты. *Мамай* аны йуwып, таса чеперәккә бөреп[4] пирде. «Син аппарып сиратта күмәрсең», — тиде. Қәйне йуқ, қайыныма[5] әйтәте. Минеңке палтысым[6] йәш қыс, қоймақ пешерте тулы итеп тәлинкәгә. *Мамай* да, қартым да пергә утырып чәй эчтек.

— Камилә *мамай* йөрәте. «Камилә *мамай*, ничә тустақ[7] чәй эчәсең? Йәш wақытта уналты, қартайғач сигез, хәзер дүртне генә», — дигән.

## Бабай, бабка

Мордва-каратай сөйләшендә *бабай, бабышка,* касыйм сөйләшендә *бабка* (<рус. бабка) сүзләре кендек әбине белдерәләр.

## Бабай

**Бабай** *м.-кар.* әби, кендек әби.

— *Бабайны* җәшәләр, белүче бабайны. Безнең авылда эчәүләр иде алар, эч карчык. Баланы да җывалар, тапкан кешене дә җывалар икән *бабайлар.*

---

[1] мунчаға төшә — мунчага керә
[2] йатақ — бүрек
[3] суң — соңгылык
[4] бөреп — төреп
[5] қайыным — каен атам
[6] палтыс — балдыз
[7] тустақ — чынаяк

## Бабышка

**Бабышка** [<рус. бабушка] *м.-кар.* кендек әби.

— Минн ад'ийым[1] *бабышка* булып җерде.

## Бабка

**Бабка** [<рус. бабка] *кас.* кендек әби.

— *Бабкалар* җөри иде, бабка буладырыйы бала түрәтә торган. *Бабка'а* бирәләр иде 'үли'ли'[2] и җаулы'. 'Әйнәмнең анасы *бабка* булып җери иде.

## Бахсы

**Бахсы** *эстр.* кендек әби.

— *Бахсы* дип без туғанда (тудырганда) бер мама булады. Шул мама туғызып[3] алған баланы, кендек кискән, шул қараған. Аwырғанда шул кимпер[4] килеп баланы ошықлаған[5].

## Қортқайақ

Себер диалектларында **қортқайақ** — карчык дигән сүз.

## Аппай қортқайақ

**Аппай қортқайақ** *төм.* кендек әби, имче карчык.

— *Аппай қортқайақны* тиз генә алып килделәр бала туғанда.

## Инәлек қортқайақ

**Инәлек қортқайақ** *төм.* кендек әби.

— *Инәлек қортқайақ* пелән мин түрт паламны та өйтә асыраған. *Инәлек қортқайақлар* туқсан йәшкә цығып үлтеләр.

## Оста қортқайақ

**Оста қортқайақ** *туб.* кендек әби.

— *Оста қортқайақны* цағыратылар пәпә[6] туғанда.

---

[1] ад'ийым — [< морд.] — әнием
[2] 'үли'ли' — күлмәклек
[3] туғызып — тудырып
[4] кимпер — хатын
[5] ошықлаған — имләгән
[6] пәпә — бала, бәбәй

## Инә, инәкә, инәлек

Әстерхан сөйләшендә һәм себер диалектларында *инә, инәкә, инәлек* сүзләре һәм түбәндәге сүзтезмәләр кендек әби мәгънәсендә кулланылалар.

### Кентек инә

**Кентек инә** *бараба.* кендек әби.

— *Кентек инәм* тип әйтәмен. *Кентек инә* ул зур кеше.

### Инәкә

**Инәкә** *төм.* кендек әби.

— *Инәкәләр* асырантыраты баланы. *Инәкә* баланы йуwындырып сәлтепкә салаты.

### Инәкә мама

**Инәкә мама** *әстр.* кендек әби.

— *Инәкә мама* тудыра баланы. Аwылда бырач йуқ иде. Туwа алмасаң **азан қычқыралар**[1]. Миңә Аптулла баба қычқырды. Қыйнала, таба алмаса, ир кеше китертеп азан қычқырталар. **Азан қычқырса** инде, бала туа булған. Ир кеше қычқыра аны, хатын-қыз түгел. Хатын-қызға йарамый қычқырырға.

### Инәкә әби

**Инәкә әби** *әстр.* кендек әби.

*Инәкә* сүзе им-том иткәндә дә кулланыла: Идел кичкән *инәкәләр* теле, минем телем түгел...

— *Инәкә әби* булды аwылда. Электә мамайлар арасында белгән кешеләр булған, алар йөргән бала туwайақ җирдә.

**Инәлек** *төм., тара.* кендек әби.

— Минем өннәм[2] *инәлек* пулған. Палаға аwырып китсә *инәлек қортқайақ* алып киләте.

— *Инәлек* белән балалар тис туып қуйаты. Инәлек әйтеп инәте:

---

[1] азан қычқыра — азан әйтә

[2] өннәм — әбием

«Йақты йулдан кереп киләм,
Алла тәлә уңыннан бирсен,
Аwырцылык белән тапмасын,
Йеңелцелек белән тапсын».

Инәлек баланы мунцада йуwаты. Инәлеккә көйләк кигесәтеләр — *төм.*

— *Инәлек* тигәннәр, бала асырата торған әби булған. Ул асыратқан баланы алып, кендеген кисеп, йуwындырып сала урынға — *төм.*

— *Инәлек* керәте. Асыранасын. Сылайты, пулышаты. *Инәлекләр* асырантырған[1] элек. Пелгән тоғаларын уқыйты — *төм.*

— *Инәлек булған кеше* теләк әйтәте:

«Алла тәғалә мидәт бирсен,
Пети күсе йарсын,
Үсе дә белми қалсын» — *тара.*

— Өч баламны инәлек таптырған. Кендек кисәте инәлек, өцәwен өйтә тапты. Чәпчә инәлек йөритегән, Сәхипчамал ул, Чәпчә тип қуйғаннар. Инәлек ипләп кенә сылап сунны төшерәте, сунны сыйаратта күмәтеләр.

## Инәлек әби

**Инәлек әби** *төм.* кендек әби.

— *Инәлек әбиләрем* бик оста булғаннар. Көйләклек, йаулық алып бирәбез аларға.

«Ошо нарасита төнйаға килеп,
атинәсенә рәхимле бала булсын», —

тип теләп қуйты.

Йанына утырып әйтәте:

«Алла тәләм, йартәм бир,
ошо нараситәне исән-имин асырағалы».

— Бала туған сун инәлек әбине көйләк биреп қәтерлиләр. Оста қортқайақ була — *төм.*

---

[1] асырантырған — тудырырга булышкан

## Инәлек нәнә

**Инәлек нәнә** *туб.* кендек әби.

— *Инәлек нәнәне* цақыратылар. Ул киләте, қулы йеңел булса, әшкәрә тис генә баладан бушанаты.

**Инәлек ишектән кергәндә** [ырымнар]:

**Көйләк итәген**[1] **йелбеп керә:**

— *Инәлек нәнә* көйләк итәген йелбеп керәте:

«Песмилла, песмилла,
Йел[2] булмасын,
Йеңеллек булсын,
Осон ғомерле булсын» — *төм*.

— Инәлек ишектән керәндә, итәген йелпеп кергән, песмилла әйтеп:

«Шайтаннар ийәреп кермәсен,
Шайтан-майтаннар[3] кермәсен,
Йел-күс[4] кермәсен», —

тип песмиллалап[5] керәте, сыпырып тораты инәлек.

Мин қысымны инәлек беләм тапқан.

Инәлек булған кеше **тус йандырып керә:**

— Тусға цирәңке цийып[6] кергән инәлек:

«Йен кермәсен», — тип.

Инәлек тусны йандырып керәте тә йақ-йағына **тус цирәңке цийып** йөгереп китәте инәлек. Айақ арасына да кертеп йибәрә утны:

«Айақ арасыннан йен үтеп китмәсен» — *туб.*

**Инәлек булу — саwаплы:**

— Урасбигә қортқайақ *инәлек* булыпты. Бөтөн аwыл йөрөткән аны. Йөсдән ашып китепте шул *инәлекнең* балалары. Аныңқы әрwақыт ғулы йеңел булған, кентекне дөрөс кискән. Қайбер *инәлекләр* гентекне қысға кискән.

---

[1] көйләк итәге — күлмәк итәге
[2] йел — җил
[3] шайтан-майтаннар — шайтаннар, җеннәр
[4] йел-күс — җен-фәлән
[5] песмиллалап — бисмилла әйтеп
[6] цирәңке цийып — шырпы сызып

«Қысқа кисепсез», —
тип әйтепте Урасбигә қортқайақ. Ул балацық үлгән.

*Инәлек* булу саwап тиделәр.

### Инәлекче

**Инәлекче** *бараба.* кендек әби.

— *Инәлекче* аwылда оста әбиләр булған. Қатынның балаға биле аурады. Ул әби инде йардәм итеп баланы қулға алған. Йуwады инәлек баланы, аузына май сөртәде.

— *Инәлекчеләр* болған, алар тоwырғаннар[1]. Күп кенә тоуған бороңғы кеше, әллә ничә бала болған. Кентекче килеп-китеп йөрәде, хәлен беләде.

### Қолағинәм

**Қолағинәм** *туб.* кендек әбисенә зурлап әйтү сүзе.

— *Қолағинәм* тиделәр инәлек қортқайақны, кендек кискән қортқайақны. Ул wақларның да, қартларның да қолағинәсе.

— Бер қортқайақ *қолағинә* булыпты. *Қолағинә* тип қуйатқан идек. Ул қортқайақ йөс ашуға йетеп дөнйа қуйты.

«*Қолағинәм* рухына», —
тип сатақа салам әйеттә.

### Қолақа, колақам

**Қолақа, қолақам** *туб.* кендек әбисе.

— *Қолақа* кергән. Аны чақырып алып кергәннәр. Менә Қорманбигә мама қолақа булады аwылта. Кем аwырайақлы, кем йиңеләйә, ул булышаты. Ул кентеген кисәте, йеп beлән буып қуйаты.

«Ул минем қолақам», — тип әйтәтегәннәр ите.

Қолақаға көйләк бирәтеләр ите.

Қатым-туwа уқытсалар да әйтәтеләр:

«Қолақамны да әйтеп китең», — тип тип искә алатылар.

— «Йел кермәсен, аурақ кермәсен» тип йелпенеп, итәкләрен йелпеп керәтеләр қолақалар».

— Сәйнәп қортқайақ қолақа булаты. Ул кешенең баласы йаңлыш йатса да аны бораты. Үсенең балалары булмаған. Ул имце тә ите. Ул йөс йәшкәцә йәшәп үлепте тиде.

---

[1] тоwырған — тудырган

## КЕНДЕК ӘБИЛӘРНЕ ЗУРЛАУ, ХӨРМӘТЛӘҮ ҺӘМ БҮЛӘКЛӘҮ

Изге күңелле һәм белдекле кендек әбиләрнең кадерен белеп, хөрмәтләп тору тиешлеге турында җирле сөйләшләрдә бик күп истәлекләр сакланган.

**Урта Урал (Свердловск өлкәсе) *к.-уф.* сөйләшендә:**

— Элек улан асыраганда *кендек инәйне* сақырып китергәннәр.

— *Кендек инәйне* сақырып алаң, *бүләк* бирәң, *күлмәк* бирәң, *шәлйаулық бирәң*. Кендек инәләре бар балаларымның. Элек бал'нискә бару булмады.

— Сәдәқә итеп *әпәй, күмәс бирәң* пешергән wақытында. Алай қулына тотқозу йуқ. *Чәйме, канфитмы бирәң*.

— Кендек әнигә тәч *күлмәклек бирәң*. *Күлмәк бирәң*, сақырып алаң кендек әбейне. Арта аны үлгәнсе *кендекәй* дип, *кендек әней* дип йөрейләр. Аның әнейе булып қала wы.

— Доға қылғанда доғадан қалдырмыйың *кендек әбейне*. *Кендек қызлары* күп минең кендек әбейнең.

— Хәлеңән килсә *күлмәк* салаң *кендек әбейгә*, хәлеңән килмәсә *тастымал* бирәң. Хәлеңән килдисә *күлмәк* кәрәк *кендек әбейгә*. Ул мунсасын индерә, баланы йыwа қый.

**Минзәлә сөйләшендә:**

— Кендек әби булған аwыл сайын. Беđ дә кендек әбисе белән таптық баланы. Кендек әбине бик хөрмәт иткәннәр. Đур кеше ул кендек әбисе.

Кендек әби өйгә кергәндә «матчалар сығылып торор», — дигәннәр. Бик хөрмәтле кеше булған кендек әбисе.

Шәмшенур қортқа кендек әбисе булған безнең Күҗәкәдә.

— Кендек әбигә қоймақ белән чәй эчерәделәр. Кендек әбигә чәй җасап биргәннәр икән, ул чәйне үзе эчмәгән, бәбәй тапқан хатынға эчергән. «Кибеккән ул», — дип.

Кендек әбине аштан-чәйдән қалдырмадылар. Аңа сабын, күлмәк, йаулықлар бирделәр.

— Бәбәй туғанда аwылда бер атақлы кендек әби булыр ыйы. Минем үземнең кендек әбийем Бәдиғолҗамал исемнейе, бөтөн

аwылға бер ийе. Әле мин үскәндә, мин кийәүгә киткәндә дә һаман шул кендек әбисе булып йөрде.

— Кендек әби булсаң әгәр,
Алырсың син бик күп саwап.
Үлеп қаберләргә кергәч,
Күрмәссең син ичбер азап.

**Себер диалектларында:**

— *Инәлек* сур кеше, қәтерли[1] инәлекне. *Инәлек* өйгә килеп керсә, өйдәге *арқалық*[2] *ийелеп китәр*, ди — *төм.*

— Бала туғац *инәлек әбине көйләк*[3] биреп қәтерләгәннәр. Оста қортқайақ пула.

— *Кендегәц булғанны* хадерен бик белгәле икән, *инәң белән тиң күргәле* икән *кендегәцне* — *том.*

— *Кендек әбийе* — хақлы. Пирбуй *хәйерне* анарға *бирергә кирәк, кендегәч әбийеңә.* Анан үз әнийеңә, үлгән булса. Бәйрәм сайын, балаңа йәш тулғанда йаулық булса да алып бүләк бирә идең — *том.*

— *Кентекләгән әбийеңә көйләк, шәл* бирәтләр — *тара.*

— Инәлек қортқайақ өйгә керсә, өйнең арғалығы ийелеп сәләм бирәте, — тиләр — *туб.*

## Кендек ипийе

**Кендек ипийе** *минз.* кендек әбисенә бирү өчен пешерелгән кечкенә ипи.

— Кендек кискән кешегә, кендек әбисенә *ипей биру* иде. Ипине түгәрәкләп җасап, уртасына бармақ белән чоқырлатып уйым йасап, *кендек ипийе* дип кендек әбисенә бирерләр ийе.

Менә җылақ бала булса әйтерләр иде:

«Әй, *кендек ипийе* бирмәдегезме әллә, нишләп җылый бу бала», — дийерләр ийе.

*Кендек ипийе* бирәләр ийе кендек әбигә, түгәрәк ипи салып, уртасына болай чоқыр йасап бирерләр иде.

---

[1] қәтерли — кадерли
[2] арқалық — матча
[3] көйләк — күлмәк

— Кендек әбисен бик хөрмәтләр ийек. Элек бит җуқ ɗаман. Ипекәй пешердег исә, ипи салғанда төртеп қуйар ыйық кендек әбисенә бирергә. «Кендек ипийе» дип.

Менә шулай мин ипи салған сайын барнағым белән төртеп қуйар ыйым. Әнкәй шулай қушты. «Кендек әбисе ипийе ул», — дип, ипи салған сайын аңа илтеп бирергә қушар ыйы — *минз.*

**Кентек ипийе** *төм.* бала тугач бирелә торган хәер (икмәк).

— Беренце бала туғац пешергән ипине *кентек ипийе* тип *кентек сәтәқәсенә* пирәте.

Эце аwыртулы булмыйты баланың.

### Кентек сәтәқәсе

**Кентек сәтәқәсе** *төм.* бала тугач бирелә торган хәер.

— Пала төнйаға килсә, перенце ипи пешергән wақыттта «аның *кентек сәтәқәсе*» тип, берәүгә пирәте.

## КЕНДЕК КИСҮ ҺӘМ ҖЫЕП КУЮ

Җирле сөйләшләрдә бала тугач кендек кисү һәм төшкән кендекне җыеп куюга карата бик күп йолалар, ырымнар сакланган.

Төшкән кендек белән баланың киләчәк гомере арасында ниндидер бәйләнеш бар дип караганнар. Кендекне изге китаплар эченә салып кую, югарыга кыстыру, бишеккә элеп кую, иген чәчкәндә иген белән бергә җиргә күмү һ. б. әле дә халык хәтереннән җуелмаганнар.

[Кендекне кисеп, тегәрҗеп белән бәйләгәннәр һәм төшкән кендекне изге китап эченә салып куйганнар]:

— Кендек әби белән тудым баланы. *Кендеген кисә* кендек әби.

— *Кендеген җитен тегәрҗебе белән бәйләп қуйа* кендек әбиләр. Мунчалар кергәч, йуғач, ул кендек төшәдерийе — *минз.*

— Чи тегәрҗеп белән бәйләп чығып киткән бер кендек әби, күзе күрмәгән. Ә ул чи тегәрҗеп бушаған, баланың қаны ағып бетә йазған. Йарый әле үлмәгән, күреп қалганнар — *т.я.-к.т.*

[Кендекне кыска калдырып кисмәскә кушканнар]:

— Кендекне қысқа қалдырып киссәләр, малайлар сигәк булалар. Әбиләр озынрақ қалдырып кискәннәр, төптән үк кисмәскә қушқаннар — *т.я.-к.т.*

**Әфтийәк арасына салып қуйалар:**

— Кендек әбисе *кендекне киптереп,* төреп китап арасына сала, әфтийәк арасына қуйадырыйы — *минз.*

**Доғалық эченә салып қуйалар:**

— *Кендекне киптереп* бер доғалық эченә салып қуйа торған булғаннар — *минз.*

**Коръән эченә салып салып куйалар:**

— *Кендекне* пиц башына куйып киптерәләр, төшкән кендекне. Аннары корән эценә салып куйалар — *чст.*

— *Кендеккә* арта йапрақ қуйа торғаннар ыйы, тиз төшсен, дип. Төшә wы. Минеке арта *қорән эчендә* булды төшкән кендекләре. Төшә wы, белеки генә булып қала wы. Аны арта *қорәнгә* қуйабыз инде, шулай қыйландық — *к.-уф.*

— Баланың төшкән *кендеген* мамайлар *корән кап эченә* салып қуйа торғаннар ыйы.

— Инәлек кентекләгән. Кентекләгән *кентекне* әwәл киптергәннәр дә *қорәнгә салып қуйғаннар — тара.*

— Қороп төшкән кендеген, беренче чәчен қоръән эченә тығыш ыйы. Шулай исемен җазып қоръән эченә қуйыш ыйы — *минз.*

**Кендекне бөти эченә салып тагып куялар:**

— Баланың кендеген *бөтү*[1] итеп тақтылар қый аны. Бармағ озондый була wы кендек. Ул қорый, төшә. Төшкәс аны қайсы кеше сормап йуғарыға қыстырып қына қуйалар — *к.-уф.*

**Кендекне абзар башына кыстыралар:**

— *Кендек әней* кеше бала тыуғас *кендеген* кисә дә, арта йыwа да, төрни дә сала.

— Қороп төшкән *кендекне* кендек инәйләр мал қарый торған җиргә арбазға[2] қыстырып қуйдылар.

«Мал өргәсен», — диделәр — *к.-уф.*

[1] бөтү — бөти
[2] арбаз — абзар

**Кендекне арғалыққа (матчага) қыстыралар:**

— *Кентекне арғалыққа*[1] қыстырып қуйа торған. Аш цәцкән[2] wақытта талаға цацаты — *төм.*

**Өй түбәгә[3] қыстырған:**

— Төшкән кентекне цүберәккә урап өй түбәгә қыстырған, ул анта қороп қалаты, йуғалаты — *туб.*

**Стенага бүрәнә арасына кыстыра:**

— *Кентеге* төшкәц *эстинәгә* йеккә[4] қыстырған. Йуғарыға қыстырмаған. Йуғарыға қыстырсаң, малай шуқ пулаты тигәннәр. Түбәнгә генә қыстырған, чеберәккә урап, песмиллалап — *төм.*

**Ишек башына элеп куялар:**

— *Кендекне* марлыга бәйләп, аның йанына бер йомырка салып *ишек башына* элеп қуйа торғаннар ыйы. Шул йомырқа кибеп қалады ишек башында, тора бирәде шунда — *эстр.*

Кендекне ишек қашқа (ишек өстенә) элеп қуйғаннар:

— Қортқайак тамырны ошлайты, қул тамырны. Қәсер йиңеләйәсең осақламый тиде. Үсем тә кентек кискәнем бар. Кертем, баланы туырып алдым, кендек кистем. Кентек кисү саwаплы тип әйтәтләр.

Кентек қороп қалса, песмилла әйтеп ишек қашқа элеп қуйатылар.

**Кендекне йеккә (ярыкка) кыстыралар:**

— Қорып төшкән *кентекне* қағасқа урап йеккә қыстырып қуйа торған — *төм.*

**Чормада морҗа янына күмәләр:**

— Тешкән *кендеген* чарлаққа[5] шуwал[6] йанына күмгәннәр — *эстр.*

---

[1] арғалық — матча
[2] аш — ашлык
[3] өй түбә — өйнең түшәме
[4] йек — ярык
[5] чарлақ — чорма
[6] шуwал — морҗа

## Кендекне бишеккә элеп куялар:

— Кендеген кисә, җуwындыра. *Кендекне* аҡ чеберәккә бәйләп *бисекнең мийесенә*[1] элеп ҡуйа җуғарыға, далада җөрмәсен, бала өйдән чыҡмасын, дип. Балаға күз тисә, аwырса, йыласа, шуны чайҡап эчерәләр иде.

— *Кендек мамай кендек* кисеп, урап, *бишек башына* элеп ҡуйа — *әстр.*

## Сәңгелчәккә (бишеккә) эләләр:

— Кентек инәм[2] тип әйтәмен, ул кендекче ғой. *Кендеген* кисеп *сәңгелчәккә*[3] *элеп ҡуйады* кендекне. Ул ҡороп кечерәйеп китәде ғой. Чеперәккә терәде аны. Белмәм аннары ул йағын.

— *Кендеге* төшкән суң кечү[4] генә чепрәккә төреп, *селкенчәккә* тағып ҡуйады бороңғы кеше.

— *Сәңгелчәккә элгән* баланың төшкән кентеген. Төсәлгән суң төшкән кентекне чүпрәккә бөрөп[5] сәңгелчәккә эләйде — *тара.*

## Бәллүгә (бишеккә) эләләр:

— Кентекче кисеп алаты кентекне. Ҡайсы кеше кентекне ҡысҡа кисә, бала үләргә мужыт. Кентекне ташламайты борон, *бәллүwенә*[6] тегеп элеп ҡуйаты. Бала тыныч йоҡлый — *төм.*

## Кендекне атка атланган кешегә биреп җибәрәләр:

— Төшкән *кендекне* җыйып ҡуйадылар кендекче әбиләр. *Атҡа менгән йулаучы* кешегә биреп җибәрәделәр. «Ат өстендә йөрсен, бийеклектә йөрсен», — дип йурап, ат менгән кешегә бирәделәр — *әстр.*

---

[1] бисек мийесе — бишек почмагы
[2] кентек инәм — кендек әбием
[3] сәңгелчәк — бишек
[4] кечү — кечкенә
[5] бөрөп — урап, төреп
[6] бәллү — бишек

**Ир бала кендеген — атның җалына бәйли, кыз бала кендеген — ишек бусага төбенә күмә, йә сандыкка салып куйалар:**

— Ир баласының кендеген атның җалына бәйлиде. Қыс булса кендеген сандыққа салады, йә ишек бусаға төбенә күмәде.

«Қыдырламасын[1], өйдә торсон,
Қысқайақлы бала[2] анда-монда чықмасын», — *эстр.*

**Кендекне сандыкта саклыйлар:**

— Инәлек *кентекне* кисәте. Аны қәтерләгән, йақшы кеше *сантығынта* сақлайты. Төшкән *кентекне* цеберәккә салып төрәте. Пороңкы кеше *кентекне*, қарын цацны ташламаған, *сантықта* пулған аныңқы — *төм.*

— Баланың төшкән кентеген цүперәккә урап *сантық төпкә* салып қуйатылар. Бала тапмаған кешегә цайқатып эцерәтләр, ул да қолаққа төшеп қалған — *төм.*

— *Кенgеге* теләсә қайда җөрсә, баланың эче аwыртучан була диләр. *Кенgекне* сондоқ төбенә, кендек қыймылтамый торған җиргә салырға кирәк. *Кенgек* қыймылтап торса, баланың эче аwыртучан була, диләр — *минз.*

— *Кенgеге* йортта калса, ул кеше китми икән. Китсә дә, үлгәц монда китереп йийалар икән. Выт шылай — *срг.*

**Урдық асқа (сәке астына) күмәләр:**

— Менә Нәқыйә бәбәйләгәле итте, мине чақырып килде. Әмәлем йуқ, бардым. Бәбәйләтеп қайттым. Кендекче йуwа бәбәйне дә, қатынны да қарый. Әwәл монда Мәрчән пашлық[3] булған, минем абам[4]. *Кенgекне* ақ чүпрәккә бөрөп, *урдық асқа* күмә тегән — *бараба.*

---

[1] қыдырламасын — читтә, биләмдә йөрмәсен
[2] қысқайақлы бала — кыз бала
[3] пашлық — олы яшьтәге хатын-кыз
[4] абам — әбием

**Кеше басмас йиргә күмә:**

— Пөтөн аwылның кентеген минем қарт инәм[1] кискән, атамның инәсе. *Кентекне кеше басмас йиргә* аппарып күмеп қуйаты, кеше қурасына[2] күммәйте — *бараба.*

**Кендек чыбалына (кендек зиратына) тимер салып (энә яки кадак) күмәләр:**

— *Кендекне* қуйа торған йир булған, ташларға йарамый кендекне. Уғынып, қазып, *күмеп қуйалар кендек чыбалына.* Қадақ салып күмеп қуйалар — *бараба.*

— *Кендек чыбалы* булған аwыл йанында, анда қуйғаннар *кендекләрен*, күмгәннәр туалығын[3] әйтеп, салаwат әйтеп. Әле дә бар әле *кендек чыбалы — бараба.*

**Кендек күмгәндә «энә санчып күмәләр»:**

— Төшкән *кендекне* чүпрәккә бөрөп, чүпрәк өстенә *энә санчып* қуйа.

«Ийәләнмәсен[4]».

*Кендек чыбалы* дип, анда аппарып күмә тегән — *бараба.*

**Кендекне иген чәчкәндә җиргә күмәләр:**

**Аш цәцкәндә цәцәләр** *төм.* иген чәчкәндә күмәләр.

— *Аш*[5] *цәцкәндә* кентекне пергә цәцә тегән ийе. Шунтай пулған.

«Аш уңсын», — тип.

«У, палабыс бәхетле булыр, ницек аш уңты», — тип. Сынар өцен *цәцәләр* ийе *кентекне* аш белән.

— Бәхетен сынап, *аш белән* бергә *цацтырғаннар* қороп төшкән *кентекне.* Шул нараситаның бәхетен сынап. Моның кентеге *төшкән аш уңармы.* Пу бала бәхетле булса, ғумере осон булса, *аш* уңаты.

Ғумере қысқа баланың *ашы цықмай* қалаты — *төм.*

---

[1] қарт инәм — әбием

[2] қура — абзар-кура, ишегалды

[3] туалық — догалык

[4] ийәләнмәсен — җенләнмәсен

[5] аш — иген

— Қырата[1] аш белән бергә цацқаннар қороп төшкән кентекне.

«Балаларыбыс та аш хәтле күп булсыннар».

Шалай булыпты әwәле.

## СОҢҒЫЛЫҚ, СОҢҒЫЛЫҚ КҮМҮ

**Соңғылық** — ана карынындагы яралгының тышчасы: бала белән бергә яралып, аны ана тәне белән тоташтыра һәм шул рәвешле аның туклануын, матдәләр алмашуын тәэмин итә торган орган; плацента (ТТАС).

Җирле сөйләшләрдә *соңғылық* атамалары һәм соңгылыкны урнаштыру, күмү йолалары да бик үзенчәлекле.

### Соңғылықны ару җиргә күмәләр:

— *Соңғылықны* салаwат әйтеп бағана төбенә күмгәннәр.

— *Соңғылықны* чабатаға салып, чормаға менгереп туфраққа күмәләр.

— Әби тәтә *соңғылықны* җуып җиргә күмә.

«Аны җөзтүбән күмәргә җарамый, җөзтүбән күмсә, икенче бала булмый имеш, җөзтүбән күмә күрмә», диләр.

Қойаш байышы җағына, ару җиргә күмәләр — *т.я.-к.т.*

— Кендек әбиләре баланы җуа, *соңғылықны* күмә бисмилла әйтеп чиста урынға — *минз.*

— *Соңгылыкны кеше йерми торган* йиргә әллә ничә кат йуwып, догалар укып күмәләр — *чст.*

### Соңғылықны қайын төбенә күмәләр:

— *Соңғылықны қайын төбенә* күмәләр. Әби әйтә: «Айақ асты булмасын, қайын төбе булсын», — *минз.*

Соңғылықны тимер салып агач төбенә күмәләр:

— *Қайын төпкә* генә күмәмсен *соңғылықны,* ағач төпкә күмәмсен. Ул ченнәнәте[2]. Тимер саласың да бергә күмәсең:

«Ченнәнмәсен».

---

[1] қыра — кыр

[2] ченнәнәте — җенләнә

— *Соңғылықны* ике айырылы *қайын төбенә* қуйсаң, фәрештәләр алып китә, имеш. Шул қайынға элеп қуйтым — *төм.*

— «Қайын төбе булсын, айақ асты булмасын», — диләр.

### Соңгылыкны иске чабатага салып, чыршы төбенә күмәләр:

— *Соңгылыкны* иске чабатага салып, чыршы төбенә күмэлэр. «*Соңгылыкка* басса, айак аwыртучан булыр», — дилэр. Шыршы астыга күмгэлэделэр, айак астыга табылмасын, дип — *нокр.*

Соңгылыкны идән асты базына күмәләр:

— *Соңгылыкны идән астына пүгәрәпкә*[1] казып күмгәннәр аны, тапталмасын да, кеше дә тимәсен дип, саламнарга тереп күмгәннәр казып — *чст.*

### Соңғылықны пүгрәпкә (базга) күмәләр:

— Инәлек пулған кеше соңғылықны қатақ[2] салып үсепеснең пүгрәпкә цүберәккә урап-урап күмәте. Песмилла әйтеп күмәтеләр.

«Шайтан йулламасын».

Шайтаннан қурыққаннар поронғылар — *туб.*

### Соңгылыкны эргәгә (нигезгә) күмәләр:

— *Соңгылыкны* астылы-өстеле *өйнең эргәсенә*[3] күмәтеләр қасып-қасып — *тевр.*

### Соңгылыкны зират янына күмәләр:

— *Соңгылыкны* зират әйләнәгә күмгәләделәр — *глз.*

**Соңгылыкны сиратқа (зиратка) күмәләр** *себ.:*

— *Соңғылықны* күмәтеләр *сиратқа*[4]. Инәлек қортқайақ[5] үсе Қорьән ошлап[6], цүперәккә бөрөп алып китәте *сиратқа күмгәле.* Күмеп киләте — *төм.*

---

[1] пүгәрәп [рус. погреб] — баз

[2] қатақ — кадак

[3] эргә — нигез

[4] сират — зират

[5] инәлек қортқайақ — кендек әби

[6] ошлап — тотып

**Соңғылықны бакчаға күмәләр:**

— Соңғылықны бақчаның буйына сазраққа[1] күмеп қуйалар, *чеперәккә урап, қадақ салып.* Санийа мамай белә Йәwештә.

## СОҢҒЫ, СУҢҒЫ

Әстерхан сөйләшендә һәм себер диалектларында *соңғы, суңғы* — әд. соңгылык.

**Соңғы күмү — әстерхан сөйләшендә:**

— Инәкә әби[2] *соңғыны* тотылған қура[3] буйларына, үсеп утырған тирәк асларына күмә булған.

**Соңғы, суңғы күмү** — бараба диалектында.

**Соңғыны идән астына энә яки кадак кебек тимер салып күмәләр:**

— *Соңғыны* өйнең астына, борос[4] астына инә қадап күмәләр. Ә йуған суны, чоқырға *қадақ ташлап*, күмәләр. Кеше басмас йиргә. Хәзер чыға да ишегалдына ақтара[5]. Ақтарырға йарамыйты. Кеше аwыру булыпты.

— *Соңғыны* идән астына йортқа күмәләр. *Инә саласың* да күмәсең. «Баламның ғомере озын булсын», — дип — *бараба.*

**Соңгыны кадак салып бусага астына күмәләр:**

— Бала туған сун төшкән *суңғыны қатақ* салып бусаға астына күмәтеләр.

«Ийәләнмәсен», — тип — *бараба.*

**Соңгыны тимер, кадак салып абзар артына күмәләр:**

— Кендекче әби баланы туwыра, суңғыны қызыл балчықлы йиргә алып барып күмә. *Тәмер*[6], *қадақ* салып мал сарайының

---

[1] сазрақ — сазлык
[2] инәкә әби — кендек әби
[3] қура — киртә
[4] борос — идән асты өрлеге
[5] ақтара — ташлый, түгә
[6] тәмер — тимер

артына күмә. Анда тәгәнәк үсә. *Тәмер чәчә суңғыны* күмгән суң — *бараба.*

### Тимер салып зиратка күмәләр:

— *Суңғыны* чеперәккә түгән[1]. Эченә тәмер салып күмеп қуйған. Қадау[2] чәчеп, *зиратқа күмәде — бараба.*

### Балта белән урынын чабып урнастыга (сәке астына) күмәләр:

— Суңғыны урнастыға күмәтеләр, уғыныт-уғыныт *балта мән урынын цабып-цабып* қуйатылар.

«Ченләнмәсен», — тип — *төм.*

## СОҢГЫ

**Соңгы** *срг.* соңгылык.

### Соңгыны ызба башына куйалар:

— *Баланың соңгысын ызба башына куйарга* икән, ап-аруга кибә, тора.

— Элек кырда тапканнар. Кендеген бәләгән, ар'ан эцергән, арбада йаткырган. Оланны цорнаган. *Соңгыны* кырда калдырмаган, китереп *ызба башына куйган.*

## СУҢ, СУҢЛЫҚ

Себер диалектларында *сун, суң, сунлық, суңлық* — әд. соңгылык.

### Бала суны күмү

— *Бала суны* булаты. Өйнең эчендә түберәккә[3] төреп күмәтләр — *төм.*

---

[1] чеперәккә түгән — чүперәккә төйнәгән

[2] қадау — кадак

[3] түберәк — чүпрәк

— Бала сунын цебергә[1] урап урындық астына кумәтеләр — *туб.*

— Йуwасың, тасартасың, *урнастыға*[2] кумәсең суңны қатақ салып. Қузы йарғаннан суң[3], *урындық астыға*[4] кумәтләр — *төм.*

— Бала суны төшкән сун *урындық астына* кумәтеләр, айақ басмай торған *эргә астына* кумәтеләр — *туб.*

— Суңны *өй түбәгә*[5] цығарып элдертте, йарымын *урын астыға* кумдертте. Ташламаған *суңны* қолағинәм. Өй түбәтә ул қороп китәте.

— Түбәгә апцығып балцыққа кумгәннәр *сунлықны.* Шуннан ул аwаға очоп китәт диләр қарцықлар. Балцыққа кеше йөрмәй торған йергә қуйма кирәк — *төм.*

— *Суңғыны* тасартып йуwып, эценә бер қақ сөйәк урап *өй түбәгә* пер мейешкә кумеп қуйатылар. Таса себергә урап, песмиллалап кумәтеләр.

«Йел[6] ийәләшмәсен» — *төм.*

## УЛАН АНАСЫ, УЛАН АРТЫ, УЛАН БҮКӘН

Урта Уралның (Свердловск өлкәсе) красноуфим сөйләшендә соңгылыкның түбәндә күрсәтелгән атамалары бар.

### Улан анасы

**Улан анасын** (соңгылыкны) чабатага салып багана башына куялар:

— Мәсә қындырғаннар *улан анасын. Улан анасын* сабатаға салып, бағана башына куйып қоротқаннар — *к.-уф.*

### Улан арты

**Улан артын** (соңгылыкны) чабатага салып биек урынга куялар.

— *Улан артын* аны элек чабата булайы, хәзер чабата йуқ. Чабатаға салалар ыйы да әбрәкәй башына қуйалар ыйы. Қарға

[1] цебер — чүпрәк
[2] урнасты — сәке асты
[3] қузы йарғаннан суң — бәбәйләгәннән соң
[4] урындық асты — сәке асты
[5] өй түбә — чорма
[6] йел — җен

алып китә арта. Элек тә шулай булған, хәзер дә шулай. Эт ашамасын, песи ашамасын. Қарға алып китсен. Шулай булды. Қошлар ашаса йарый диделәр.

— *Улан артын* сабатаға салып, сабатаның башын бәйләп қуйдылар. «Қошлар ашасын», — дип қуйдылар қый.

*Улан арты* төшкәнсе көттеләр кендек әбейләр. Сабатаға салып, крилса башына қуйғаннар, қарғаға алырға. Җиргә күмү булмады — *к.-уф.*

Улан артын (соңгылыкны) кеше йөрмәгән, ару җиргә күмәләр:

— *Улан артын* кеше йөрмәгән җиргә илтеп күмеп қуйа кендек әби. Айақ басмасын кеше аңар. Кендек әби аны әйбәт, таза җиргә генә күмә. Уқып-уқып күмеп қуйа — *к.-уф.*

— Белгән кендек әбейләр *улан артын* чепераккә урап күмеп қуйғаннар — *к.-уф.*

### Улан бүкән

**Улан бүкәнне** чабатага салып багана башына куялар:

— Сабатаның эсенә салдылар, *улан бүкән* диделәр. Аны бағана башқа ғына қуйдылар. Аны қош-қорт ашасын, диделәр. Қош-қортлар гонахсыз қый, алар ашаса йарый, диделәр.

— Сабатаға салып, бағананың башына қуйдылар. Қошлар аны килеп-килеп ашап китәләр — *к.-уф.*

## ОЛАН ОЙАСЫ

**Олан ойасы** нократ-глазов сөйләшендә: соңгылык. Аны зиратка күмәләр.

— *Олан ойасын* зиратка илткәләделәр, зиратка илтеп күмгәләделәр. Теләсә-кайа күмдермәделәр, ишег алларга нигә күмдермәделәр — *глз.*

— *Олан ойасын* зират йанда кайын төбенә күмеп килгәләделәр — *глз.*

## ИПТӘШЕ, БӘБӘЙ ИПТӘШЕ

**Иптәше, бәбәй иптәше** — минзәлә сөйләшендә соңгылык. Аны **агач төбенә** күмәләр, яки **чабатага салып** бакчага күмәләр.

— *Бәбәй иптәше* дип бер эт алмастай ғына җиргә, ару җиргә чоқыр қазып күмә торғаннар ыйы, җуып, чайқап, чүперәккә төреп күмәләр ийе.

— Әбиләр буладырыйы *бәбәй* китерү өченгә. Әwәле балниска барып бәбәйләү җуғыйы ул. *Бәбәй иптәше* дигәнне кендек әбиләр чиста ару йиргә күмәләр ийе бер ағач төбенә — *минз.*

— Чабатаға салып күмәләр ийе, кендек әби күмә.

«*Иптәшен күмдем*» — ди. Бақча тирәсенә күмә — *минз.*

— *Бәбәй иптәшен* җирне чоқып җиргә күмгәннәр, кеше йөрмәй торған җиргә. Қош-қорт ашаса да бала чирләшкә була ди. Пычрақ җиргә дә күммиләр, ағач төбенә күмәләр — *минз.*

## ЙУЛДАШ, ҖУЛДАШ, БАЛА ЙАТАҒЫ

**Җулдаш, бала йатағы** *әстр.* соңгылык. Аны чормага күмәләр:

— Бала туғач, төшкән җулдашын, бала йатағын чарлаққа күмәләр. Аның йанына қуйның ике ашығын салалар, берәwе унақай, берәwе сунақай итеп. Шуны чарлаққа күмәләр дип ишеткәнем бар.

### Әүләгә (ишек алдына) яки чормага күмәләр:

— *Бала йатағын* әүләгә[1] күмәләр, айақ басмас җиргә.

— *Бала йатағы, йулдашы* дип аны китереп чарлаққа[2] күмәделәр, балнистә туса да китереп чарлаққа күмәләр. Малай булса ашық салып күмәләр, қыз булса болай күмәләр чарлаққа, анда-монда түгел. Ул шуннан аwаға очып китә диләр. *Бала йатағын* алып қайт дип балнистән дә алып қайтадылар.

— *Бала йатағын* төкәнгә[3] күмгәннәр, айақ басмас җиргә — *әстр.*

---

[1] әүлә — ишек алды
[2] чарлақ — өйнең чормасы
[3] төкән — абзар

## ЙАТАРЫ, БАЛА ЙАТАРЫ, ЙАТАР УРЫНЫ

**Йатары, бала йатары, йатар урыны** әстерхан сөйләшендә: соңгылык.

— *Йатары, бала йатары, йатар урыны* диде. Аның эченә ашық салып әрү[1] җиргә күмәләр. Қуйның ике ашығын салып күмеп қуйалар. *Йатар урыны* дип ақ чүперәккә урап күмәләр — *әстр.*

## ЙУЛТАШ

**Йулташ** тубыл-иртыш диалектының тара сөйләшендә: соңгылык.

— Баладан суң урдығ астына[2], йә қураға[3] күмәтләр йулташны кентек инәләр — *тара.*

## БАЛА УРЫНЫ

**Бала урыны** *минз.* соңгылык.

— Бала урыны диләр аны. Кеше йөрмәгән айақ басмас җиргә әйбәтләп күмеп қуйалар, доғалар уқыйлар кендек әбиләр.

## ЙАТҚЫЛЫҚ

**Йатқылық** *перм., к.-уф, минз.* соңгылык.

— *Йатқылықны* чабатаға салдылар да канушни башына қуйдылар. Қош алалмастый җиргә қуйдылар. Қороп бетә икә wы шунда үзе. Алай җиргә бәрмәделәр, эткә-қошқа бирмәделәр — *к.-уф.*

Бала йатқылығын чичта җиргә күмәләр, айақ асты булмасын, қош-қорт ашамасын.

Иске чабатаға салып күмгәннәр элек, хәдер белмәйем — *минз.*

---

[1] әрү –ару

[2] урдығ асты — сәке асты

[3] қура — абзар

— *Йатқылық* төшмәсә тарма орлоқ[1] кебек орлоқны ашата, чыпчық орлоқны ашата, им печиннәр[2] ашата — *перм*.

## ИС, ЙЕС

**Ис, йес** әстерхан сөйләшендә: соңгылык.

— *Исте* алып, урап, чарлақның[3] туфырағына күмә булғаннар, ит[4] ашамасын дип. Мамай күмә булған.

— *Исен* җыйып ала, уны алып китеп айақ басмас җиргә күмәделәр, ақ чеберәккә урайдылар.

— Әүләгә[5] күмәде қалған затын, *исте*. Бала туwайақта[6] мама әзерләп қуйады таза чүперәкте. Чүперәккә урап әүләгә күмәде *исте* айақ басмас җиргә — *әстр*.

**Йес** (соңгылык) **төшмәсә** [ырым]:

— Зыйандаш[7] булат диде. Бер усал қатын иргә барды, бала күрмәде[8]. Шул кереп килгәндә мин бала туғанда минем йесем туқталды, тамақ эчкем[9] келәде. Йесем төшмәде. Қәрт қәйнәтәмез[10] килде дә тоз тутырып мылтық атқачын йесем төште. Тарсылдап мылтық атқачын тоз мынан йесем килеп төште — *әстр*.

## БАЛА АВЫЗЛАНДЫРУ

Бала тугач та авызына бал-май тидереп, салаватлар, изге теләкләр әйтү йоласы татар халкы яшәгән барлык төбәкләрдә күзәтелә.

---

[1] тарма орлоқ — киндер орлыгы
[2] им печин — дару үләне
[3] чарлақ — чорма
[4] ит— эт
[5] әүлә — ишек алды
[6] бала туwайақта — бала туганда
[7] зыйандаш — бозым, зәхмәт
[8] бала күрмәде — бала тудырмады
[9] тамақ эчкем келәде — эчәсем килде
[10] қәйнәтәмез — каен атабыз

## Аwызландыру

**Аwызландыру** — урта диалект сөйләшләрендә:

— Кендек әби бал белән, май белән аwызландыра салаwатлар әйтеп — *минз.*

— *Салаwат* әйтеп, бал белән аwызландыралар баланы — *каз.ар-дөб.*

— Май белән *аwызландыралар*. «Әниеңә-әтиеңә шәпкәтле бул, шушы май кебек тәмне телле бул», — ди.

— Бала тыуғас та бисмилла әйтеп *бал* қаптыралар, *май* қаптыралар, шулай *аwызландыралар*. Арта йыwындыралар — *к.уф.*

— *Кендек әби* баланы аwызландыра, аwызына бал-май тидерә.

«Пар қанатлы булсын,
Алтын қанатлы булсын,
Ата-инәле, бәхетле-тәүфиқле,
Тәмле телле булсын,
Бәхетле-тәүфиқле булсын» — *минз.*

## Авызландыру

**Авызландыру** — мишәр диалекты сөйләшләрендә.

**Авызландыру** *кузн.* бала тугач та авызына бал тидерү, бал каптыру.

— Түрәтә торган әбине[1] китерәләр, ылан тугач авызына *бал* тигезәләр. Имеш инде *авызландыру* була — *кузн.*

— Бала бал'ничадан килгәч, *бал-май* каптыра.

«Ата-ана йоласы,
Бәхетле бул, тәүфикле бул», —

дип каптыралар — *кузн.*

## Бәбәй авызландыру

**Бәбәй авызландыру** — чистай сөйләшендә.

— *Бәбәй авызландыру* бар. Шынарга бал белән май каптырыга кушалар.

---

[1] түрәтә торган әби — кендек әбисе

— Бәбәй тугац та бәбәй әбисе[1] авызландырган баллы майлар белән.

«Бәхет-тәүфик телим. Бал кебек телең татлы булсын», — ди.

### Аwызлыкландыру

**Аwызлыкландыру** — мишәр диалектының хвалын сөйләшендә:

— Әби[2] *аwызлыкландыра* баланы, кендеген кисә дә авызына бал ышки: «лә илаһә илаллаһ, мөхәммәде рәсүл аллаһ» — дип *аwызлыкландыра*. «Аллага кол булсын. Мөхәммәткә өммәт булсын», — ди — *хвл*.

**Бала аwызландыру, аwызлыкландыру** — әстерхан сөйләшендә.

— Мамай[3] үзе *аwызландыра*. Кем *аwызландырса*, бала шуарға ошый. «Үзем *аwызлыкландырдым*, холкы йахшы», — диләр. «Ул ғына *аwызландырды*, тирес[4], үҗәт[5] булды», — диләр — *әстр*.

### Аwызландыру

**Аwызландыру** — себер диалектларында:

— Балаға аwызына *бал-май* тигерәләр.

«Балди-майди теле татлы булсын», — дип қуйа — *төм.*

— «Әби, син *аwызландыр* әле. Синең ғүмереңне бирсен балама», — дидем.

Кем *аwызландыра,* шуңа ошиты бала.

«Усал булсын,
Эшкә батыр булсын,
Бәхетле булсын,
Қаршы килгәнгә
Күкерәге белән бәрсен», —

дип аwызландырды. Бал-май белән аwызландырды — *бараба.*

---

[1] бәбәй әбисе — кендек әбисе
[2] әби — кендек әбисе
[3] мамай — кендек әбисе
[4] тирес — тискәре, кире
[5] үҗәт — кире, үз сүзле

### Бабай аwызландыру

**Бабай аwызландыру** — нократ сөйләшендә:

**Бабай аwызландыру** — баланың авызына бал-май тидерү.

— *Бабай аwызландыра* салаwат әйтеп. *Бал* қабыза[1] аwызына, чормаштырып сала бишеккэ бер әби. Балаға аwызына *бал* тигезэ. «Татлы тормош булсын», — дип. Йә туғач уқ *май* қабыза аwызына — *нокр.*

### БӘБӘЙ МУНЧАСЫ

Бала тугач мунча ягып, яңа туган баланы да, яшь әнине дә мунчада юындыру борынгыдан килгән йола. Бу йолада кендек әбиләр дә, әби-бабайлар да, күрше-күләннәр дә актив катнашалар, күчтәнәчләр һәм бүләкләр китерәләр.

**Бәбәй мунчасы** хвалын сөйләшендә:

— Элке ыланны кертәләр *бәбәй мунчасы* дип, әбиләр дә килә. «Ад'агыз, *бәбәй мунчасы*», — дип чакыра. Бер ычтакан каймак, биж-алты йомырка, сабын китерәләр — *хвл.*

**Бәбәй мучасы** *минз., каз.ар., глз.*:

— Бәбәй туу белән муча кирәк. *Бәбәй мучасын* элек өч көн рәттән җақтылар. Хәdер инде қырығар көн җағалар.

— Мучада җуындырабыd бәбәй тапқан киленне дә, бәбәйне дә.

Онықларымы, онықчықларымы да үdем җуындырдым мучада — *минз.*

**Бәби мунчасы** *каз.ар., т.я.*

— Малай туғач мунча җағалар, көне буйы мунча керәләр. Күп кеше килә, күршеләр керә. Мунчадан чыққач бәби чәйе эчертәләр, қоймақлар, җуқалар пешеп тора — *т.я.-трх.*

— Бәбәй табучы айаққа басқач *бәби мунчасы* җағалар ыйы. Бәби әнкәсен дә, бәбине дә мунча кертәләр ийе. Җөрешә торған кешеләрне мунчаға чақырадырыйық. Мунча чығып чәй эчәбез.

---

[1] қабыза — каптыра

— *Бәби мунчасы* буладырыйы. *Бәби мунчасын* ишетсәләр, әйтмәсә дә киләләр. Күрше-тирәләр бөтенесе керә *бәби мунчасына.*

*Бәби мунчасына* кергәне берсе өйдә чәй эчеп чыға. *Бәби мунчасы,* бәби чәйенә қамыр ашлары пешереп қуйабыз.

«Бәби мунчасы әҗерле», —

дип керәләр ийе инде. *Бәби мунчасына* буш килмиләр, җә сабын, җә сөлге-тастымал қалдыралар инде — *т.я.-к.т.*

Бәбинең арқасын нық чапмыйлар мунчада, йәш тән бит. Әкерен генә лептер-лептер итеп алалар.

«Ай үсәсен көн үссен», —

дип себеркенең парын ғына җибәрәләр.

Бәби тапқан хатынны мунчаның қызуы беткәч кенә әби җуындырып чығара инде. Ләүкәгә җатқызып, уқый-уқый, өшкерә-өшкерә җуа ул аны. Әби булып җөргән кеше бөтен аwылның бәби мунчасыннан, бәби чәйеннән қалмаған — *т.я.-к.т.*

## Биби мунчасы

**Биби мунчасы** *баст.* бала тугач ягыла торган мунча, анда бәбине юындырганнан соң олы кешеләрне чакыралар, чәй мәҗлесе ясыйлар.

— *Биби мунчасы* җағалар, мунчасына қунақлар җыйалар иде.

## Нәнәй мунсасы

**Нәнәй мунсасы** *к.-уф.* бәби тугач ягып әзерләнә торган мунча.

— *Нәнәй мунсасына* кергәндә тастымал белән сабын алып керәң. Болай ғына кермийең *нәнәй мунсасына.*

Иң беренсе қәртнәйләре[1], қәрттәйләре[2] керә *нәнәй мунсасына.*

«Аларның йәшен бирсен, аларға ошаулы бала булсын», — диләр. Туғаннарын, күршеләрен дә сақыралар.

---

[1] қәртнәй — әби

[2] қәрттәй — бабай

— Минең әней кем мунча инә[1] икән дип, үзе мунча инеп чыққач кеше эзләп йөрде *нәнәй мунсасына*. Элек мунча бик қадерле булды бит, утын йағы начар булды — *к.-уф*.

## Мунча себеркесе

Яңа туган баланы юганда каен себеркесе белән йомшак кына җилпеп, ырым сүзләре, такмаклар әйтеп кую һәртәрле йола хәрәкәтләре белән башкарылган.

## Миллек, қайын миллеге

**Миллек** [рус. веник], **қайын миллеге** урта диалект сөйләшләрендә: мунчада чабыну өчен әзерләнгән себерке.

— Қайын миллеген иң йомшағын, бәләкәйен әзерләп қуйалар бәбәй мунчасына. Кечкенә миллекләрне йегермешәрне әзерләр ийе — *каз.ар.*

## Кайын винигы

**Кайын винигы** мишәр диалектында: мунча себеркесе.

— *Кайын винигы* белән чабындыралар әби булып килгәннәр — *хвл*.

## Қайын қаwағы, қайын йапырағы

**Қайын қаwағы** *тара.* каен себеркесе.

— Мунчада *қайын қаwағы* ман йилбиләр паланы. Қара мунча да, ақ мунча да булаты.

**Қайын йапырағы** *туб.* каен себеркесе; мунчада чабыну өчен әзерләнә.

— *Қайын йапырағын* пәйләп әсерләп қуйған мунцаға. Қайын йапырақсыс паланы мунца төшермибес. Менә *ақ мунчалық* ағач алып қуйғанмин.

## Нәнәй йапырақ

**Нәнәй йапырақ** *к.-уф.* яңа туган баланы чабу өчен әзерләнгән мунча себеркесе.

— *Нәнәй йапырақ* дип әзерләп қуйдылар wақ-wақ итеп йапырақны бәйләп. Шуның белән җилпеделәр, баланың тәннәре

[1] мунча инә — мунчага керә

нық булсын, дип. Хәзер сапмыйлар бит. Элек саптылар кендек әбейләр.

*Нәнәйнеке* белеки генә, йомошақ қына *йапырағы* була анықы. *Йапырақ* бәйләгәндә үк бер-икене белекине бәйләп қуйалар. Нәнәйләрне сабарға дип.

## Улан чапқан йапырақ

**Улан чапқан йапырақ** *к.-уф.* мунчада баланы чапкан себерке.

— Әтнәнең буйына мунча җағып баланы чабабыз. *Улан чапқан йапырақ* белеки була.

## Баланы мунча кертү

**Минзәлә сөйләшендә:**

— *Кендек әби* олан тудырған ананы мунча кертә. Бөтен тәнен, табан асларын сылап-сылап җуындырып ананы да, баланы да қадерли.

«Бәхетле бул, таза бул», — ди.

*Кендек әбиләрем* күршедә генә ийе, әби қулына төште балаларым. Кендек әбиләрен бер дә доғадан қалдырмыйбыз — *минз.*

— *Кендек әбисен* алып килдем әле баланы мунча кертергә, диләр. Кендек әбисенә сый әзерләп қуйғаннар, қадерле ул кендек әби. Им-том да итә кендек әби.

«Минем *кендек әбийем* бит ул», диләр, хәdердә дә. Шуңа *кендек әбийемә* доға қылығыd, диләр. Кендек әбисе бик оло кеше ул — *минз.*

— Баланы муча керткәндә кендек әбисе баланы қайын пиннек белән чабар ыйы:

«Ата сарылы булсын,
Инә сарылы булсын,
Туғаннары сарылы булсын.
Аталы-инәле булсын,
Алтын қанатлы булсын,
Олыларны олы итсен,
Кечеләрне кече итсен,
Бәхетле булсын,

Тәүфиқле булсын,
Тиген қарағыԁ балағыԁны», —

дип әйтеп чабар ыйы.

— *Кендек әби* бәбәйне чаба мучада:

«Муча ташы,
Бүрәнә башы,
Аллаға қол булсын,
Мөхәммәткә өммәт булсын» — *минз.*

**Казан арты-лаеш сөйләшендә:**

— *Әби* итеп чақырғаннар. *Әби* өч мунча кертә бала тапқан хатынны. *Бәбине* дә җуа, әнисен дә. *Әбине* қунақ иткәннәр, әбигә күчтәнәч, бүләк биргәннәр — *каз.ар.-лш.*

**Казан арты балтач сөйләшендә:**

— *Кендек әбиме*, үзенең әбисеме баланы мунчада йуындырғанда қайын миллеге белән чаба:

Айу баласы, бүре баласы,
Бүреккә саласы,
Айу баласы, бүре баласы,
Йалан төлкесе...

**Волгоград сөйләшендә:**

— *Бәбәй мунчасы* була бәбәй туган көнне үк. Килгән әбиләр дә керә *бәбәй мунчасына.*

Менә бездә *бәбәй мунчасына* йегерме катын ийылды. Йакыннары килә берчесе.

«Бәбәй мунчасына керийек,
Күркәйербез бәбәй кебек», —

дип мунча керәбез. Әрберсендә мунча хазер.

Салаwат әйтеп оланның айакларын, аркасын сабынлый кендек әби.

Кайын винеге, имән винеге белән аркасын чаба йылы суга манчып. Пары сала да чаба:

«Йакшы бала булсын,
Сау-сәламәт булсын,
Ата-аналы,
Әбиле-бабалы булсын,

Атлы-тунлы булсын,
Аллага кол булсын,
Ризыкка, бәхеткә каршы
Туган бала булсын».

— Туган катынны да йывалар *бәбәй мунчасында*. Мин ойала идем кан'анамнан, кан'сеңелем йывындырды мине бәбәй мунчасында. Бәбәйне дә күреп өлгермәдем, йывындырып алды.

Килгән әбиләр, күршеләрне дә керергә ат'абыз *бәбәй мунчасына.*

«Ад'агыз керийек бәбәй мунчасына.
Красивый булыйык», — дип ат'алар.

*Бәбәй мунчасында* оныкларымны үзем чабам, пары салам да чабам, винек йакшы, күп кеше керә мунчага. Үзем чабам, жар чабам мунчада.

Аштыр-таштыр,
Йаманнардан ад'аштыр,
Йакшыларга йулдаштыр,
Ач итмә, йалангач итмә,
Үзеңнән гайрегә мохтаҗ итмә.

**Хвалын сөйләшендә:**

— *Әби* йәж баланы да, ананы да мучага кертә, тугач та кайын винигы, кан'ар су әйбәт. *Әби* балага әтеп чаба:

Атаң кискән утын түгел,
Анаң йаккан муча түгел,
Бүрәнә башы, бүре теше, у-у-у, —

дип чаба, таза бул, сау бул дийә — *хвл.*

**Тау ягы керәшен сөйләшендә:**

— Олан әбисе[1] кендек кисә, баланы җуwа. Кендекне кибезеп, ак киндергә чорнап куйалар. Оланның эче аwыртса, шаны чәйкаб эчергән — *т.я. крш.*

— *Олан әбисе* баланы мунчада йуwа, чабындыра:

Әби-баба мунчасы
Җан тынычы бирсен,

[1] олан әбисе — кендек әби

Көн тынычы бирсен,
Җапрак кебек җарпайсын,
Комнак[1] кебек кабарсын,
Борчак кебек тәгәрәп җөрсен,
Куйан кебек сикереп җөрсен.
Кирелгистән киртә буйы,
Сузылгистан су буйы булсын,
Кайын ничек таза булып үсә, шылай
Үссен, дип чәпәли, ләп-ләп чаба.
Айу кебек батыр бул,
Куйан кебек җитез бул,
Бүре кебек усал бул,
Кайын кебек җарпай,
Чәчәк кебек кабар, —
дип чаба — *т.я.-крш.*

**Пермь сөйләшендә:**

— *Кендекәй*[2] *чаба* баланы мунчада:

Ата баласын чабам,
Инә баласын чабам.
Атаң кебек симез бул,
Инәң кебек җитез бул,
Көндез уйна, төннә җокла, — ди — *перм.*

— Ата баласын чабам, инә баласын чабам тип әйтмәгә кушмыйлар, йарамый ти карт әни, *шайтаннар белмәсен*, ти.

**Айу баласы, бүре баласы:**

Айу баласын чабам,
Бүре баласын чабам, тип әйт.
Айу кебек симез бул,
Бүре кебек җитез бул,
Көндез уйна, кич җокла,
Әбине әби дип әйт, бабайны бабай дип әйт,
Әйшә-Батыйма[3] куллары

---

[1] комнак —колмак
[2] кендекәй — кендек әби
[3] Әйшә-Батыйма — Гайшә-Фатыйма

Име-йомы шул булсын,
Бәкытле бул, тәүпиклы бул,

Тауга–ташка тфү–тфү дип төкерәсең, бәкыт сурап чапканнар мунчада — *перм.*

**Себер диалектларында:**

— Қырық көнгә қадәр көн дә мунча йаққан бала туғач.

— Мунчада қайын қаwағы[1] ман йилбиләр[2] паланы.

«Шиба[3] қаwақлары булсын, исәнлек-саулық бирсен» — *тара.*

— Баланы йомшақ йафырақ белән сыпыра инәлек қортқайақ[4] мунчада, баланы йуwаты.

Минем балам түгел,
Айу баласы, бүре баласы,
Муйса[5] ташы, бүрәнә башы, бүре теше.
Сыулар буйы сузылсын,
Киртә буйы кирелсен,
Таштиˆ[6] таса пулсын,
Атинәсенә мәрхәмәтле,
Тәүбиқле, идайәтле булсын,
Ырисықлы, тәүләтле булсын, —

дип теләйсен. Инәлек қортқайақлар баланы баштан айаққа қадәр сыпыра. Йаңа туған баланы шулай итеп төшергәннәр мунчаға. Мин инәлек қортқайақ белән асыраған[7] баланы. Баланы да, ананы да мунца төшергәннәр, қайын йапырағы белән цапқаннар.

**Урта Урал (Свердловск өлк.)** ***к.-уф.*** **сөйләшендә:**

**Мунча индерү** *к.-уф.* мунча кертү, мунчада юу.

— Кендек әней қырық көннең буйына мунча йағып *мунча индерә* баланы.

---

[1] қайын қаwағы — каен себеркесе
[2] йилби — җилпи
[3] шиба — шифа
[4] инәлек қортқайақ — кендек әбисе
[5] муйса — мунча
[6] ташти — таш кебек
[7] асыраған — тудырган

Қырық көннең буйына *мунса индерделәр* қайсы бер кендек әбейләр. Көн дә, көн дә йуwынсын бала, бер көн дә қалмасын йуwынмый.

Қырық көннең буйына *мунса йақтылар*, кендек әбейләр сылап-сылап йыудылар баланы. Арта *кендек әбейне сәйгә сақыралар*, йаулық салалар.

— Йаңы тыуған баланы қырығы тулғанчы *мунса индерергә* кәрәк дип әйтәләр ине.

[Урта Уралның к.-уф. сөйләшендә кендек әби баланы мунчада юындырганда бик күп ырымнар, тылсымлы сүзләр куллана: биредә **мунча төнлеге, мунча ташы, мунча матчасы** һ.б. йола хәрәкәтләре белән кушылып китәләр].

— Кендек әбей уланны мунса индергәндә тақмақлап саба торған ыйы.

**Төндөкне**[1] ача да:

«Минем сабыйым йылақ түгел, йылақ түгел», — дип **сыу сибә** торған ыйы.

«Минем сабыйыман чирләре чығып очсон,
Бәхетсезлекләре чығып очсон,
Қара қошлар алып китсен,
Қарғалар алып китсен,
Әмин, әмин», —

дип әйтеп **мунчаның матчасына йафрақның төбе белән төртеп ала** торған ыйы.

Йафрақ белән башынан айағына қадәр сыпыра торған ыйы, **төндөктән сыу сибә** торған ыйы.

— Уланны[2] мунчада чаба дағын аның тәненнән тирен суырып алып ташқа төкереп қуйа икә:

Таш чабам, таш чабам,
Таш кебек нық бул,
Ләүкә кебек озон бул,
Мунча ташы, бүрәнә башы.
Қандалаға қаптырма,
Кәгәwенгә киптермә,

дип мунча индерә.

---

[1] төндөк — төнлек
[2] улан — бала

«Чиреӊ-чороӊ бар да шунда қалсын», — дип мунча ташына төкереп қуйа икә.

— Қайсы кендек әбей менә болай әйтеп чаба икә:

Айыу баласын чабам,
Бүре баласын чабам,
Айыу кебек аға бул,
Бүре кебек боға[1] бул,
Қуйан кебек йөгерек бул.
Тәмле-татлы телле бул,
Инә-атаӊа шәпқәтле бул.
Әбине күрсәӊ — әби дип әйт,
Бабайны күрсәӊ — бабай дип әйт.
Бәхетеӊ артсын,
Ғумереӊ артсын.

Бала чапқан йапырақны **нәнәй йапырақ дип төндөктән ташлый** ыйы Шәмшехәйәт әбей. Мунча төндөген ачайы да төндөктән ташлыйы. Аннары бисмилла әйтеп **мунча мичена кертеп йағайы**.

— Ағыйделнеӊ арйағыннан **имче-йомчы қортқа**[2] килгән.

Атаӊ йаққан утын түгел,
Инәӊ йаққан мунча түгел.
Айу кебек көсле бул,
Бүре кебек тешле бул.
Қуйан кебек сикереп йөр,
Борчақ кебек тәгәрәп йөр.
Бабайны бабай дип әйт,
Әбине әби дип әйт.

Кендек инә мунчада баланы чаба:

Ата баласын чабам,
Инә баласын чабам,
Атаӊ кебек симез бул,
Инәӊ кебек җитез бул.
Көндез уйна, төннә җоқла,
Аш бағытыӊ күп булсын.

---

[1] боға — үгез

[2] имче-йомчы қортқа — имче карчык

Ата баласын чабам,
Инә баласын чабам,

тип әйтмәгә қушмыйлар, йарамый ти қарт әни, **шайтаннар белмәсен,** тей:

Айу баласын чабам,
Бүре баласын чабам,
Айу кебек симез бул,
Бүре кебек җөгерек бул.
Көндез уйна, төннә җоқла,
Әбине әби дип әйт,
Бабайны бабай дип әйт.
Әйшә-Фатыйма қуллары,
Име-йомы шул булсын.
Минем қулым түгел,
Ағыйделдән ағып килгән имче әбинең қулы.

Чирле баланы чапқан **нәнәй йапырақны төндөктән бәрәләр**.

«Қайан килдең шунда кит», — дип.

— **Кендеге төшкәнсе бер йапырақ белән сабасың**, аңан сун улан чапқан **йапырақны сыуға ташладылар** шай. Улан чапқан йапырақны **мунчаның төндөгеннән бәрәләр** ийе алып чығып.

**Баланы мунча чабындыру** нократ-глазов сөйләшендә.

[Баланы чапкан **миллекне** (мунча себеркесен) мунчаның төнлегеннән ташлыйлар]:

— Баланы чапкачын *миллекне мунчаның төнлегеннән ташлайлар*. Андый гадәт булган, *миллеген* алай бәргәләгәннәр.

Карт әби булган, бер әби. Ике бала тапканда мин. Ул әби мича керткәләде олан тугачын. Алай мунча кертмә әби килгәләде.

Бәкытле бул,
Тәүфикле бул,
ата-ана белән үс,
озон гомерле бул, —

дип такмаклап чаба иде оланнарымны — *глз.*

**Бала йуwындыра торған су** *к.-уф.*:

— Баланы йуғанда *йарма суы* белән *йуwындыралар.* «Йармасы қалқа», — дип.

— Баланы йуғанда *сыуға тоз салып йуwа* кендек әби. Бөтөн йирен йуwа.

## БӘБӘЙ ТУУ ХӨРМӘТЕНӘ ҮТКӘРЕЛӘ ТОРГАН МӘҖЛЕСЛӘР

### Бәбәй ашы, бәби аш

**Бәбәй аш, бәбәй ашы** *каз.-ар., минз., нокр.* бәбәй тугач котлап бәлеш һ.б. ашамлыклар илтү.

— *Бәбәй ашы* китерәләр қазнасында нәстәкәй бар: қоймақ, бәлеш, баwырсақ, чәкчәк — *минз.*

**Бәби аш** *глз.* бәбәй ашы.

— *Бәби ашка* котлачклап[1] бала әйбере китерәләр, бешерешәләр пирәмәч, бөккән. Элеке йылларны бәлеш бешерәләр иде *бәби ашка — глз.*

### Бәбәй ашы илтү

**Бәбәй ашы илтү** *каз.ар.-блт.* бала тугач котлап бәлеш һәм башка төрле күчтәнәчләр илтү.

— Бибикамал аппай бәбәйләгәч тә қызыл ашаулығыма төйнәп бодай йармасы белән қабақтан бәлеш пешереп илттем. «*Бәбәй ашы* илтәсеңмени?» — дип сорыйлар урамда уқ күршеләр.

### Аш кертеш

**Аш кертеш** *минз.* ашамлыклар әзерләп, бала тудырган хатынның хәлен белергә керү.

— Бәбәй туғач, күршеләр аш кертеш булды. Кендек әби бәбәйне тудырғанда булыша, қулына алуға, күрше-күкерт аш керткән. Умач пешерепме анда, тоқмач кисепме, шулпа керткәннәр бәбәйләгән хатынға. Бәбәйләгәненңне белсәләр, ашын, қоймағын, бәлешен пешереп кертәләр күршеләр.

---

[1] котлачклап — котлап

## Аш белән килү

**Аш белән килү** *срг.* ашамлыклар әзерләп, бала тудырган хатынның хәлен белергә килү.

— Олан тапкан әнине багарга киләләр аж белән. Йә катлама, йә пирашкилар пешерәләр, сөтләш. Әбиләр кунак йәшәләр. Сөтләш гарабдайдан, суп пешерәләр.

— Сөтләш пешереп китерәләр, күмәц китерәләр. Үзләре дә күмәц белән цәй эцеп китәләр. Шылай иде әwәле — *срг.*

## Аш пелән керү

**Аш пелән керу** *туб.* коймак һәм башка ашамлыклар белән бала тудырган хатынның хәлен белергә керү.

— Күсе йарған кешегә[1] *аш пелән керәтеләр*, қоймақ буламы, башқа нимә буламы. Элек кеше мохтаҗны белгән, әдәпле булған.

## Бәби кимагы, бәбәй қоймағы

**Бәби кимагы** *чст.*, **бәбәй қоймағы** *минз.* бәбәй тапкан хатынга күршеләре яки туганнары пешереп алып килә торган коймак.

— Элгәре *бәбәй кимагы* пешереп килү ийе бәбәй туган кешегә, кимаг алып килеш ийе. Киленгә *бәбәй кимагы* — цеце кимак[2] пешергәннәр инде. Аннан сың бәбәйнең хален белергә килгән кешегә цәй эцергәннәр — *чст.*

— *Бәбәй қоймағы* пешереп китерәләр, кем ачыға, кем төчегә — *минз.*

## Бәбәй боткасы, бәбәй буткасы

**Бәбәй боткасы** *т.я.-крш.* бала туу хөрмәтенә уздырыла торган мәҗлес.

— Аш-боткалар пешереп барганнар *бәби боткасына*. Түр башында олан әби[3] утырган.

---

[1] күсе йарған кеше — бәбәй тудырган кеше

[2] цеце кимак — төче коймак

[3] олан әби — кендек әбисе

**Бәбәй буткасы** *влгг.* бала туу хөрмәтенә уздырыла торган мәҗлес.

— Туган хатын хал' ала төшкәч *бәбәй буткасы* була. Күп кеше чакыралар. Анда салма ашаталар, салма артыннан чөче бутка, кур'ага, йөзем белән. Падарыклар китерәләр.

## Бәбәй күҗәсе

**Бәбәй күҗәсе** *влгг.* бала туу хөрмәтенә пешерелә торган ботка.

— Бәбәй буткасы, *бәбәй күҗәсе* пешерәләр иде. Тевә идек киле белән түне, бодай да сала идек йарма йасап. Йөзем эләк, күрәгә сала.

## Май аш, майаш

**Майаш, май аш** *нокр., глз.* бәбәй туу хөрмәтенә уздырыла торган мәҗлес.

— Кодага[1] илтәсең туганнарыңны, нәсел-йәwереңне[2]. Алар бар да *майашка* әйбер котлап китерэ, бәбәй кийем китерә.

— *Майаш* дип әйтэлэр бабай тугач, кунак чакыралар. Пешешемнэрне[3] йаман күп куйалар өстелги.

— *Майаш* дилир. Бәбәй ашка чакырабыз исем салганда[4] ук. Бәбәй котламага дип йакын кешелэр удийал, күлмэк йә йурган ала.

— *Май ашта* бәбәй анасына май суккан айран[5] эчертэлэр — *глз.*

## Биби майы, бәби майы

**Биби майы** *кузн.*, **бәби майы** *каз.ар.-лш., том.* бала туу хөрмәтенә уздырыла торган мәҗлес, өстәлгә бал-май да куела.

— *Биби майына* киләләр. Йийа кардәшләрен. Бутка китерә, бәлеш китерә, катыннар килә *биби майы* ашарга. Ылан чирә-

---

[1] кодага илтү — туй мәҗлесенә алып бару

[2] нәсел-йәwер — нәсел-нәсәп

[3] пешешем — камыр ашлары

[4] исем салу — исем кушу

[5] май суккан айран — май әйрәне

пүнкәләре[1] белән май китерәләр, гаршук пикечләргә[2] салып сөт китерәләр —*кузн.*

— *Биби майына* йийа. Килә кардәшләре, бутка китерә, бәлеш китерә, катыннар килә *биби майы ашарга — кузн.*

— *Бәби майына* дип бүләк сала, аш қуйалар, бәлеш, төче-мөче, тура-май[3] қуйа өстәлгә уртаға, бал-май қуйа, бәби майына бардық дип сөйлиләр — *каз.ар.-лш.*

**Бәби майы** *том.*:

— Өйдә айақ басыр урын йуғ инде. *Бәби майы* дип бал-май китерәләр. Инәм сарық бирде, «пирбуй туған нугыма[4]», — дип китерде — *Йәwештә.*

**Бәбәй майы** *том.:*

— *Бәбәй майы* дип үзе йасаған май белән чәй эчкәннәр. Май әзерләп қуйған әркем чәй эчәргә. Бәбәй қотлап әрбер туғаны аш китерә. Кем балан бәлеше, кем кишер бәлеше, қоймақ. Кем ачыға, кем төчегә. Бик зур саwап инде, туған қатынға[5] ни булса да китерсә, саwабы бик зур икән. Бешемле май утысатлар, эссе икмәк — *том.*

— Элгәре ат куштыралар, шының артыннан бәбәй майы була. Анда әркайсы май илтә, чи май, күләкме анда, ни зат инде.

Бәбәй майында бәбәй мунчасы да йагалар. Бәбәй майына килгән кеше мунча керә.

«Мунча керегез,
Май ашагыз,
Бәбәй үпкәче булмасын,
Йомшак кеңелле булсын» —

дип май куйалар. Үзләре атлаган чи май куйалар — *влгг.*

## Бабай бал-май

**Бабай** — нократ-глазов сөйләшендә: бәбәй.

---

[1] ылан чирәпүнкәләре — бәбәй савыты
[2] гаршук пикеч — кечкенә чүлмәк
[3] тура май — кортлы май
[4] нугым — оныгым
[5] туған қатын — бала тудырган хатын

**Бабай бал‑май** *нокр.* бала туу хөрмәтенә уздырыла торган мәҗлес, чакырылган кешеләр бүләкләр белән киләләр. Бал‑май белән кунак итәләр.

— *Бабай бал‑майга* чакыралар, чакырмайчы да киләлэр. Бабай котлайлар. Бабай әйберләр[1], күлмэкләр, адийаллар, кайнанасына, кайнатасына бирнә[2] китерэлэр. Анда эчерэлэр бал‑май белэн чәй — *нокр.*

## Бабай сүбәт

**Бабай сүбәт** *нокр.* бәби туе, бәби котлау мәҗлесе. *Сүбәт* гарәп теленнән кергән сүз: беркетү, язып беркетү.

— Йаман күп кунаклар чакырдылар *сүбәткә.* Тәбәгый[3] китерделәр, оланга күлмәкләр, бәйләwечләр[4] китерделәр. *Сүбәттә* үзем кизүләп йөрдем[5], зур чуннар[6] күтәреп йердем — *нокр.*

## Бәби туйы, бәбәй туйы

**Бәбәй туйы** *урт.д., миш.д.* бәби туу хөрмәтенә уздырыла торган мәҗлес.

— *Бәбәй туйын* менә арци тешеп[7] туй иткән сыман бик зурлап уздыралар.

«Ары‑бире *бәбәй туйы* тегелдер бит, белмицә бара күрмә тагын», — диләр.

Туганнарын дәшәләр *бәбәй туйына — чст.*

— *Бәбәй туйы* ул үзенә атаклы аш ыйы. Ҡайсы чәкчәк, ҡайсы бәлешләр алып килерләр ийе, паштитлар алып килерләр ийе. Буш килмиләр ийе бер дә. Йә йаулығын, йә ситсасын алып килерләр ийе — *минз.*

— Аш‑быткалар пешереп барганнар *бәби туйына. Бәби туйына* олан әбисен[8] дәшкән, түр башына утыртып зурлаган — *т.я.‑крш.*

---

[1] бабай әйберләре — бәбәй әйберләре
[2] бирнә — бүләк
[3] тәбәгый — баллы пирог, кекс
[4] бәйләwеч — бала чүпрәге
[5] кизүләп йөрү — өй эшләрен эшләп йөрү
[6] чун — чуен
[7] арци тешү — туй кодалары килү
[8] олан әбисе — кендек әбисе

### Бибич туй

**Бибич туй** *эстр.* бәбәй туе.

— *Бибич туйға* қәрдәшләрен чақыра, қуншыларын[1] чақыралар.

### Нәнәй туйы

**Нәнәй туйы** *к.-уф.* бала туу хөрмәтенә оештырылган мәжлес. **Нәнәй** *к.-уф.* бәбәй, бала.

— *Нәнәй туйда* үзеңнеке туғаннарың, күршеләрең килә. Анда бүләк таратаң, тастымал таратаң. Шулай үзеңнекеләрне сақыраң.

— Ирле кешеләрне генә чақыралар ыйы *нәнәй туйына*. Ырымлап инде. Тигез йәшәсен, бөтен йәшәсен тип. Хәзер дә *нәнәй туйы* дип чақырып йөриләр қый. *Нәнәй туйы* шул исем қушқанда була.

### Бишек туйы

**Бишек туйы** *эстр.* бала туу хөрмәтенә уздырыла торган мәжлес.

— *Бишек туйына* қыз анасы үзенең бөтен булған туғантохомын җыйып килә. Бәбәйгә кийем килә, пылау пешерәсен, кийет[2] бирәсен. Бишеккә баланы салып мамайдан[3] тақмақ әйттергәннәр. Мамай баланың атасын мақтый, абасын[4] мақтый, икөн абасын[5] мақтый, қәйенбикәсен[6] мақтый. Йефәктән чыбылдық қороп мамайдан тақмақ әйттерәләр.

«Бәхетле бала туды,
Батыр булып үс,
Матур булып үс,
Атайың йахшы,
Анайың йахшы», — ди.

---

[1] қуншы — күрше
[2] кийет — бүләк итеп бирелә торган тукыма
[3] мамай — кендек әби
[4] аба — әни
[5] икөн аба — әби
[6] қәйенбикә — иренең апасы

Баланың бишегенә манит[1] салалар. Түрдә утырған хатын бишекнең тишегеннән бавырсақ бирә.

— *Бишек туйына* баланың өстенә җиде йағалы кийем йапқаннар, җиде кешенең җиде йағалы кийемен йабаты икән. «Йақшы булсын, әрү[2] булсын, йақшы кешеләрдән үрнәк алсын, қалыққа җақшы булсын, сау булсын», — ди — *әстр.*

### Биби чәйе, бәбәй чәйе

**Биби чәйе** *кас., баст.*, **бәби чәйе** *т.я.*, **бәбәй цә**йе *срг.* бала туу хөрмәтенә уздырыла торган чәй мәҗлесе.

— *Биби чәйе* җыйалар бала ту'ач. Бар да бәлеш белин 'илилир ту'ан 'ардашлары. Бар да эчми'и 'илилир. Малый'а ыштан, 'үли', 'оз'а шулай 'үли', ыштан 'итери. Үзенең дәдәләрен[3], йадашлары[4] булсын, бар да 'илилир. Монда әбиләрне дә җыйалар — *кас.*

— Бала туса күрше хатыннары бөтен бәлеш белән 'илилир *биби чәйенә*. «Бәлеш белин 'илим, 'аршы да чы'майсыз», — дилир. Бөтен бәлешне 'ис'илилир — *кас.*

— *Биби чәйе* эчмә җыйа қайсы кеше берәр айдан сун. Зур итәйдәр баланы. Қайсы сабын, қайсы күләк китерә. Қатлама, күмәч китерә, бәлеш китерә — *баст.*

— Хуҗа кеше *бәби чәйе* үткәрә. *Бәби бәлеше* дип бәлеш пешереп киләләр чәй үткәргән көнне — *т.я.-трх.*

— Кечкенә малай аwырый да аwырый. Күремче әйтә: «Сез бу малайға *бәби чәйе* дә җыймаған, бәби мунчасы да йасамаған», — ди. Шуннан сун *бәби чәйе* дә, бәби мунчасы да йасадық. Малай майға салған кебек булды.

*Бәби чәйендә* шул мунча кереп чығалар да чәй эчәләр инде. Самаwырны қайнатып торасың. Күп кеше килә, йегермеләп кеше була. Мунчаға керә бара, чығып чәй эчә бара, қайтып китә бара. Қабартма, җуқа була, қош телләре, итле аш була.

Күчтәнәч алып киләләр *бәби чәйенә* килгәндә — *т.я.-к.т.*

---

[1] манит [рус. монета] — тәңкәле акча

[2] әрү — ару, яхшы

[3] дәдә — ир туган, абый

[4] йадаш — кыз туган, сеңел

— *Бәбәй цәйенә* қарцықларны җыйалар. Табын да әзерлиләр, мунча да җағалар. Бөтенесе күчтәнәч беләк киләләр биби чәйенә. Берсе чумара пешереп китергән, берсе сумса китергән.

*Бәби ашы* дип қызыл эскәтергә төреп китерәләр ийе қабартма, җуқалар — *т.я.-к.т.*

— *Бәбәй цәйенә* китерә адийал, йастык, мендәр. Ике көнме йийа, бер көнме йийа. Кем мендәр китерә, мендәргә кемеш кади пыцмагына. «Кемеш кебек йалтырап торсын», — дип.

— *Бәбәй цәйенә* китерәләр, цүлмәк белән цумар, шуның кәтле цумарлар катыкка салган. Кайберләре китерә күмәцләр, кайберләре сайук[1] китерә, аг икмәк магазиндан. Бутка да китерәләр. Кем нәрсә тели, шуны китерәләр — *срг.*

## Бәби хәйерләтү

**Бәби хәйерләтү** *эстр.* бәби туйы.

— *Бәби хәйерләтү* дип, *бәби хәйерлегә* дип киләләр, қорән уқытабыз, туған-тохомны чақырабыз.

— «Хәйерле булсын, озын ғомерле булсын», — диләр. Бәбиләрне, оныкларны күп күрдем.

— *Бәби хәйерләтү* диләр, туған-тума[2] җыйыла, кийетләр, кийемнәр алып киләләр балаға. Бәлешләр, қатланчықлар[3] пешә.

— Бала туғач:

«Хәйерле булсын оныгыгыз», — дип киләләр. Малай туса:

«Батырыгыз хәйерле булсын», — дип киләләр. Қыз туса:

«Қызыгыз хәйерле булсын», — дип киләләр.

Бәби хәйерләтүгә **баwырсақ, балды йау** пешерәләр. **Йау, йаг** — борынгы телдә май.

— *Баwырсақ* пешереп, аның *эченә* салалар *балды йау*. *Балды йау* дип йомырқаны атлыйсың шикәр белән, ул күперә. Шуны тақийа баwырсақ[4] эченә саласың, эче чоқыр була тақийа баwырсақның. Шул *баwырсақ белән балды йауны* биреп җибәрәләр.

---

[1] сайук [рус. сайка] — кечкенә булка

[2] туған-тума — туган-тумача

[3] қатланчық — катлы бәлеш

[4] тақийа баwырсақ — түбәтәй формалы бавырсак

## Бәбәй котлашма килү

**Бәбәй котлашма килү** *нокр.*, **бәбей котлачклама килү** *глз.* бәби котларга бару.

— Чакырмайчы пирбуй *котлашма* киләләр, кем тәбәгый, кем чепчеги[1] китерә — *нокр.*

— *Бәбей* тугач пирбуй чакырмайчы *котлачклама*[2] баралар, кемнең нәрсәгә кәле йетә, бәлиш илтесин, күлмәг-иштан илтесин, балалар булгачын шулай — *глз.*

## Кытлачкон

**Кытлачкон** *[удм.] глз.* бәбәй котлау.

— *Кытлачкон* дилэр, ипи ил'тып баргаладылар, мындар, йурган. Кем йакыны бар, насылы-тамыры бар да ипи был'ан кила, пышырынып кила.

## Бала кыртлау

**Бала кыртлау** *миш.д.* бала котлау, бүләкләр китерү.

— Кыз анасы *бала кыртлап* мендәр, йурганнар китерә, мендәрнең пыцмагына көмеш кади. «Көмеш кебек йалтырап торсыннар», — дип — *срг.*

## Пала қотлоқ

**Пала қотлоқ** *төм.* бәби котлау.

— Перенце палаға *пала қотлоққо* киләте. Пөтөн туған-қардәше, йәше-қарты киләте.

## Нәнә қотлоқ

**Нәнә қотлоқ** *төм.* бәби котлау.

— Нәнә қотлоққа кем кеше көйләген апкерәте балаға, кем кеше йәйгелекләр[3] апкерәте. Хәлле хәленцә.

## Тәпәй йуу

**Тәпәй йуу** *к.-уф.* бала туу хөрмәтенә оештырылган мәҗлес.

— Тәпәй йуwарға дип тә чақыралар дусларын, күршеләрен.

---

[1] чепчеги — чәкчәк
[2] котлачклама — котларга
[3] йәйгелек — бала чүпрәге

## Бәбәй үстерү

**Бәбәй үстерү** *чст.* бәби туе.

— *Бәбәй үстерү* диләр бездә.

— Килен бәбәйләгән йә мунцада, йә бер өйдә.

— Кызның әнисе әби кеше китергән балага кецкенә күпцек[1].

— *Бәбәй үстереп* киләбез дип сүлибез әле дә. Бу йола һаман да саклана. Бәбәй үстерегә киләбез дип *бәбәй кимагы*[2] да пешереп киләләр — *чст.*

## Кечтинә

**Кечтинә** — керәшен сөйләшләрендә бәби туйын шулай дип атыйлар.

— *Кечтинәдә* калык күп зыйыла, бүләкләр китерәләр. *Кечтинә* — бәби туйы була. Кум-кумалар булып ыру-тамыр килгән. Казыр бик зурлыйлар бит инде. Җырлыйлар ыйы, багытлы булсын балалар дип — *каз.ар-крш.*

— *Кечтинәгә* шул бирнә белән киләләр, элгәре басма салган кечтей генә — *чст.-крш.*

— *Кечтинә* диләр, чуқындырыйқ диләр. Ырита белән Ычтапан җанағам киттеләр Әлмәткә, аш-сулар алып қайтырға. Кечтинә йасадық, чуқындырдық — *т.кам.-крш.*

## Кричтинә

**Кричтинә** [рус. кристины] *т.я.-крш.* христиан дине йоласы буенча баланы чукындыру йоласы.

— *Кричтинә* бүген, анда барабыз дип баралар. Йоморы икмәк кебек *чыгыт*[3] *пешерәбез*. Бала тугистан чыгыт башламаллы. Чукындырып кайткистан шал *чыгытны* барына да өләшеп чыгалар. Чыгытын да, калачын да турый да бирә кеше сайын берәр кисәк ызбадагы кешегә бөтенесенә дә биреп чыга.

«Бала йылый да йылый, син чыгыт башлаганмы әле балага», — диләр.

---

[1] күпцек — кечкенә мендәр

[2] бәбәй кимагы — бәбәй котлап китерелгән коймак

[3] чыгыт — икмәк кебек әвәләп мичтә пешерелгән эремчек

## БИШЕК

**Бишек** — яшь баланы тирбәтеп йоклату өчен махсус җайланып эшләнгән асма ятак яки йоклау урыны. Җирле сөйләшләрдә *бишек* сүзенең күп кенә лексик вариантлары билгеле: *бәллү, сәли, цәңгелцәк, чәңгелчәк, шәлтеп* һ.б.

**Бишек** *урт.д., мишәр диалекты* сөйләшләрендә:

— Ыршы ағастан йасаған *бишек* ийе, сүрә йағына[1] киндер тегәләр қаты булмасқа.

— Ике килен була, *бишек* пич арасында була. Олан[2] йылый, оланны таба алмый. Дүрт айакланып эзлимен дир, бишектә дә йук оланым, дир. Он эценә салып куйган йилпуцына[3] йокы арасында. Әле дә тора ул катын. Ызбабыз[4] кецкенә, дир. Кыцкырып атергә йакшысынмим, кан'агам[5] бар, дир. Ирем ат'а, нәг оланны алмисын бишектән, дир — *срг.*

— *Бишеккә* салып тирбәтәләр. Астан теккән астар, аны элгән гузга[6], кулчага[7] инде, путалакка[8]. Шуны тирбәтәләр — *мәл.*

— *Бишекне* эләләр путалакка. Дүрт җепне кучалилар[9] да эләләр крукка[10] путалактагы — *хвл.*

— Путалакка кулча йасаганнар, шыл кулчага йасаганнар ыргак. Бишегенең дүрт йагына да таза йепләр бәләгән. Шында ылан йокли рәхәтләнеп — *влгг.*

## Бишек астылык

**Бишек астылық** *нокр.* бишек төбенә салу өчен әзерләнгән киез.

— *Бишек астылық* дип олан туғачын нәсел-тамырларыннан кем ни китерә.

---

[1] сүрә йағы — тирә ягы
[2] олан — бала
[3] йилпуц — җилпуч
[4] ызба — өй
[5] кан'ага — иренең абыйсы
[6] гуз [рус. гвоздь] — кадак
[7] кулча [рус. кольцо] — боҗра
[8] путалак [рус. потолок] — түшәм
[9] кучали [рус. куча+ -ли] — бергә төенли
[10] крук [рус. крюк] — ыргак

## Бишек баwы

**Бишек баwы** *урт.д., миш.д.*:

— Балаға күз тисә, бишек бауларын чайқап арқасына сөртәләр — *эстр.*

## Бишек бирнәсе

**Бишек бирнәсе** *нокр.* бәби котлап китерелгән бүләкләр, бала әйберләре.

— Беренче бала булғач қыз анасы, дағын қызалдычылар[1] *бишек бирнэсе* китэрэлэр. Ыштан, бабайға[2] күлмәк, чүпрәк, йурған, чыбылдық, бишек астылық, көрпә, матрас, мәләкәй[3] китерэ.

— *Бишек бирнэсе* китерэлэр. Бишеккә чаршаулар, йурған, чыбылдықлар, күлмэкләр китерэлэр, қазан кукыл[4] китерэлэр.

## Бишек фәрдә, бишек саршау

**Бишек фәрдә, бишек саршау** *к.-уф.*, **бишек чаршау** *минз.* бишек чаршавы.

— Бишеккә *фәрдә* қороп қуйалар ыйы — *к.-уф.*

— *Бишек саршау* булды электә — *к.-уф.*

— *Бишек чаршаwын* бала итәкләп тегеп қуйдылар — *минз.*

## Бишек бөгәлҗәсе

**Бишек бөгәлҗәсе** *т.я.-трх.* бишеккә өстән дугасыман итеп ясап беркетелгән чыбык, өстән чыбылдык япканда уңайлы була.

— *Бишеккә* чики (чикләвек) чыбыгыннан *бөгәлҗә* йасаған була. Қабық бишек, *бөгәлҗә* өстеннән бөркәү җабыла.

## Бишек бөркәwе

**Бишек бөркәwе** *т.я.-трх.* бишек чаршавы.

— Бишеккә бишек бөркәwе җабалар. Малай тыныч йоклый, чебен килми, суык җилләр тими.

---

[1] қызалдычы — туйга кызны озатып килүче

[2] бабай — бәбәй

[3] мәләкәй — мендәр

[4] қазан кукыл — пилмән

## Бишек чыбылдығы

**Бишек чыбылдығы** *әстр., т.я.-к.т.:*

— *Бишеккә* йефәктән *чыбылдық* қороп қуйатылар. Бишек туйына туған-тохомны чақыратылар — *әстр.*

Қабық бишеккә чыбылдық қороп қуйалар чебен кермәскә. Бик тыныч җоқлый анда малайлар — *т.я.-к.т.*

**Чымылдық қорған бишек** *әстр.:*

Чымылдық қорған бишек
Айрылмабыз дигән идек,
Айрылдық менә ничек, —

дип җырладылар әзилдә[1].

## Бишек җыры

**Бишек җыры** — бишектәге баланы тирбәтеп йоклатканда, юатканда җырлана торган җыр (көй).

Мин яшәрмен әкиятләрдә,
Аналарның бишек җырында.
Ә. Ерикәй.

**Бишек җыры** — әстерхан сөйләшеннән язып алынган сүзләр китерелә:

— Бишек җыры җырлый бала баққан кеше.

Әлли-бәлли ақ балам,
Ақ бозауды бақ балам.
Ақ бозауды бақмасаң
Сиңа қаймақ җуқ балам,

дип тирбәтә.

Йөгерә-йөгерә йөргәндә
Тәбәнәк қурай кермәсен.
Кечкентәй генә қызыма
Қалықтың күзе тимәсен.

Әйдәче, балам, әйдәче
Җоқодан қайчан торасы.

[1] әзилдә — элек

Җаз тимәсә қыш тийәр
Шушы балам пайдасы.

Бийесен балам бийесен,
Биленә чәчәк қыйылсын.
Бийемәгән җегетләрнең
Җилкә чәче қыйылсын.

Минем балам бийеп тоу,
Махмал[1] күлмәк кийеп тоу.
Матур қызлар күреп тоу,
Җанына килеп күреп тоу.

Минем балам қайдикән, қайдикән,
Ат чаптырған туйдикән, туйдикән.
Минем балам қайдикән, қайдикән
Қызлар белән туйдикән, туйдикән.

Туйда булса утырсын, утырсын
Қулына йөзек тутырсын, тутырсын.
Саратский саз[2] алып, саз алып
Қызлар белән қыдырсын[3], қыдырсын...

Һәйди-һәйди һәйдәсе, һәйдәсе
Қайчан тийәр файдасы, файдасы.
Йаз тимәсә қыш тийәр, қыш тийәр
Шушы балам файдасы, файдасы.
Тиздән тийәр файдасы, файдасы,
Йегет қызға йалнасы, йалнасы.

Қызым, қызым қыз дана,
Қызыма килер йөз дана.
Иллүwен үзем ашармын
Иллүwен қызыма йасармын.

Йөз манит[4] килсә, илле манитын үзем ашармын, илле манитына пыридан[5] йасармын дигән сүз булады.

---

[1] махмал — бәрхет
[2] саратский саз — саратов гармуны
[3] қыдырсын — йөрсен, уйнасын.
[4] манит [рус. монета] — акча
[5] пыридан [рус. приданое] — бирнә

Минем балам туыпты,
Ал күлмəген җуыпты,
Арысқа[1] элеп салыпты,
Қанның улы күрепте,
Башын чайқап китепте.

Җарлы қызы күрепте
Җылап-җылап китепте.

Йылама балам, йылама
Йелек чабып бирийем.
Қалаға киткəн абаңды[2]
Қайдан табып бирийем.

Йоқла, балам, йоқлачы,
Йортым тулы эшлəрем бар
Эшемне қалдырмачы.

Абасы қалаға мадур[3] сатарға китепте, мин менə бала бағып утырамын. Əзилдəге[4] җырлар бу, йəшлəр белми.

**Бишек җыры** — сергач сөйлəшендə:
— Бишекне селкетəлəр такмаклап.

Йылама, балам, йылама,
Йылы катык сорама.
Йылы катык пицтə
Анаң килер кицкə.

Аналары китə выт' кырга уракка.

Тедер-тедер дудкасы
Пешер арыж буткасын.
Ашасын да кикерсен
Цитəн аша сикерсен.

Батыр булып, таза булып үссен дир.

Ал'у, бал'у итəр бу
Мəдрəсəгə китəр бу.

---

[1] арыс — арба тəртəсе
[2] аба — əни
[3] мадур [рус. помидор] — помидор
[4] əзилдəге — борынгы

Мәдрәсәдә укыгацтын
Мулла булып йитәр бу. —

дип тирбәтәләр дә кү белән йокыга китә.

Йокла, балам,
Йом күзең,
Хайырлы булсын сүзең — *срг.*

**Бишек җыры** — Волгоград сөйләшендә:

Йылаwык бала була, үскенче йыли. Мин йарты төн багам. Күләп, йырлап утырам.

Аллаһу, аллаһу
Алла әйтер бала бу.
Алла әйтеп йөргәннәр
Ким-хур булмас аллаһу.

Куйаннар, куйаннар
Йогорошып уйнарлар
Тал төбөндә тонок су
Тонып-тонып эчәрләр.

Ал'и-бал'и бау итә,
Балам йокыга китә.

Куйан килгән кабакка
Баламны чакыра сабакка.
Балам әтә барамын,
Әби әтә калмимын.

Ак куйаннар,
Ак куйаннар,
Йаталар мижада
Ир балалар,
Ир балалар,
Йарилар нужага.

Кыз балалар,
Кыз балалар,
Жар чабалар мунчада.

Ал'и-бал'и бау итә,
Балам йокыга китә.

Улым бара сабакка
Айагында чабата.
Килешәме, ан'икай,
Бик килешә, балакай.

Ал'и-бал'и бау итә,
Балам йокыга китә.

## Бишек җырында һәм баланы тирбәткәндә әйтелә торган сүзләр [ТТАС]:

**Бәлли** — кабатлап яки «әлли», «бәү» һ.б.ш. сүзләр белән аралаш, бәбине йоклату өчен көйләп тирбәткәндә әйтелә. — шаян кызым син минем, Таң йолдызым син минем. Йоклыйк әле без икәү, Әлли-бәлли, бәлли бәү. Н. Исәнбәт. Йокла, балам, йокла син, Бәлли-бәү, бәлли-бәү. Т. Гыйззәт.

**Бәлли итү** — 1. «бәлли-бәлли» дип, көйләп тирбәтү. — Әлли итеп ал үскән, Бәлли итеп гөл үскән. Н. Исәнбәт; 2. Йоклау (көйләп тирбәтелүче бәби турында). — Әлли-бәлли итәр бу, Бохарага китәр бу. Г. Тукай.

**Бәллиләү** — «бәлли» һ.б.ш. сүзләрне әйтеп көйләп тирбәтү (бәбине). — Бай, бай, бай ... дип сузып бәллили иде ана. Ә. Айдар.

**Бәллү** — 1. Кабатлап яки «әллү», «бәү» һ.б.ш. сүзләр белән аралаш,бәбине йоклату өчен көйләп тирбәткәндә әйтелә. — Син еларга башласаң, чү-чү, балам, чү-чү дигән; Тирбәтеп, көйләп кенә, Әллү дигән, бәллү дигән. М. Гафури; 2. Бишек. — бала елый иде бәллүдә. Н. Баян.

**Бәллүки** к. бәллү 1. Бәбине йоклату өчен көйләп тирбәткәндә әйтелә. — Әлли-бәлли, бәпкәм, бәллүки; Көйлим икән сиңа нинди көй? М. Җәлил.

**Бәллүләү** — «бәллү» һ.б.ш. сүзләр белән көйләп тирбәтү.

**Бәү** — кабатлап яки «бәүки», «бәлли» һ.б. сүзләр белән аралаш бәбине йоклату өчен көйләп тирбәткәндә әйтелә. — Йокла, йокла, бәү-бәү (бәү-бәү дип бишекне селкетә башлады). Г. Иделле. Бик нәни кыз әле Диләрә, йоклый ул әлли, бәү дигәнгә. Ә. Бикчәнтәева.

**Бәү итү** — 1. шул сүзләр белән көйләп тирбәтү (бәбине); 2. йоклау (көйләп тирбәтелүче бәби турында). — Бәү-бәү итеп, күз йомып, Изрәп кенә китәр ул. К. Әмири.

**Бәүки** — к. бәү. — Әлли-бәлли, бәүки, җан кисәк! Тыныч йокла тагын бик озак. М. Җәлил.

**Әлли-бәлли** — бала йоклатканда әйтелә; бишек җырының кушымтасы. — Әлли-бәлли, бәбкәем, хәзер кайтыр әткәең.

**Әллү-бәллү** — к. әлли-бәлли. — Әллү-бәллү итәр бу, Мәдрәсәгә китәр бу. Г. Тукай.

## Әү итү

**Әү итү** *бараба.* бала юату.

— Кәбән төбендә утырайдым мин бала бағып. Олу бала булдым. Әлли-бәлли әйтеп, *әү итеп* утырайдық.

## Ырғау

**Ырғау** *төм.* бала тирбәтү.

— Қартым ырғайтыған баланы. Минеке балам сықтақ[1] пулған, алты айына цақлы сықтаған[2]. Сәлтепкә[3] салып әү итәтләр баланы.

## Баланы бишеккә салу

Әстерхан сөйләшендә баланы бишеккә салу бишек туйы йолалары белән үрелеп бара, борынгыдан килгән ырымнар, йолалар һәм йола сүзләре түбәндәге этнодиалектологик текстларда, мәгълуматларда чагылыш таба.

**Бишеккә салу** *срг.:*

— Бәбәйне бишеккә пирбуй салганда **айaтелкөрси укып** салалар иде. Шылай пирбуй салуга айaтелкөрси кирәк. «Шайтаннан сакласын» дир.

— Бәбәйне бишеккә салуцыга садака бирәләр иде, кан'ан'аңмы сала, кан'игәцеңме сала бишеккә. **Ир йагы сала** оланны бишеккә.

---

[1] сықтақ — елак

[2] сықтаған — елаган

[3] сәлтеп — бишек

**Бишек туйы йасау һәм баланы бишеккә салу** *әстр.:*

— *Баланы бишеккә* салады, тустақайдағы[1] баwырсақны бишекнең тишегенә салып ике кимпергә[2] бирәде, ике йақның анасына өшкереп. Шул баwырсақны тустақай белән тотып барысына да өләшәде. Шул *бишек туйы* дип аталады.

— Бишек туйында йефәктән чыбылдық қорып мамайдан тақмақ әйттергәннәр. «Бәхетле бала туды, батыр булып үс, матур булып үс, атайың йахшы, анайың йахшы», — ди. Баланың бишегенә манит салалар. Түрдә утырган хатын *бишекнең* тишегеннән баwырсақ бирә.

— Баланы *бишеккә* сала, тирес[3] йағына сала. «Тиресме, уңмы?» — дип сорый *бишеккә* салған кеше. Өч кат сорый. Тирес, ди. Соңғы қатында уң ди.

— Баланы *бишеккә* салу бар. Ат қушайды ғуй. Баwырсақ пешерәделәр. Wақ-wақ итеп қаталақ баwырсақ[4] пешерәйделер зур шара табақ[5] белән. Шуның эченә канфит қушады, пичинйә қушады.

Әйесе[6] йегетнең бишекне әкилеп, баланы салып, тустақай шарадағы баwырсақны әкилеп қуйады. Баланы бишеккә салады. *Бишеккә* салғанда «уңмы, тиресме?» — дип қычқырады. Бер кәрәм[7] «тирес» дип қычқырадылар, икенче кәрәм «тирес» дип қычқырадылар, өченче салғанда «уң» дип қычқырадылар.

**Баланы бишеккә салганда «тычтыма» дип вак бавырсаклар өләшү** *әстр.:*

— Бәбәй хәйерләтәләр дә аннан суң тычтыма йасыйлар.

«Тычтыма, тычтыма» дип бер тустақай белән тычтыма өләштерә, wақ баwырсақ. Ул баwырсақны бишекнең тишегеннән бирәтеләр. «Бәбәй тычып йатыр» дип. Баwырсақтай[8], арихтай[9] итеп майға салып пешерәләр.

---

[1] тустақай — касә, чынаяк
[2] кимпер — хатын
[3] тирес — кире, тискәре
[4] қаталақ баwырсақ — вак бавырсаклар
[5] шара табақ — зур агач табак
[6] әйесе — әнисе
[7] бер кәрәм — бер тапкыр
[8] баwырсақтай — бавырсак кебек
[9] арихтай [рус. орех + -тай] — чикләвек кебек

«Тиресме, уңмы» ди, баланы салғанда, өч мәртәбә сорый җиңгә. «Уң, уң» ди, баланы бишеккә сала. Ақча ташлыйлар, «күремнек»[1] дип, бишекне тутыралар, җабулар[2] җабалар.

**Бишек туйында баланың өстенә кием йабу** *эстр.:*

— *Бишек туйында* баланың өстенә җиде йағалы кийем йапқаннар, җиде кешенең җиде йағалы кийемен йабаты икән.

«Йақшы булсын, әрү булсын, йақшы кешеләрдән үрнәк алсын, қалыққа йақшы булсын, сау булсын».

Берәү арқалығын[3], берәү қапталын[4], берәү күлиген[5] салады.

*Бишек туйына* қыз анасы үзенең бөтен булған туған-тохомын җыйып килә. Бәбәйгә кийем килә, пылау пешерәсен, кийет бирәсен. Бишеккә баланы салып мамайдан тақмақ әйттергәннәр. Мамай баланың атасын мақтый, абасын[356] мақтый, икөн абасын[7] мақтый, қәйенбикәсен мақтый.

— Бала туса *бишек туйы* йасыйлар, бәбәй туйы инде. *Бишек туй* дип атасы-анасы киләде. Урамаға, йабынмаға йурғанын алып киләде қызның анасы — *эстр.*

## БИШЕК ТӨРЛӘРЕ ҺӘМ АТАМАЛАРЫ

### Ал бишек

**Ал бишек** — халык җырларында искә алына:

Әлли-бәлли итәргә
Ал бишеге бар аның;
Йылағанда йуwатырға
Үз әбкәсе бар аның.

Ал бишеге бар аның,
Гөл бишеге бар аның.
Тәрбийәләп үстерергә
Үз әнкәсе бар аның.

---

[1] күремнек — күрү бүләге
[2] җабу — өстенә ябу өчен дип китерелгән киемнәр һ.б.
[3] арқалық — камзул
[4] қаптал — өске кием, бишмәт
[5] күлик — күлмәк
[6] аба — әни
[7] икөн аба — әби

## Ат бишек

**Ат бишек** *әстр.* идәнгә куйып атындыра торган бишек, балага исем кушканда шул бишеккә салалар.

— Килен кеше алып баланы *ат бишеккә* қуйа, өстенә җиде қат кийемне йабалар, бер чара[1] баwырсақ өләшәләр.

— *Ат бишекнең* төбе тишек булады әзилдә. *Ат бишекнең* төбенә җылы көл саладылар, қоросын салып торадылар. Түшәге қоро торады баланың.

«И аллам, маған биргән балам булсын,

Қодай биргән балам булсын», — дип әйтәде.

## Алтын бишек

**Алтын бишек** *глз.* җен-зәхмәттән, күз тигәннән имләгәндә әйтелә.

Алтын тауда алтын өй,
Алтын өйдә алтын сөрмә.
Алтын сөрмәдә алтын бишек,
Алтын бишектә Нәсимә...

## Алтын бишек, қабық бишек

**Алтын бишек, қабық бишек** — керәшен сөйлшләрендә борынгы йола җырларында искә алына:

Безнең уллар туғанда
*Алтын бишек* асқанда...
Сезнең қызлар туғанда
*Қабық бишек* асқанда...

## Әр бишек

**Әр бишек** — тау ягы керәшеннәре сөйләшендә:

— *Әр бишек* — җүкәдән җүләгән[2] бишек. Кызны йылатканда туйда җырлаганнар болый дип:

Әнкәй, мине тапкистан
*Әр бишеккә* ник салдын.
*Әр бишектән* алгистан
Җиде йатка ник саттын.

---

[1] чара — зур табак

[2] җүләгән — тегеп ясалган

## Кабык бишек, такта бишек

**Кабык бишек, такта бишек** *чст., т.я.:*
— Элгәре *кабык бишек, такта бишек* була иде.

**Сиртмә:** шымырт сиртмәгә элә бишекне.
— Элеке заманда бер ызба ийе бит инде, шында шымырт сиртмә белән *кабык бишек* аскан — *чст.*
— Җүкә ағачының қабығын әйләндереп төшерәләр дә шул қабықтан бишек җасыйлар ыйы. Шул бишекнең төбенә салам җәйәләр ийе, аның төбен киндерә белән үргән буладырыйы. Баш астында мендәр астында йасин торадырыйы. Мәләш ағачыннан кисеп сикертмә җасыйлар ыйы, шул сикертмәгә бишекне асып бәби тирбәтү ийе. Қабық бишек ул җиңгел буладырыйы, бик җайлы буладырыйы — *т.я.-к.т.*
— Безнең әти қабық бишек эшләдейе. Аның төбенә шалама салған, баш очына мендәр салған. Җүкә қабығыннан бишек, аны сикертмәгә элгән. Бүлем башына тыгып қуйалар сикертмәне дә селкетәләр бишекне. Шулай җүкә қабығыннан җасыйлар ыйы бишекне — *т.я.-к.т.*

**Цыбылдык:** цебен-церки тимәстән, кеше күзе төшмәстән баланың бишегенә цыбылдык теккәннәр. Тукыган киндердән булган ул — *чст.*
— Бишекне җүкә қабығыннан җасыйлар. Бишеккә салып очыртып-очыртып тирбәтәбез малайны — *т.я.-к.т.*
— Йүкә агацының кайырысыннан бишек эшләгәннәр. Аның дүрт цитенә йепләр бәлиләр, аннан йепле ыргакны путалактагы бер шипкә эләләр. Бишеккә коргоц коралар, цыбылдык диләр — *срг.*

## Тал бишек

**Тал бишек** *к.-уф., минз.* тал чыбыгыннан үреп ясалган бишек.
— *Тал бишек* булайы элек. Туза ул тал бишек. Аны биг ыспай итеп үрә торғаннар ыйы. Ақ тал бишекләр үрделәр — *минз.*
— Бишекне бау белән пуржинәгә элеп қуйабыз, тал сыбықтан үрәбез бишекне — *к.-уф.*

**Тал бишек үрүче** *минз.*:

— *Тал бишек үрүчеләр* күп булды. Сыйык̡ тал чыбыгын бөгеп бишек үрәләр. Тал бит монда ғына, күп үсә.

Менә Иманғали абдый бишек үрүче булды. И матур итеп үрерләр ийе тал бишекне.

Тал чыбығының беразын қайызларлар ыйы, беразын қайызламаслар ыйы. Ансы җәм-җәшел булып торор ыйы, и матур булып торор ыйы ул.

Шулай тал чыбығыннан үрелгән бишек эләрләр ийе, менә шулай бәләкәй божрағa эләрләр ийе. Бed ике баланы да тал бишектә үстердек.

Тал бишеккә чаршау йасадылар бәбәй итәкләп. Шулай бишек чаршаwы булыр ыйы чебен тимәскә — *минз.*

## Тигәнә бишек

**Тигәнә бишек** *влгг.* җиргә, арбага кую өчен агачтан тагарак сыман ясалган бишек.

— Әбийем көлтә бәләгәндә тигәнә кебек итеп йасаган бишеккә салганнар оланны. Ул *тигәнә бишек* арба өстендә торган эстиптә. Шыл тигәнә бишектә атындырганнар оланны.

— *Тигәнә бишек,* бишек өстенә коргоч корган, коргоч астында йокли олан.

## Җил бишек

**Җил бишек** *эстр.* дүрт агачка тукыма тегеп ясалган бишек.

— *Җил бишек*, дип дүрт ағачқа мата[1] тегәде. Чебелдек қоралар матадан, дүрт мийесенә[2] җеп бәйлиләр дә пыржинаға эләдләр.

— *Җил бишеккә* салады баланы, җоқлағанда бишеккә чыбылдық йабып қуйады. Аwырмайды да бала. Имезә, кире сала. «Баланың арқасы арған булыр, алығыз бишектән», — диделәр.

— *Җил бишек* диде. Дүрт җеп белән чөйгә элеп қуйды. Мата тегәде җилбишеккә, кечкентәй түшәк сала бишеккә. Баш астына әптийәк[3] сала, атның тағасын сала бишеккә.

---

[1] мата — тукыма

[2] мийес — почмак

[3] әптийәк — әфтияк, изге китап. Коръәннең җидедән бер өлеше.

### Цәпе бишек

**Цәпе бишек** *срг.* тукымадан тегеп ясалган бишек.

— Бездә цәпедән эшләгән бишек булды. Путалакка элгән бишекне.

### Бәллү

**Бәллү** *минз., бараба, төм.* бишек.

**Қабық бәллү** *минз.* юкә кабыгыннан ясалган бишек. — *Қабық бәллү* йасап бирде ақ бабай.

**Артыш бәллү** *бараба.* артыш агачыннан ясалган бишек. — *Артыш бәллүдә* баланы йоқлатқалы йақшы, тыныч була.

### Сәли

**Сәли** *к.-уф., перм.* бишек.

— *Сәлигә* салып тирбәткәннәр уланны[1], дүрт мүгешенә бау тағалар да *сәлине* эләләр. Киндердән теккән *сәли* була, *сәли* ағачқа элә — *перм.*

## СӘЛТЕП, ШӘЛТЕП

**Сәлтеп, шәлтеп** *себ.* бишек.

— *Шәлтепкә* салып ырғаған[2] паланы. Түрт тайақ йантаған та аңа мал[3] теккән. *Шәлтеп* тип атала. *Шәлтепкә* тоғалық[4] элеп қуйғаннар. Шәлтепне қыраға[5] алып барған, қайынға бәйләп элгән, пецән цапқан, урақ урған.

— *Шәлтеп* тибес. Әнә паулар, қатақлар. *Шәлтепкә* салып ырғаган палаты, *шәлтепкә* йатқысқаннар. *Шәлтепкә* ырғап тирбәтү әйбәт — *тара.*

— *Сәлтепне* күргән булырсың. Песнеңке сәлтебебес булған, үсләре бала асрауны қуйғач күршегә биргәннәр.

---

[1] улан — бала
[2] ырғаған — тирбәткән
[3] мал — тукыма
[4] тоғалық — догалык
[5] қыра — кыр, дала

— Кецкенә бала туған сун *сәлтепне* қуйатлар арғалыққа[1]. Балацық[2] сурайған сун өй башқа[3] салып қуйатлар, қороп йатсын, тип. Ул *сәлтепне* күршеләренә тә биреп торатлар, йә үс балаларына та кәрәк булаты. Шалай йөри иде ул аwыл буйлап.

### Шәлтеп бөркәwе

**Шәлтеп бөркәwе** *туб.* бишек бөркәве.

— Шәлтеп бөркәwен қороп қуйатылар:

«Балага кеше күсенең уқлары төшмәскә».

### Сәлтеп пау, шәлтеп пау

**Сәлтеп пау, шәлтеп пау** *себ.* бишек бавы.

— Сәлтеп пауларынта туwалықлар пулаты. Шайтан алыштырмасын нараситаны. Йаман ченнәр булған.

Шәлтепнеке түрт мөйөшенә түрт бау булған, осон бау. Шәлтепне күргәнме син? Шалай баулары әлүле. Пы мөйөшеннән бау, пы мөйөшеннән пау. Аны осонорақ итеп пыружинаға элеп қуйатылар, тирбәтәтеләр.

«Ишек йегеннән йел-қус керәте,
ишек турыға элмәң шәлтепне»

тип әйтәтеләр.

**Сәлтеп, шәлтеп пауға айу тырнағы элеп қуйу** *туб.:*

— Айу тырнақны шәлтеп паwына, түрт паwына да тағып қуйатылар.

«Йел-шайтаннар килмәсен».

— Атып айуны алып қайтатылар, айуның тырнағын алатылар, шәлтеп баwына элеп қуйатылар. Аны икене алатылар, шәлтепнеке асты йағына баwына элеп қуйатылар.

«Йел килмәйте», — тип.

Томар эценә тығып тегәтеләр айу тырнақны.

**Сәлтепкә туалық (догалык) элеп кую** *төм.:*

— Сәлтеп башына тегеп қуйатылар туалықлар тесүле. Йасдырып алатылар туалықны. Сәлтеп итәккә туwалар кирәк,

---

[1] арғалық — матча

[2] балацық — кечкенә бала

[3] өй баш — чорма

тиделәр. Сур туалықларны әйбәт маллар белән тышлап қуйатылар. Тораты сәлтептә алай.

**Сәлтепне артыш ағачыннан йасау** *тәм.:*

— Сәлтепне түрт йақ мөйөшеннән[1] бәйләп, артыш ағацтан йасаған. Артышқа сәхмәт килмәйте. Песнеке сәлтеп әлүле көйөнцә тора әле кәсәнкәдә[2].

**Сәлтепне артыш йандырып төтәтү:**

— Артыш ағачын йуwынаты, йуwынаты да аны учақта төтәтеп сәлтепнең астыннан, эргәләреннән төтәтеп чығады ғыйлемдар қортқайақ:

«Йел-шайтаннар килмәсен,
малайны[3] алыштырмасын».

**Сәлтепкә баланың баш астына артыш салып кую** *төм.:*

— Сәлтепкә баланың йастығ астына да артыш салып қуйғаннар:

«Бала тыныч йоқласын».

**Сәлтепкә аруланып кына якын килү** *туб.:*

— Сәлтеп қабатына[4] килмәң, йуынып қына тотының сәлтепкә тиделәр, шалай аруланып қына тотының, тиделәр инәкәләр[5].

## Сәлтеп йыры

**Сәлтеп йыры, пәпә йыры** *төм.* бишек җыры.

— Сәлтеп йырын йырлый бала баққан кеше. Сәлтептә йата бала, пәпә йырларын йырлап утыратылар сәлтеп қырында. Элүле сәлтепләр булаты.

Әлли-бәлли ит улым,
Қарлығацым, пылбылым.
Тыңна минем сүсемне,
Йә, йом, пәғрем күсеңне.

---

[1] мөйөш — почмак
[2] кәсәнкә — бүлмә
[3] малай — бала
[4] қабатына — янына
[5] инәкә — кендек әби

Әлли-бәлли итәрсең,
Үсеп пуйга йетәрсең
Ил сақцысы пуларсың,
Йоқла, улым, йом күсең.

Әлли итсен пы бала,
Бәлли итсен пы бала.
Пы баланы қарай-қарай
Пашың пулыр пумала.

Йоқла, улым, йом күсең.

## СӘҢГЕЛЧӘК, ЧӘҢГЕЛЧӘК, ЦӘҢГЕЛЦӘК

**Цәңгелцәк, чәңгелчәк** *төм.* бишек.

— Сәңгелцәкне кулцага[1] элеп қуйабыс. Қадақ қағабыс та. Сәңгелцәгем әле дә элүле тораты. Аның белән бала үскерү уңай.

— Сәңгелцәкне идән төпкәрәк ултысабыс, бала үсеп китүле булғанда. Үсепес ишегалға, кураға цығып китүле булсақ, алар төшкеләре килсә төшәтеләр, йығылмайтылар.

— Менә кецкенә әйтә паwырсақ пешерәбес. Керсәк, бала сәңгелцәктән төшеп, он сибеп уйнап утыраты алаша[2] өстәл өстендә. Тойоғы белән[3] он, аурақ[4] шикелле утыраты. Тышқа алып цығып йуwындырып керттек.

**Артыш цәңгелцәк** *төм.* артыш агачыннан ясалган бишек; аңа җен-пәриләр килми, дип ышанганнар.

— Артыш ағацтан қыласың цәңгелцәкне. Аңа йел-қус[5] сипелмәйте. Чен-пәриләр[6] кермәсен тип артыш кыстырасың.

— Цәңгелцәк қылдырдым. Артыш агацтан қайным[7] йасап биргәйте.

«Йел-кус килмәсен аңға».

---

[1] кулца [<рус. кольцо] — боҗра
[2] алаша — тәбәнәк
[3] тойоғы белән — баштан-аяк, бөтенләй
[4] аурақ — өрәк
[5] йел-қус — җен-пәри
[6] чен-пәри — җен-пәри
[7] қайным — кайнатам

Артыш агацтан цәңгелцәктә палаға йоқлағалы йақшы — *төм.*

— Артыш сәңгелчәк хәсер йуғ инте, дүрт мийешенә[1] бау бәйләп, астына китән тегеп элеп қуйғаннар.

— Сәңгелцәкнеке йақ-йақларын, башларын артыштан қылтылар. «Артыш сәңгелцәктә бала йарсып китми», — тиделәр.

«Йел-қус, йел-йасмақ артыштан қурыға».

**Сәңгелцәккә айу тырнақларын элеп қуйалар** *тара., том.:*

— Айуның тырнақларын, қуйанның қойрыкларын элгәннәр сәңгелчәккә.

«Бала йылаwын қуйа».

— Айу тырнағы салып қуйалар иде бала астына. Зур айу тырнағы, аны қайан алғаннардыр. Ул баланы сақлый иде аwырудан, шайтаннардан — *том.*

— Бер айу тотқаннар иде, айуны китерделәр аwылға.

«Айуның тырнағын алырға кирәк», — дип қычқырышалар — *том.*

**Сәңгелцәккә туwалар (догалар), пыцақ (пычак) салып қуйалар** *тара.*

— Сәңгелчәккә баланың баш астына туwалар, пыцақ салып қуйалар.

«Шайтаннар килмәсен».

**Цәңгелцәк итәге** *төм.* бишек яны.

— Цәңгелцәккә паланы сала та ырғайты, сықтаса-сықтамаса[2] йататы. Цәңгелцәк итәгентә[3] бер әби йон эрләп кенә, көйләп кенә утырған.

— Талага паланы алып парса, чебен ашамасқа чәңгелчәккә сала, өстөнә чаршау қора, шунда чәңгелчәк итәгентә ырғап утыра паланы.

**Сәңгелцәкне арғалық турға[4] элгәле йарамайты** *туб.*

— Арғалык турға сәңгелцәк элгәле йарамайты, ишек турға сәңгелцәк элгәле йарамайты.

---

[1] мийеш — почмак

[2] сықтаса-сықтамаса — еласа-еламаса

[3] цәңгелцәк итәгентә — бишек янында

[4] арғалық тур — матча турысы

«Йел-ҡус йөреп йататы, антай йергә сәңгелцәкне элмәң», — тип әйтәтеләр.

Аның өцен сәңгелцәкне антай йиргә элмәйбес.

## БИШЕК СИРТМӘЛӘРЕ

### Сиртмә

**Сиртмә** — бишек элеп тирбәтү өчен куелган сыгылмалы нечкә колга. Кабыктан ясап бирделәр безгә дугалы бишек. Миләш сиртмәгә элделәр, бауны юкәдән ишеп. З. Нури.

— Улым, бишеккә *сиртмә* кисеп кайт урманнан. Миләш агачыннан кис. Азлысыннан кисмә, күплесеннән кис. Балалар күп булыр күплесеннән киссән — *каз.ар.-крш.*

— **Сиртмәне ҡайын ағачыннан** йасадылар. Ҡайын сиртмәгә асадыр ыйыҡ бишекне.

Ҡайын сиртмәләрдә үстем,
Шуңа ҡайғылы башым, —

дип җырладылар элек — *минз.*

— **Шымырт сиртмәгә** элә бишекне. Элеке заманда бер ызба ийе бит, шында шымырт сиртмә белән кабык бишек асканнар — *чст.*

— Бүлмә таҡтасы өстенә сығыла торған ағач ҡуйып, **шомыртмы, миләшме,** сиртмә ағачы ҡуйып бишек элдек.

Балаға күз тимәсен дип, күбрәк **миләш сиртмә** ҡуйалар ыйы безнең әниләр.

«Миләш сиртмә ҡуйсаң, имеш, балаға күз тими».

Элек ат тәртәләрен дә **миләш ағачыннан** йасағаннар. «Атҡа күз имәсен», — дип — *минз.*

### Салтма

**Салтма** *м.-кар.* бишек сиртмәсе.

— Бишекне сәндерәгә эләләр, тагып куйалар да салкыталар[1] шуны бәлә, агач була *салтма*. Мәләштән җасилар икән, *мәләш салтма* диләр:

---

[1] салкыта — селкетә

Ал'у бал'у бәбәсе
Мәләш агач *салтмасы.*
Аҗыкасы[1] кайа микән
Җылап тора бәбәсе — *м.-кар.*

### Сикертмә

**Сикертмә** *т.я.-крш., т.я.-трх.* сиртмә.

— *Сикертмә* белән сикерткән бишекне, миләш куйалар күбрәк, озын була, сыгылып тора миләш агачы — *т.я.-крш.*

— Миләш агачыннан алкага элеп куйганнар да ул сәленеп тора шулай, миләш агачы сынмый ул.

*Сикертмәсе* миләштер
Җегетләрне иләштер, —

дип әйтеп селкетә иделәр. Миләш сынми ул, җомшаг ул — *т.я.-крш.*

— Бишекнең ағач **сикертмәсе** була. Мәләш ағачыннан сикертмә, шомырт ағачыннан сикертмә сығылмалы була. Менә ызбаның почмақ йағын бүлеп қуйған бүлем тақта була, шул **бүлем тақта** өстенә сикертмәне қуйған була, сикертмәгә қабық бишекне эләләр — *т.я.-трх.*

— Бүлем башына сикертмә қуйалар ыйы да шығырт-шығырт сикертәдерийек қабық бишекне.

Қарға қазан асқан,
Чыпчық җоморқа салған.
Абыйыңа бутқасы
Сиңа анық шулпасы.

— Почмақ йаққа, қазан асқан йаққа кергәндә бүлем башы бар. Шуның башына сикертмәгә бишек элгәннәр. Қайын була ул сикертмә ағачы.

Қайын сиртәләрдә үстем
шуңа қайғылы башым, —

дип җырлағаннар әwәлгеләр — *т.я.-к.т.*

[1] аҗыкасы — әнисе

## Бишек ағач

**Бишек ағач** *нокр.* бишек сиртмәсе.

— *Бишек ағачны* кертмәгә қулчу[1], йомро боросқа[2] пытылукка[3] кертэлэр. Артыш ағачны салалар бишеккэ. Исе бик тәмне артыш ағачның. Кэндер тегэлэр иде тебенэ. Бишекне бала қайтқан көнне китерә қоз анасы — *нокр.*

## Бишек киштә

**Бишек киштә** *глз.* бишек сиртмәсе.

— Түшәмгә кулчу салып киштэ элэлэр, *бишек киштэ.*

— *Бишек кишта* мил'аштан куштылар йасамага, кайынны кушкаламадылар, кайгылы була дип. Кабык тубалдан йасагаладылар бишек. Кайынны салгаламадылар *бишек киштәгә.*

Карурманга кергән чакта
Кистем кайынның башын.
*Кайын киштәләрдә* үстем
Шуңа кайгылы башым — *глз.*

## Сәли агач

**Сәли агач** *к.-уф., перм.* сиртмә.

— *Сәли ағачны* қайындан йасама, қайын қайғылы була. Милештән йаса, милештән зәхмәтләр керми. Милеш ағачы файдалы була — *перм.*

— Қырда *сәли сәнчек* күли, сәли элә — *к.-уф.*

## Сәнсек, сәнчек

**Сәнсек, сәнчек, сәли сәнчек** *к.-уф.* сиртмә.

— *Сәнсек* ул бишек элә торған кәртә була. Миләш ағасын сәнсек итеп қуйдылар.

— *Сәнсек* ул қайын ағас, кәртә ағас кеwек. Матчаға тимер қағалар ыйы, ул қулчалы булайы. *Сәнчекне* шул қулчаға тығалар ыйы. Бишеккә бау тегәң, шул бауны эләң. Тирбәлә ул қайын ағасы.

---

[1] қулчу [рус. кольцо] –боҗра
[2] йомро борос — матча
[3] пытылук [рус. потолок] — түшәм

### Кәртә

**Кәртә** *к.-уф.* сиртмә.

— *Кәртә* булды. Пуржинкә қайсы бер кешедә генә булды.

*Кәртә* киртәләр дә бер башын түбә тақтаға қуйалар, бер башына бишекне эләләр дә тирбәтәләр.

## КЫРГА ЭШКӘ БАРГАНДА БАЛАНЫ АЛЫП ЙӨРҮ ӨЧЕН ЯСАЛГАН АРБАЛАР

### Арба

— Йаланға алып барғанда да шулай итәбез. Эшкә йөрөгә кәрәк, барыбыз да йәш балалыбыз. Балаларны қуйабыз *арбаға*, үзебез җәйәү барабыз қабырғада. Қайсы *арбада*, арба қырға айақларын сәлендереп утыралар ый.

Арта кич қырын килеп алалар ыйы ат белән. Балаларны төйәп алып китәләр ийе, үзебез йаланда қалайық — *к.-уф.*

### Алын арба

**Алын арба** *байк.* Баланы тартып йөртә торган ике тәгәрмәчле кечкенә арба.

— *Алын арбага* куйып баламны алып барсам, барып итәрменме, дим.

### Бәбәй арбасы

— Бәбәй арбасын матурлап, бизәкләп бийатам йасап бирде беренче балам туғачтын — *каз.ар.-блт.*

### Қузалағ арба

**Қузалағ арба** *эстр.* бәбәй арбасы.

— Қузалағ арбаға утырта баланы. Дүрт тәгәрчәкле[1] арба. Қузалағ арбаны тахтам биткә[2] қуйа.

---

[1] тәгәрчәк — тәгәрмәч
[2] тахтам бит — сәке

## Күмә

**Күмә** *т.я.-к.т.* бәбәй арбасы.

— *Күмәне* сумала эретеп қараға буйап қуйалар ыйы. «Ай, матур күмә алған син» диләр ийе. Фанердан йасыйлар, кечкенә көпчәк қуйалар күмәгә. Малайны күмәгә салып урақка тартып йөридерийек.

— *Күмә* буладырыйы, қара күмә. Шунарга салып тартабыз баланы. Чебен килмәскә чыбылдығын қороп қуйасың. Хәзер *күмә* дә бетте, урақ та бетте, *күмәгә* малай салып урақка йөрү йуқ.

— Малайны күмәгә салып қырға алып йөрделәр. Күмәсез булмый бит. Күмәле хатыннар, бәбәй тартып барған хатыннар унар-умбишәр булып тезелеп барадырыйың. Қырда араларын йырақ қуйабыз, бер-берсен уйатмасыннар дип.

Қараға буйаған бик матур қабық күмәдә үстердек малайларны. Қабық күмәм әле дә бар, тәртәләре, көпчәкләре дә бар. Қантарлар арасыннан йөридерийек күмә тартып, бәрәңге кәтмәннәдек, борчақ чаптық.

## Мәдәк

**Мәдәк** *чст.* бәбәй арбасы.

— *Мәдәкне* кан'атам йасап бирде кабыктан. Йүкә кабыктан йасаган *мәдәк* йиңел була.

## Мошко

**Мошко** [удм.] *нокр.* баланы утыртып аркага асып кырга алып йөрү өчен каен тузыннан ясалган җайланма.

— *Мошко* туздан йасаганда ул, күрсәтермен менэ келэттэ.

— *Мошкосы* аркасында, мошкода бәбәй бара корга. Анда йоклай бәбәй, йапкычын йаба.

— Печин чапканда да *мошкода* калалар иде оланнар. Әллә ка китәләр иде печән чабып. Ә без бәбәй сакчылар[1] кала идек мошко кырда.

— *Мошко* йасайлар, аның алдысына чаршау йабалар, оланга койаш тимәсен өчөн.

[1] бәбәй сакчы — бала караучы

Бәбәй тугачын ике көн генә торалар да ике көндән сун корга китәләр *мошкога* салып бәбәйне. Бәбәй *мошкода* тора, үзләре уралар. Бер көн генә торалар да эшкә китәләр.

*Мошкога* бәбәйне салалар да кушул'[1] кебек аркага элеп корга китәләр. Ул бәбәй көннең көн озон анасы белән корда тора. Йыласа ки барып имезә анасы, дагын ул мошкода йокога китә. Бәбәй сакчы да йук. Ул *мошко* корда тора.

— Бәбәй тугачын әбиләр корга илтә алмай, әниләр кайта алмай имезмәгә. *Мошкога* салып алай йаннарында тоталар корда. Йаңгыр йауса да анда ук тора.

## Мошкога «шайтан агач» салу

**Шайтан агач** *глз.* шайтан таягы (чертополох).

— *Мошконы* анда да, монда да утыртып калдырабыз корда урак урган чакта. Олан *мошкода* йоклай. Йырак кала *мошко*. Аны өчөн *мошкога* бәләкәй баш астыга шайтан агач салгаладылар. «Шайтаннар килмәсен өчөн».

— *Мошко* белән корга оланны алып барса, *мошкога* да баш астыга шайтан агачын салайык. «Оланнарны шайтан алмасын өчөн».

— Бәбәйләрнең баш астыга бишеккә, *мошкога* баш астыга шайтан тайак салгаладылар, *мошко* белән корга оланны алып барса.

«Шайтаннарны куркытмага шайтан тайак өзеп алыгыз», — дигәләделәр. Ал чәчәкле була шайтан тайагы. Бишеккә бәләкәй астыга салгаладылар.

— Әни кушайы шайтан агач китергәләмә. Элек *мошко* кийеп йөргәләделәр ич корга. *Мошко* баш астыга бәбәйгә салгаладылар шайтан агачны.

## Чөлкәwеш

**Чөлкәwеш** *к.-уф.* җилпүч.

— Чөлкәwешкә салып кәртүк қабағы[2] өстенә қуйабыз баланы кәртүк қазғанда.

---

[1] кушул' [рус. кошель] — корзина

[2] кәртүк қабағы — бәрәңге сабагы

### Куш

**Куш** *глз.* бәбине утыртып кую өчен агачны куышлап ясалган җайланма.

— *Кушка* утырткаладылар бәбәйне, йыгылмасын, йаламасын өчен. *Кушта* утыра иде әле бәбәй, кереп кара. Сугылмасын, йөзен-башын суктырмасын өчөн *кушка* утырталар.

## КЫРДА БИШЕКНЕ ЭЛЕП КУЮ

### Баланы қырға алып йөрү

**Баланы қыраға йөртү** *туб.* баланы кырга алып йөрү.

— Элек қырата йөреткәннәр паланы. Пиләп алып киткәннәр. Таң пашыннан китәбес паланы алып тиде, алай эшләгәнпес тиде.

### Ақ тирәк

**Ақ тирәк** *төм.* бишекне элеп кую өчен җайланган өч йәпле агач.

— Цәңгелцәкне[1] аппаратлар талаға. *Ақ тирәк* тип элеп қуйғаннар өч йәпле ағачқа. Үсең урақ урасың, эшләйсең.

— Талаға паланы алып парса, чебен ашамасқа қороп қуйасың, сәңгелсәккә саласың, шунда ырғап йоқлатасың. *Ақ тирәк* тип әйткәннәр.

*«Ақ тирәгеңне* қалдырма, анда қуйғалы кәрәк цәңгелцәкне».

Пала талата әйбәт йоқлай. Үсләре урақ ураты әнейләр.

— Өц тайақ йасаптылар, пауға бәйләп *сәлтепне*[2] қуйыптылар, картупларын қасыптылар, урақларын урыптылар. *Сәлтепләре* элүле торыпты. Сықтаса[3] ырғайтылар[4] *сәлтепне.*

### Арба арышы

**Арба арышына элү** *төм.* арбаның тәртәсенә бишекне элеп кую.

---

[1] цәңгелцәк — бишек

[2] сәлтеп — бишек

[3] сықтаса — еласа

[4] ырғайтылар — тирбәтәләр

— *Арбаның арышын* йуғары күтәрткән, шунда бау белән бәйләгәннәр, асып қуйғаннар чәңгелчәкне.

— Шәлтепне[1] қырға барса да алып барған. Арбаның арыш ағацына бәйләп қуйатылар. Ак мал[2] беләнме, йаулық беләнме, йабып қуйған шәлтепне.

### Сәли сәнчек

**Сәли сәнчек** *к.-уф., перм.* кырда бишек элү өчен җайланган агач.

— Ашар нимәсен күтәреп, сәли күтәреп қырға китә, чеперикләрен алып китә. Сәли сәнчек күли, сәли ағачын элә шунда, йатқыза сәлигә, килеп-килеп қарый — *перм.*

### Селкенцәк

**Селкенцәк** *туб.* бала арбасы.

— Селкенцәккә салып тартып йөргән баланы, селкенцәкне олатам йасайты йүгә ағацтан.

## ИМИ, ИМЧӘК

**Ими, имчәк** — хатын-кыз күкрәгенең өске өлешендә түгәрәкләнеп калкып торган сөт бизе. Ул тыңлый тынып, Беренче кат имчәк капкан төсле сусап, йотылып. М. Җәлил.

Әдәби телдәге **ими, имчәк** сүзләренең җирле сөйләшләрдә түбәндәге вариантлары бар:

**Мими** *каз.ар.* (күбрәк балалар телендә),

**имцәк** *туб.-ирт.*, **ымма** *саз.я.*

— Палаңа *ымма* wир.

### Бала имезү

Бала имезә торган хатыннар имчәкләрен кешегә күрсәтмәгәннәр. **Күкрәкчә** астыннан гына имиләрен чыгарып балага каптырганнар.

---

[1] шәлтеп — бишек

[2] ақ мал — ак тукыма

**Күкрәкчә кийеп бала имезү** *минз.:*

— Күкрәкчәне матур ситсылардан тегеп йасыйлар ыйы. Менә болай муйыннан кимәле йе, күкрәккә дә йылы булып торған.

Бәбәй имезгәндә күкрәкне күрсәтмәгәннәр йәш хатыннар. Күкрәкчәне йәш хатыннар да, қарт қортқайақлар да кигән күлмәк астыннан.

**Түшти кийеп бала имезү** *минз.:*

— Түшти шул уқ күкрәкчә инде ул. Түшти дип әйтә торғаннар ыйы. Түшти астыннан ғына имийен чығарып бәбәй имезгәннәр. Бисмилла әйтеп имезгәннәр.

## ИМЕЗЛЕК

**Имезлек** — элек (гадәттә шикәр кушып) чәйнәп әзерләнгән һәм, имчәк балага каптыру өчен, чүпрәк яки марляга салынган ипи йомшагы; Шундый ашамлык төрелгән чүпрәк. — Түтәе аңа, иске чүпрәккә төреп, әче арыш икмәгеннән зур итеп имезлек каптыра. Ф. Хөсни.

### Имезлек салу

— Анасы эшкә чығып киткәндә әбиләр бәбигә *имезлек* салалар ыйы марлыға салып. Бала имә-имә бишектә җоқлап китәр ийе. Сөтне қалақ белән аwызларына салалар ыйы — *минз.*

— *Имезлек* дип марлыға қара әпәй сәйнәп салырлар ыйы, имә торғаннар ыйы балалар. Шәкәр белән қушып сәйнәр ийек — *к.-уф.*

### Имешлек

**Имешлек** *т.я., себ.* имезлек.

— *Имешлек* суырып үскән малайлар. *Имешлек* дип марлыға йә чичта чүпрәккә әпи чәйнәп салғаннар баланың аwызына — *т.я.-трх.*

— *Имешлек* тип паланың аwысына икмәк цәйнәп қаптыратылар, цеберәккә урап. Пала суыраты, әзрәк үскән сун үсе имешлек йасайты үсенә, тик суырып йөрите — *себ-төм.*

## Имтек

**Имтек** *к.-уф.* имезлек.

— *Имтек* имеп йата улан, чәйнәп салғаннар, суwыра ул.

## Имгеч

**Имгеч** *т.я.-крш.* бала имезлеге.

— Имгеч җасаган, марлы үтәли имезгән.

## Суыртқыч

**Суыртқыч** *каз.ар.-дөб.* имезлек, марлыға яки чүпрәккә кечкенә генә итеп төенләнгән бала азыгы.

— *Суыртқыч* диләр, элек бәбигә ипи белән шикәр чәйнәп салған марлыға, җә манный ботқасы пешереп марлыға салып *суыртқыч* бирә бәбигә. Қарначса шул *суыртқычны* суыртқан анасы эштә чағында.

## Сымрақ

**Сымрақ** *себ.* имезлек. Сыер яки сарык суйгач, җилененнән имчәген кисеп алып, тиресен генә калдырып эшкәртеп, шуны сыер мөгезенә киертеп, бала имезү өчен җайлаганнар.

— Сыйыр имцәген кисеп, сытырып, тосқа қайната. Посолмайты та. Тиресе генә йоқа ғына пулып қала. Сыйырның мейесенә[1] имцәкне бәйләп имескән. Бу йағыннан сөтен қойоп утырасың. Пала имәте.

— *Сымрақ* йасайты қуйның имцәген тосқа салып, итен сытырып алып. Эчендә ите була тоған. Аны айландырып, итен сытырып алатлар, тиресе генә қала. Сыйыр мейес, қуйның имцәге. Имеп бетсә, аны тосло суға салып қуйасың эстәкәнгә — *туб.*

— *Сымрақ* йасағаннар сыйыр имцәкне тослап. Аны *сымрақны* пала аwысыннан пушайтмаған. Менә *сымрақны* эт алып киткән. «Ақтүш ашап қуйты сымрақны» тип әйтепте пы бала — *төм.*

---

[1] мейес — мөгез

### Тастар

**Тастар** *каз.ар.-дөб.* имезлек.

**Тастар қаптыру** *каз.ар.-дөб.* имезлек каптыру.

— Қара ипине шикәр белән чәйнәп балаға аwызына тастар қаптырғаннар элек.

### Омчы

**Омчы** *том.* имезлек.

— *Омчы* дигәннәр. Икмәкне чәйнәп, марлыға салып аузына салғаннар баланың. *Омчы* була. Бала йыласа *омчы* салатқаннар иде. Икмәкне шикәр белән чәйнәп марлыға салатқаннар иде дә аwызына қаптыратқаннар иде. Имеп йататқан иде бала *омчыны.*

## БАЛАНЫ КОТЛАП КИТЕРЕЛӘ ТОРГАН ӘЙБЕРЛӘР

### Бәбәй кийем, бабай әйберләр

**Бәбәй кийем, бабай әйберләр** *нокр., глз.* бала әйберләре.

— Майашка бәбәй котлап *бәбәй кийем* китерәләр — *нокр.*

— *Бабай әйберләр*, күлмәкләр, адийаллар китерәләр, бирнә китерәләр — *глз.*

### Бишек бирнәсе

**Бишек бирнәсе** *нокр.* бала котлап китерелгән әйберләр.

— Беренче бала туғач қыз анасы, дағын қызалдычылар[1] *бишек бирнәсе* китерәләр. Ыштан, бабайға[2] күлмәк, чүпрәк, йурған, чыбылдық, бишек астылық, көрпә, матрас, мәләкәй[3] китерә. *Бишек бирнәсе* китерәләр, бишеккә чаршау, чүперәген, йурған, чымылдықлар, күлмәкләр китерәләр, қазан кукыл'[4] китерәләр.

### Бишек астылық

**Бишек астылық** *нокр.* бишек төбенә салу өчен тегелгән киез.

— *Бишек астылық* китерә қыз анасы.

---

[1] қызалдычы — туйда кызны озатып килүче
[2] бабай — бәбәй
[3] мәләкәй — мендәр
[4] қазан кукыл' — пилмән

## Бишек қормасы

**Бишек қормасы** *бәр.* бишек чаршавы.

— *Бишек қормасын* ақ йефәктән йасыйлар.

## Саwын

**Саwын** *тара.* бала котлап бирелгән бүләкләр.

— Пала қотлоққо *саwын* аппарасың қәлең килгәнцә. Әтийәл, кәчәлкә[1], қүләкләр[2]. Оллы қысым қусы йарғацын йақшы әтийәл апардық, сыйырыбыс посаулаған ыйы. Ул посауны ырыслатық[3].

«Ул посау мал булса, қысыбысқа», — тип. Ул йетте, қысыбысқа пиртек.

— Күргәле килгән хатыннар пүләк алып килә. Пашына пер нимә қадайлар тақыйасына[4].

— Перенце паласы тыуғасын, қусы йарғасын посаулаған тана апардық. Йәнгә-йән[5] қушылу пулаты.

## Йастық, йастығац

**Йастық, йастығац** *төм., туб.* беренче бала тугач, бала котлап бишегенә элү өчен дип матурлап ясалган кечкенә мендәрчекләр.

— Пирwайғы балаға шәлтепкә йастықлар алып килгәннәр, кийемнәр, шәңкәләр[6] китергәннәр.

Шәлтеп бауға тегеп цығатлар йастығацларны. Қайсы өц мейешлене[7] эшләйте, қайсы түрт мейешлене тегеп-тегеп цығатлар. Баш балаға тегеп қуйатлар шәлтеп бауларына. Қортқайақлар[8] тегеп утырған.

— Ул йастықларны төрле-төрле қыйықлардан[9] тегәтләр, өстөнә суқлар, ақцалар тегәтләр. Қәлле қәленцә цөпөрәктән

---

[1] кәчәлкә [рус. качалка] — коляска
[2] күләк — күлмәк
[3] ырыслатық — багышладык
[4] тақыйа — бала калфагы
[5] йәнгә-йән — җанга-җан
[6] шәнкә — шәңгә
[7] өц мейешле — өч почмаклы
[8] қортқайақ — карчык
[9] қыйықлар — тукыма кисәкләре

тегәтләр йастыкъларны, сәңгелцәк бауға[1] эләтләр. Ул йастыкълар селкенеп торатлар. Бала йаткъан йирендә аларға къарап көлөп йататы. Пирwайғы, алдынғы балаға китерәтләр йастыкъларны.

— Сәңгелцәккә йастыкълар къылатылар. Къәрендәш туғаннары ул йастыкъкъа акъца тегәтеләр, аны цәңгелцәк бауға элеп къуйатылар. Цукъ къылып тегеп къуйғаннар йастыкъны.

— Сәңгелцәкнең түрт паwы та тулы йастығацлар була тоған ите. Кергән бер кеше йастыкъ апкерәтеләр ите. Йастыкъкъа хәленцә акъца тегәтеләр ите.

— Перенце балаға йастыкълар китерәтләр. Ул йастыкъларға къайсына сәдәп, къайсына көмешләр тегеп къуйатлар, цукълар къылатылар ул йастыкъларға. Цуғы матур була. Түрт бау булаты, түрт бауға да йастыкълар элеп къуйатылар. Къайсы йастыкъ өц мейешле, къайсы дүрт мейешле пулаты. Ыспайы[2] булаты, аны сукъкъылап пала уйнататылар. Ицкем алмаған аныңкъы цуғын. Ул йастыкъларға ағыйыкълар[3] тегеп къуйасың күз тимәсен тип.

— Йастығацны къыйыкълап кискеләп тегеп цығасын, ул цукъ булаты. Аны шәлтепнеке дүрт баwына тегеп цығасын, туп-тулы йастығац булаты. Мин алай асыраған баланы. Шәлтебенә бүләккә алып керү кәрәк.

— Къыслы булғанымта дүрт баwында икешәр рәт тегелгән иде йастыкълары. Бала олоғайып ул йастыкъларны тартып ала башлағац ул йастыкъларны сүтеп үсенә *къорама йурған*[4] къылып къуйтым. Йастыкъ тегеп элә тегәннәр ийе сәлтепкә. Тимә, сәтәп, акъца тегәтегәннәр ите. Йастыкъның уртасына пакъта[5] салып йасай тоғаннар ите перенце балаға.

## Къалта

**Къалта** *төм., туб.* баланың бишегенә элү өчен бала котлап китерелгән кечкенә мендәр яки чуклар.

— Перенце паланы тапса пөтөн кеше къалта тегеп алып кәрә тоғаннар. Түрт цукъ къылып сәлтеп баwына элә теләр. Кем бала

[1] сәңгелцәк бау — бишек бавы
[2] ыспайы — матур
[3] ағыйыкъ — ахак
[4] къорама йурған — төрле-төрле тукыма кисәкләреннән тегелгән юрган
[5] пакъта [фарсы] — мамык

туса да кѳтеп торатылар қалта тегеп алып кергәле. Кем керсә дә биш-алты қалта ошлап киләтеләр сәлтепкә әwәле.

Қалта тип қыйықлардан тегеп, цуқлар қылып утырабыс.

— Шәлтепнең тѳбен тегәтеләр мал белән. Қалта тегеп алып керәтеләр цуқлап. Тѳрле-тѳрле малтан[1] қалта эләтеләр шәлтепнеке дүрт башына, йақшы малтан, ыспай булаты. Қалта эценә пақта бецәтеләр[2] — *туб.*

**Йастықцығац, қалта // ғалта, ғалтацық**

**Йастықцығац, қалта** *тѳм., туб.:*

— Йастықцығацны қалта тип әйтәтләр. Әрбер кеше перенце палаға алып киләтләр. Сәлтепнеке түрт баwына элеп бағалар. Перенце балаң ғой.

**Ғалта, ғалтацық, қалтацық** *тѳм.:*

— Ғалта тегеп керәтеләр нараси балаға. Сәңгелцәккә элеп цығып китәтеләр. Ғалтацықлар апкерәбес. Ғалтацықлар әпкерсә, алар йеп биреп цығаратылар. Шал қыйғац ғалтацықны бәйләп цығып китәтеләр сәңгелцәккә.

— Қалтацықлар эләтеләр сәңгелцәккә. Қалтацыққа кѳмеш ақцалар тегәтеләр йақ-йағына.

— Перенце балаға йеңеләйгән сун сәңгелцәгенә йастығацлар эләтеләр ите. Йастығацны цуқлап тәңкә тегәтеләр ите. Сәңгелцәкнең түрт паwына та йастығацларны, қалтацықларны тегеп цығатылар ите. Аңа, қалтацыққа, мѳйешләренә ақца тегеп цығатылар ите.

«Цәңгелцәккә менә қалта текмәгән әле мин аның паласына».

«Кереп қалта тегеп цығу кәрәк» тип әйтәтеләр.

Шал қалтаны эләтеләр ите. Кергән гешене цай эцергәннәр.

**Қыс қотлоқ**

**Қыс қотлоқ** *туб.* бала котлап бишеккә элү ѳчен китерелгән кечкенә мендәрчекләр.

— *Қыс қотлоқ* тип күрешкәле алып паратылар ул йастықларны. Баланы цәңгелцәккә салғац алып паратылар, шул цәңгелцәккә элгәле алып паратылар.

---

[1] мал — тукыма

[2] бецәте — тутыра иде

**Малай қотлоқ, нәнәй қотлоқ** *төм.* бала котлап бишеккә элү өчен китерелгән чуклар, кечкенә мендәрчекләр.

— Сәңгелцәк баwы булған. Малай туғач, сәңгелцәк баwына төмән-төрле йеплләрдән, чөпөрәкләрдән чуқлар йасап алып кереп, сәңгелцәк баwына бәйләткән булғаннар. *Малай қотлоқ* итеп бәйләткәннәр.

— *Нәнә қотлоқ* тип сәңгелцәккә элеп қуйатылар қыйғац ғалтацықлар.

## БАЛА ЧҮПРӘКЛӘРЕ ҺӘМ БАЛАНЫ ТӨРҮ

### Биләү

**Биләү** — 1. Баланы биләүгә урап, кысып бәйләү. — Әниең сине тапкач сөя-сөя Ап-ак биләүләргә биләгән. Б.Рәхмәт. **Биләү** 2. Яшь балаларны төрә торган махсус чүпрәк, җәймә. — Карап биләвеңнән Берни белми көлеп ятасың. Ш. Мөдәррис. Кайвакытларда [баланың] кулларын, аякларын биләүгә чолгап, аны хәрәкәтләнмәскә мәҗбүр иттеләр. М.Җәлил.

**Биләүсә** — к. биләү 2. ... — биләүсәләрен кызурак итеп, тырышыбрак уарга тотынды. М.Әмир. **Биләүсә баwы, биләwеч** — яшь баланы биләүгә төргәч, кысып урап бәйли торган бау яки озын тар тукыма.

### Бүләү

**Бүләү** *әстр.* биләү, бала биләү.

Әйем мине тапқан чақ
Ақ бүләүгә бүләгән.
Ақ бүләүләргә бүләгән
Бәхте булсын димәгән.

### Иске

**Иске** *миш.д.* яшь баланы төрү өчен әзерләнгән чүпрәкләр.

— Ыланы тугач, өр-йаңа искеләр йасап бирдем үзенә — *хвл.*

### Чу

**Чу, бала чуwы** *том.* яшь баланы төрү өчен әзерләнгән чүпрәкләр. Чагыштыр: әдәби телдә *айақчу* < айақ + чу — аяк чолгавы.

— *Чу* дийәләр иде. Ҡайа ыштан балаҡлары, ҡайа ҡалған көйнәк[1] кисәкләре. Аларны йыртадыҡ та урыйбыз баланы.

— Бала *чуwы* йасайсың тузған көйнөктән, чөпөрәкләрдән[2]. Атасының көйнәгеннән йасадылар бала *чуwын*.

— «Йә инде, бу ҡортҡа *чуwын* да йумаған, аунанып[3] йата *чулары»*, дип әйтәләр.

### Йөргәк, йүргәклек

**Йөргәк** *к.-уф.*, **йүргәклек** *төм.* бала чүпрәге.

— Баланы *йөргәккә* төрәләр дә йанына салалар — *к.-уф.*

— *Йүргәклек* ошлап[4] киләтеләр хәл белгәле килсәләр — *төм.*

### Йүргәмешләү

**Йүргәмешләү** *туб.* баланы төрү.

— Йүргәкләргә *йүргәмешләп* ҡуйатылар баланы.

### Йәйгелек

**Йәйгелек** *тара.* бала чүпрәге.

— *Йәйгелекләр* кән[5] пулматы элеке. *Йәйгелекләрне* атасы көйләгеннән, инәсенең көйләк итәгеннән йасайтылар, йуwатылар да киптерәтеләр.

### Үргәк

**Үргәк** *тара.* бала чүпрәге.

— *Үргәккә* урайсың баланы.

### Атасының күлмәгенә төрү

**Бала атасына сөйкемле күренсен өчен ырымлау.**

— Кайберләре әтәләр: «*Атасының күлмәгенә* цорнарга кирәк, атасы йарата төшәр, — диләр. Элек иске күлмәкләрдән йасилар иде цорнарга — *срг.*

---

[1] көйнәк — күлмәк

[2] чөпөрәк — чүпрәк

[3] аунанып — аунап

[4] ошлап — тотып

[5] кән — күп

— Баланы *атасының кулмәгенә* төрәләр, атасына севекле булсын, — дип — *нокр.*

— Эле' *атасының 'үли'ен* (кулмәген) йырта иделәр, бибине чорный иделәр *атасының 'үли'ени* — *кас.*

**Атасының кулмәгенә төрү** *к.-уф., минз.:*

— *Атасының кулмәгенә* төргән булайық баланы.

«Атаң кебек тәүфиқле бул», — дип алладан сурап.

Башлап *әтисенең кулмәгенә* төрәсең, әтисенә үз булсын, дийеп. Шундый ғәдәт булды.

— Элек йөргәккә ир кешенеке кулмәге тузуын қарап қына тордоқ. Йөргәкне шулай ир кешенеке кулмәгеннән йасадылар. Җиңен өзөп алып бот астына салдылар баланың. Зурырақ җиренә болай төрөп қуйаң.

— *Атасының* иске *кулмәге*, *анасының* иске *кулмәге* кийем булған балаға — *минз.*

Малай булса, атасының кулмәгенә төрерләр ийе.

«Ата сарылы булсын».

Электән баланы әтисе кулмәгенә төреш ийе.

«Әти сарылы булу өчен» әтисе кулмәгенә төреп сала.

Аннан соң инде әни кулмәк итәкләре китә.

«Инә сарылы булсын» дип үdebedнең кулмәк итәкләренә төрдек балабызны — *минз.*

**Бәбәй төрү** *чст.:*

— Бәбәйне *әтисенең* иске *кулмәгенә* төрү булган, өтергәннәр диләр.

— Әбисенең, әнисенең *иске кулмәкләреннән* сырма сыргаңнар балаларга.

**Бәбәй төрү** *срг.:*

Корсаклы хатын үзенең кулмәк итәген хәстәрләп куйа бәбәй төрергә, искеләрен, өстән цоргый торганын хәстәрли. Тузган шәле дә йарап куйган. Шылай иде.

**Бәбәй төрү** *влгг.:*

— Бездә бәбәйгә әбинең кулмәк чабулары, бабайның кулмәк җиңе булды. Шынарга төреп дүрт бала асырадым. Зурлак кулмәк чабуына чормисың оланны. Ак биләүләр йук иде.

**Баланы төрү —** себер диалектларында.

— Паланы **атасы көйләгенә**[1] тә, **инәсе көйләгенә**[2] тә төргән. Йастық тышына төргән, қомачқа төргән. **Китәнгә**[3] **төрмите**, китән тәненә йарамайты — *тара.*

— Баланың кентеген бәйлисең, йуwып урап саласын. **Үргәккә урайсың баланы**. Әwәле **атасының көйлегенә** урай торған булғаннар — *тевр.*

— **Атасының чалбар балағына, инәсенең көйләгенә** ураганнар баланы — тевр.

— Күлмәгебеснең итәк йағы қала, шаны әсерләп қуйған пес. Қус үтүк[4] белән үтүкләп малайны урағалы — *туб.*

**Бала озын гомерле булсын өчен:**

— **Қарт кешенең көйнәгенә** урайтыганнар баланы. **«Аның ғомерен бирсен»**, — тип. Менә **мамайларның көйнәк итәгенә**[5] урайлар — *том.-йәwештә.*

— Мин қорама қорайдым[6], балаға йурған йасайтым. Қорама йурған осон ғомер бирәте тип әйтәтеләр — *туб.*

## БАЛАГА ИСЕМ КУШУ

Ислам дине йолалары буенча бала тугач аңа исем кушу хөкемнәре ике төрле: беренчесе аның — фарыз, ә икенчесе — сөннәт.

Фарыз: Бала тугач әтисе белән әнисе бер исемне сайлап, «балабызның исеме, мәсәлән, Гали була» дип киңәшеп бер фикергә киләләр. Шуннан соң аңа Гали дип эндәшә башлыйлар. Менә шулай итеп өсләрендәге фарызны үтиләр.

Сөннәт: Сөннәте аның азан һәм камәт белән була, ягъни баланың уң колагына азан әйтелә, сул колагына камәт төшерелә.

---

[1] атасы көйләге — әтисе күлмәге
[2] инәсе көйләге — әнисе күлмәге
[3] китән — киндер тукыма
[4] қус үтүк — күмер үтүге
[5] көйнәк итәге — күлмәк итәге
[6] қорама қору — корама ясау

Балага исем кушучы кеше баланы аякларын **кыйбла тарафына** сузып мендәр өстенә яткыра. Шуннан соң бераз уң ягынарак күчеп азан әйтә. Азан басып әйтелә һәм азаннан соң баланың уң колагына: «Синең исемең (мәсәлән, Гали булса) Гали» дип өч мәртәбә әйтә. Аннан соң бераз сул ягына чыгып, намазга камәт төшергән шикелле камәт төшерә. Камәтне төшереп бетергәч баланың колагына: «Синең исемең Гали», — диеп тагын өч мәртәбә кабатлый. Аннан соң балага тәүфикъ, һидәят теләп дога кыла.

Балага җыйнак һәм күркәм исем кушуны мактыйлар.

Бәби туе бала туганнан соң җиденче көн үткәч үткәрелә.

Шушы мәҗлескә мулланы да чакыралар. Бу ашны бәби ашы, бәби мае дип әйтәләр.

Халык җыелып беткәч, баланы бер мендәргә салып, мулла алдына китереп куялар.

Мулла сорый: «Ни атлы кушыйк?» — дип. Ата-анасы кайсы исемне ихтыяр кылса мулла шул исем белән ат куша. Кайбер кешеләр бу вазифаны мулланың үзенә дә тапшыралар, ул үзе теләгән исемне куша.

Мулла, баланың аякларын кыйблага таба куеп, баланың баш очында аягүрә торып, бармакларын колак очларына куеп, баланың уң ягына дүрт мәртәбә азан әйтә: «Аллаһу әкбәр», ягъни «Аллаһе Тәгалә һәр нәрсәдән олуграктыр».

Ике мәртәбә: «Әшһәдү әннә иләһә илләллаһ». «Күңелемнән гуаһлык бирәмен ки, тәхкыйк, бер Аллаһе Тәгаләдән башка һич тәңре юктыр», — ди. Ике мәртәбә: «Әшһәдү әннә Мөхәммәдәррасүлүллаһ», — ди. «Күңелемнән гүаһлык бирәмен ки, тәхкыйк, Мөхәммәд гәләйһиссәләм — Аллаһның илчеседер», — ди. Ике мәртәбә уң тарафка карап: «Хәййә гәләссаләһ» «Ашыгыгыз намазга!» — ди. Ике мәртәбә сул тарафка карап : «Хәййә гәләл фәләх» — «Ашыгыгыз газаптан котылырга», — ди. Янә ике мәртәбә «Аллаһу әкбәр», — ди.

Азанны әйтеп бетергәч, мулла азан догасын укый һәм мәҗлестә катнашучылар да эчтән азан догасын укып дога кылалар.

Бала туганда аның колагына азан әйтүнең мәгънәсе болай аңлатыла. Баланың иң беренче ишеткән сүзе «Аллаһ» булсын һәм аның яныннан шайтаннар качып китсен. Чөнки шайтаннар Аллаһ исемен ишетүгә качалар. Әгәр дә азан әйтелмәсә,

шайтаннар бала янына җыелып аңа зарар итүләре мөмкин (Саттар-Муллиле Г., 2006, 44–45).

Азан догасын укып дога кыйлганнан соң, мулла баланың сул ягына басып торып, куллары як-ягында булып, **камәт** әйтә. Камәт — намазлар алдыннан әйтелә торган тәкбир. Аннан соң мулла баланың йөзенә иелеп, кычкырыбрак:

«Исме шәрифең фәлән булсын», — дип, өч мәртәбә әйтә. Моннан соң Фәтихә сүрәсе укыла.

Мулла дога кылгач, баланы анның яныннан алып китәләр. Аннан соң бал-май китерәләр. Мәҗлестәге һәркем бал-майдан авыз итеп, яңа туган балага бүләк салалар. Моннан соң мулла җыелган акчаларга һәм бүләкләргә дога кыла. Шуннан соң берәм-берәм аш китерәләр. Ашаганнан соң ашка дога кылалар.

Шулай итеп балага исем кушу мәҗлесе төгәлләнә.

Исем кушу йолаларының лексикасында ислам дине йолалары һәм җирле үзенчәлекләрнең бергә үрелеп бару күренеше чагыла.

## Ат атау

**Ат атау** *төм.* исем кушу.

— *Ат атаҕанта* қолаҕына қыцқыра да әйтә. Синең исемең шул, әтийеңнең исеме шул. Өц тапқыр әйтә. Әти-әнисенең исемен қолаҕына қыцқырмаса, үлсә, әти-әнисен теге дөнйата исемен белми ти.

— Ат атаҕалы пешеренәсең. Мулла ат атайты, хәтем уқыйты. Синең исемең шунтай пулты, атаңның исеме шулай тип әйтеп. Анта пүләк әпкиләтләр палаҕа, ыштанмы, көйләкме.

— Қатымҕа барам. Бала ататалар. Үсләре йәш кенә, қартнә[1] белән қартата[2] пулып қуйыптылар. Йегетләре бар. Бабайларын, мамаларын чаҕырып ат ататалар. Тоҕасын уқып исемне өч мәртәбә қычқыраты мулла. Шулпа, шәңгә, қапшырма[3] пешерәтләр — *төм.*.

— Ат ататқалы кәрәк.

«Төнйаҕа килгән бала осон көмерле нәрәси булсын, бәқытле, тәүпиқле нәрәситә булсын», — тип — *төм.*

---

[1] қартнә — әби

[2] қартата — бабай

[3] қапшырма — бөккән

— Мулла чақырып ат ататабыс. Балаға бүләкләр ошлап киләләр. Мулла баланың башын қыйблаға қуйып, йастыққа салып, ат ататады, асан чақырады. Ата-инәсенең исемен баланың қолағына әйтәте, уң қолағына, сул қолағына. Цийә шәңкә, пәтер, туғац бешерәткәннәр ат ататқанда — *туб.*

### Атын атату

**Атын атату** *эстр.* исем кушу.

— Бала туып килә дә өч көннән соң атын ататам.

### Пәпә атату

**Пәпә атату** *туб.* балага исем кушу.

— Мин үсем пәпә ататқалы йөрим. Пәпәнең қолағына инәсенең исемен қыцқырып әйтәм. Инте қәсер үсенең исемен қыцқырып әйтәм.

### Ат кушу

**Ат қушу** *урт.д., себ.,* **ат кушу** *миш.д.* исем кушу.

— Табын күркәме тура-май[1], балмай була *ат қушқанда — каз.ар-дөб.*

**Ат кушу** *лмб., чпр., күрш., кузн.:*

— Йастыг эстенә баланы куйалар кибылага каршы и *ат кушалар.*

— Бала булгац балага күләк[2] кенә, иске генәләр китерәләр *ат кушканда — күрш.*

— Бахылай[3] мендәргә салып чыгаралар ыланны *ат куштырганда — чпр.*

**Ат кушучы** *кузн.* исем кушучы.

— *Ат кушучы* үрә айак[4] баса, оланны йастыг эстенә куйып китерәләр, атын куша, дыва[5] уки, киленгә бирә оланны. Ә син килен кеше иреңнең агасына тоттыр оланны, үз атаңа түгел. Син үз атаңнан китепсең инде.

---

[1] тура-май — кортлы май

[2] күләк — күлмәк

[3] бахылай — менә шулай

[4] үрә айак — аяк үрә

[5] дыва — дога

**Ат қушу** *тара.* исем кушу.

**Асан әйтеп ат қушу** *тара.*,

**қолағына қамәт төшерү** *тара.:*

— Нараси балаға ат қушқанда, баланы қулына алып, **қыйблаға қарап**, пашта **асан әйтеләте** уң қолағына. Баланың сул қолағына қамәт төшереләте. Асан сусып әйтеләте, ә **қамәт қысқа** ғына әйтеләте: аллаһ әкбәр, аллаһ әкбәр тип тис-тис генә қамәт төшереләте. Қамәт ул намас пашланты тигән сүсне аңлататы. Ә асан инте намасқа цақыру пулаты.

Қолағына әти-әнисенең исеме әйтеләте. Әтисенең исеме антай, әнийеңнеке монтай, ә синең исемең монтай булыр тип. Сорашың, әйбәт исемнәр қушың тип.

— Асан әйтеп *ат қушады*. Қарендәш-ыруwыңны чақырасың. Шатлық бит, кеше йуwылаты.

— Қолағына салаwат әйтәтләр, асан әйтәтләр *ат қушқанта*.

## Ат қушма

**Ат қушма** *баст.*, **ат 'ушу** *кас.* исем кушу.

— *Ат қушма* җыйалар, чәйенне тарталар[1], чәй қуйасын — *баст.*

— *Ат 'ушалар*, җыйын җыйалар[2], үзне'елири 'илилир. Қыбылаға 'аршы пәдүшкә[3], пәдүшкә өстени баланы 'уйалар — *кас.*

## Атқушар

**Атқушар** *әстр.* исем кушу мәҗлесе.

«Атын сағынып җылый», — диләр баланы, йылаwық[4] бала булса.

«Хәйерле булсын», — дип аwылдан киләләр, атқушар йасыйлар.

## Атқушар туй, атқушар мәҗлес

**Атқушар туй, атқушар мәҗлес** *әстр.* балага исем кушу хөрмәтенә оештырылган мәҗлес.

---

[1] чәй тарту — чәй эчү

[2] җыйын җыйу — мәҗлес ясау

[3] пәдүшкә [рус. подушка] — мендәр

[4] йылаwық — елак

— *Атқушар туй* була бала туғач, ат қуштырасын. Қунақ чақырасын, бабайлар чақырасын. Бәбәй ат қушқан җиргә дип әбиләр килә, кем ни зат[1] алып килә. Қара чәй эчерәсен, бал белән чәй эчерәсен, шулпа ашатасын. Туғаннары кийет[2] салалар, кийемнәр илтәләр балаға.

— *Атқушар туйы* була. Туған-қәрдәшләрен, дусларын чақырып ат қушқан йаңа туған балаға. Қуй суйады, ашын пешерәде, ат қушады. Атқушар мәҗлес җыйады, атқушар туй булды, туған-тоқомнар киләде атқушар туйға.

**Кече атқушар** *эстр.* туганнарны чакырып үткәрелә торган исем кушу мәҗлесе.

— Балаға бөтен затларын китереп, туғаннарын чақырып азан чақырттық.

**Зур атқушар** *эстр.* күп кеше чакырып, зурлап, исем кушу хөрмәтенә үткәрелә торган мәҗлес.

— *Зур атқушар* йасадық соңыда. Ирләр, ирләрдән соң қатыннар чақырдық. Урамаға кийемнәр китерәләр, қодағый киләде, киленнең анасы. Ул китергән кийемнәрне күрсәтәйәк булдылар.

### Ат кычкырту

**Ат қычқырту** *эстр.* исем кушу.

— Мулланы чақырып *ат қычқыртып* алабыз. Атсыз йатса, бала йылый диләр.

**Ат кыцкырту** *чст.*, **ат кычкырту** *хвл.* исем куштыру.

— *Ат кыцкыртырга* кирәг әле — *чст.* Бер ай тула ул балага да, *ат кычкыртабыз — хвл.*

### Ат кычкыру

**Ат кычкыру** *лмб.* исем кушу.

— Берәр атнадан сун инде ат кычкырырга җийыласың. Анда инде бабайлар йәшәсең. Ат кычкыра инде берсе, уки, азан кычкыра. Шал ад'ат бездә бар. Да, картлар буш бармый, бүләк илтәләр, тевеннәр белән барасын. Мин алкалар[3] пешереп илттем киленемә.

---

[1] зат — әйбер

[2] кийет — бүләк итеп бирелгән тукыма

[3] алка — кабартма

## Ат салдыру, ат салу

**Ат салу** *нокр.* исем кушу. Бала тугач исем бирмичә озак тотарга ярамый, баланы **әби** (нократ сөйләшендә ул мифологик образ — йорт анасы) **алмаштырырга мөмкин,** дип әйтәләр.

— Баланы тугач зак тотасы дегел, әби[1] алыштыра аны. *Ат саласы* тизерәк. Өч кендән артык тотасы дегел.

Мәләкәйгә[2] саласын баласын, *ат саласын*, салаwат[3] әйтәсен. Колагына кычкырасы эч тапкыр атын.

## Кендек аты

**Кендек аты** *хвл.* бала тугач вакытлыча бирелгән исем.

— Бала туwа, исемсез тормасын, *кендек аты* кушалар. Мулла китерәләр дә йакшы ат кушалар. Мулла кушкан исем белән гомер итә. Бусы кендек исме, ә бала йакшыргач, азанчы китереп исем бирә. Ике исем бирәләр.

## Урам аты

**Урам аты** *хвл., тмн.* кушамат.

— *Урам аты* белән ат'саң, бар да белә аны — *хвл. Урам атлары* монах буладыр — *тмн.*

## Исем атау, исем кушу

**Исем атау** *перм.*, **исем бирү** *лмб., том.*, **исем куйу** *срг.*, **исем кушу** *урт.д.*, **исем салу** *нокр.* исем кушу.

— *Исем атаганда* айателкөрси укыйм, колагына өрәм, җегерме тийен акча бирең тип сурап алам. Көмеш тәңкә бирмәгә кушкан «көмеш кебек нык булсын», — дип. Җитенче көндә исем атамага кушкан — *перм.*

— Бәбә тугач *исем бирәләр* бер йомадан[4] сун. Бутка була, аш-су, балага пударкылар[5] илтәләр, үмере булса, бала үсеп китә — *лмб.*

---

[1] әби — йорт анасы
[2] мәләкәй — мендәр
[3] салаwат — мактаулы догалар
[4] йома — атна
[5] пударкы [рус. подарок] — бүләк

— Балага *исем куйалар*. Ак мендәргә салып өстәлгә китереп куйалар баланы. Мулла исем куйа. Кан'әнисе баланы бишеккә сала, падаркы бирә бәбәй анасы кан'анасына — *срг.*

— *Исем салуны* картларны чакырып салдылар. Мулла исем сала. Йәнтәртемле[1] исемнәр салгаладылар, оланнарым йәнтәр-темле — *нокр*.

## Исем ашы

**Исем ашы** *том.* балага исем кушу мәҗлесе.

— *Исем ашында* кендек әбигә күлмәк алып бирә байырағы, йарлырағы йаулық бирә.

— *Исем ашына* туқмачлы аш пешерә. *Исем ашына* мулланы, қарчық-қорчықларны чақырабыз, қоръән уқытабыз.

## Исем кушу

**Исем кушу** *глз.:*

— *Исем кушканда* кыз алдыннан баручы[2] бабайга[3] бәй-ләwечләр[4] илтә, адийаллар илтә, күлмәкләр, тәбәгый, гебәдийә йасап китерә.

— *Исем кушкачтын* селге биреп, аш ашатып йибәрәләр.

**Исем қушу** *минз.,*
**азан белән исем қушу** *минз.:*

— Бабайлардан қалған ғадәт инде ул азан белән *исем қушу*.
*Исем қушқанда* изге теләкләр теләргә қушабыз.

Аллаһы тәғаләгә қол булсын,
Пәйғамбәребезгә өммәт булсын, —

дип исем қушабыз.

Өч мәртәбә қолағына салаwат әйтәбез.

Баланың миңе булса, җүшкәдән қашық төшереп *исем қушалар* ыйы. Миннегөл, Миннебай, Миннекамал исемнәре қушалар ыйы баланың миңе булса.

---

[1] йәнтәртемле — җанга ятышлы, ягымлы
[2] кыз алдыннан баручы — туйда кызны озатып баручы
[3] бабай — бәбәй
[4] бәйләwеч — бала чүпрәге

**Исем қушу** *к.-уф.:*

— Йүшкәне йаптылар белеки балаға исем кушканда, бал қаптырдылар. «Өй түбәне зимерегә килгән, мис түбәне зимерегә килгән», — диләр ийе. Тизерәк кенә бал қаптырыйғ әле дип, бал қаптырдылар Гөлсөм әбейләр.

Өстәлгә тишеп[1] салдылар да артаба исем қуштылар. Өй йаңғырап тора азан әйткәндә.

— **Исеме сығып китмәсен, шайтаннар-нимәләр кермәсен дип бөтөн нимәне йаба торғаннар ыйы, мөрҗә-йүшкәләрне, қапқа-ишекләрне йабалар ыйы**. Арта *исем қушалар* ыйы бабайлар килгәс. Өстәлгә сала да баланы, сәй эсмәс элек исем қушалар.

**Исем қушу** *төм.:*

— Исемнең қойтосын[2] қушыпсыс, йақшы исем қушмапсыс тим. Пер-ике қортқайақ цағырып йақшы исем қушың, тим. Пер-ике таба қоймақ қойа алмапсысмы әллә тип орошынып исем қуштырды мамапыс[3].

**Исеме килешү** *к.-уф.:*

— Қайсы бала сөйләшеп җибәрә әле исем қушқанда, **исеме килештисә.**

Менә шым ғына җатқан бала сөйләшеп китә, чыға да йоқлый. **Исеме килешә**, диләр.

## Азан чақыру

**Азан чақыру** *эстр.* азан әйтү.

— Баланың битен йабып мендәргә салып китерә. Кийездә баланың ата-анасы, мулла утыра, аwыл қартларын чақырады. Мулла баланы алып утырып *азан чақыра*, атын атайды. Мулла баланың уң қолағына қычқыра, суң қолағына қычқыра.

— Баланың қолағына қычқырып, *азан чақырып* әйтә атын қычқырып.

— Мулла чақырады, баланы йантыққа салып алдына акилеп салады мулланың. Мулла *азан чақырады*, баланың қолағына әйтәде исемен.

[1] тишеп — чишеп
[2] қойто — начар
[3] мамапыс — әбиебез

## Азанлашу, азан әйтү

**Азанлашу** *к.-уф.* исем кушу.

— *Азанлашқанда* мулла сақыралар, исем қушқанда, кендек әбейне дә сақыралар.

Бүкәнгә[1] менә шулай итеп бала мендәр[2] өстенә салалар. Артаба мулла азан әйтә. Азан әйткән кеше баланың башын үзенә қаршы қуйа.

Мендәргә сала да баланы қолағына исемен қысқыра, уқына. *Азан қысқырып* тора, уң қолағынан башлый әйтергә.

**Азан әйтү** *т.я.-к.т.:*

— *Азан әйтеп,* бишек тирәли «аллаһ әкбәр» әйтеп исем қушалар.Элек тә шулай, хәзер дә шулай исем қушалар.

## Исем кушу белән бәйле серле (магик) йолалар

**Исем аwыштыру, исем алмаштыру, исем бозу** *каз.ар., перм.* бала авырса яки миң чыкса икенче исем бирү.

## Миң чыкканда исем кушу

— Менә бала сырхау, күзен дә ача алмый. Тары бутқасы пешердек тә шуны пич алдына қуйдық тәлинкә белән. Чормаға менеп морҗадан қашық төшердем. «*Исемен алыштырам*, Миннегөл булсын», — дип қашық төшердем, саулығын бирсен, дип. Тары ботқасын чығарып қошларға бирә — *каз.ар.-лш.*

— Миң чықса симйәдә морҗадан қашық төшерә, пич алдына табақ белән ботқа қуйып шул ботқаға қашық төшерә. Менә шуның қашығы дип шул қашық белән ашаталар. Шуның миңе беткәнсе дип *исем алмаштырғаллар*. Аны вахыт белән алмаштыра, йә қар беткәнсе, йә йаз йиткәнсе дип *алмаштыралар*. Шулай исемен бозып баға торғаллар ыйы. Балада миң булса Миннәхмәт, Миңсылу исемнәре қушқаллар — *каз.ар.-дөб.*

— Сықтақ[3] булса әйтәләр, исеме килешми микән, диләр, исемен алыштырыйқ, диләр. Олосы қызнықы исемен алыштырдық — *перм.*

---

[1] бүкән — утыргыч, урындык

[2] бала мендәр — кечкенә мендәр

[3] сықтақ — елак

— Йылак булып мин. «Миңе бардыр», — дигәннәр, «исемен алыштыр», — дигәннәр. Минсылу салганнар исемне, Миңзифа, Миннехан, Минсапа салганнар йылак бала булса — *глз.*

### Қалы чыққанда исем қушу

**Қалы** *себ.* миң.

— Менә *қалы* цығады балаға. *Қалы* цыққан балаға қурасны суйып, аның қанын сөрткәле кәрәг икән. Андый ырмышлар пар. «Рәсимә-*Қалы*, Рәсимә-*Қалы*» тип қыцқырышатлар. Қалы исеме қушатылар. Менә битемдә күб иде минеке. Йаңы суйған малның қанын сөртү кәрәк қалыға. Исеме **Қалыстан, Қалпигә** булаты, *Қалы* тип паспуртыма да йасып қуйатылар.

— Қысыл нимәсе бар муйынынта, миң шикелле сурайып китәте. Ул қысға «**Миңқалыш**» тип қуйдылар атын. Алай Миңқалыш тип әйттергесе килмәй игән.

— Қалыстан исеме қуштылар, битендә қалы булаты қайсы балада. Қалы[1] — тирегә чыққан қысыл тап, миң була.

— Миңе булса, сәғиф булса, үсенә бойоролған исем тип, баланың башын мийескә[2] тығып, мөрчәтән[3] қычқыратлар.

### Балага ырымлы исемнәр кушу

**Себер диалектларында:**

Бала үлмәсен, **озын гомерле булсын**, дип:

— Берәүнең баласы гел үлеп торса, нық булсын тип**: Тимерали, Тимербикә, Тимербай, Тимерхан, Тимербәк, Нийазмехәммәт, Үлмәсбикә** тип исем қушқаннар. Бала үлмәсен, тип. **Таштимер, Ташпулат** тип тә қуштылар.

— Балалары үлеп торса, туқтасын тип **Туқтар** исеме қушқаннар. Қыз бала туса **Туқтабикә** дип исем қушқаннар.

— Мин оланнарыма **Туқтасын, Туқтар** қуштым, үлмәделәр, исән үстеләр.

**Ай исемнәре кушу — бараба диалектында:**

— Бала қайсы айда тыуған, ул айның исемен қуйғаннар: **Рамасан, Селхичә, Сәфәр, Рәчәп, Шәгъбан**. Қорман бәйрәмендә

---

[1] қалы [гар.] — миң

[2] мийес — мич

[3] мөрчә — моржа

тыуса **Ҡорманбикә**, малай булса **Ҡорман** дип исем ҡуйғаннар. Мәүлит айында туса **Мәүлиға** дип ҡуйғаннар.

**Җәнлек исемнәре кушу — бараба диалектында:**

— Бала ататырға дип килгәннәр. Тышҡа чығып ни күрсә, аны атап ҡуйғаннар элгәре. **Торна** китеп барамы, ҡарға очып барамы. Ҡарға күренсә — **Ҡарға**, чыпчыҡ күренсә — **Чыпчыҡ,** бүре күренсә — **Бүре**, эт күренсә — **Эт**.

— Пасҡараҡҡа[1] чығып паса, пала өйтә пулаты. Нәмә күренә. Сайысҡан күренсә — **сайысҡан** пулаты. Оҡмыш[2] менән пеләм.

**Тимер, Тимерүк** *т.я.-крш.* тимер кебек нык булсын, озын гомерле булсын дип кушалар.

— Бала тормаганга күрә
Тимер исеме куштык,
Тимерүк дип әйтәбез,
Гөрләп бара тормошлар.

**Тимерғали, Тимершәйех, Минтимер** *минз.:*

— Менә туғанымның баласы туды да үлде, туды да үлде. Шуңа күрә:

«Ныҡлы булсын,торсон», —

дип, Тимерғали исеме ҡуйдылар. Менә Фатыйма апаныҡына Тимершәйех ҡуйдылар. Йәшәп киттеләр балалар.

Ныҡлы була инде Тимер исеме ҡушсалар.

**Баҡый, Баҡыйа** [гар.] *баст.* озын гомерле булсын дип кушалар.

— Менә балалар туа да үлә, ҡайсы бер җәштән, ҡайсы ике җәштән. Мулла әйтә: «Баҡый исеме ҡушығыз». Ир бала туды — Баҡый ҡуштылар, ҡыз бала туды — Баҡыйа ҡуштылар. Баҡый да тере, Баҡыйа да тере — *баст.*

**Сатукай, Сатый, Сатыбал** — бер гаиләдә балалар тормаса, үлеп барса, аны икенче кешегә «сатып» бирәләр. Ул бала әлеге гаиләдә калса да, фәлән кешенең баласы дип йөртелә. Явыз рухларны алдау өчен башкарыла торган һәм Сатый, Сатукай, Сатылмыш исемнәре белән бәйле бу йола бик борынгыдан

---

[1] пасҡараҡ — баскыч башы

[2] оҡмыш — ишетү

килгән, чөнки әлеге исемнәр кабер ташлары язмаларында да чагылган (Юсупов, 1960, 107).

— Боларның биш балалары буған, бишесе дә үлгән. Бу туған, тағын үләр дип қурыққаннар. Әбисе мөрҗәдән қычқырған, икенчесе баланы күтәреп тәрәзәдән қычқырған «Сатам, аламсыз?» — дигән, өч тапқыр қычқырған. «Алабыз, — дигән, қақы ничә сум?» — дигән. «Биш сум ғына сорыйбыз, күп сорамыйбыз», — дигән. Менә қазер сиксәннән артып килә торған қарт инде шул Сатый, исемен Сатый қуйғаннар — *т.кам.-крш.*

**Әстерхан сөйләшендә:**

— Балаға үлмәсен дип **Сатыбал, Қомбат, Сөйөндек, Қуwандық** дип исем қушқан, **Туқтар** дип, туқтасын дип исем бирә. **Сатыбалды** дигән исем бар, алтмыштан артып китте менә, ул кеше менә алтмыштан чыққан.

Бала үлеп барса, озын ғомерле булсын дип**, Туқтамыш, Туқтар, Тимербулат, Туқтағол** қушалар. Бала таба да бала үлә. Шунда менә бәлки үлмәс дип **Туқтар, Туқтамыш** қуйалар.

— Тимердәй нық булсын дип **Балтабай** қушқаннар.

**Йаланбикә** *к.-уф.* яланда, ягъни кырда туган кыз балага шундый исем бирү булган.

— Инәм аwырайақлы, үзе йаланға эшкә киткән. Йаланда мине тыуған. Шуның өчен минеңә *Йаланбикә* тип исем қушқаннар.

**Әстерхан сөйләшендә** һәм **себер диалектларында** балага анасының, атасының, әбисенең яки бабасының исемнәре кушылган булса, балага исеме белән эндәшмиләр.

**Аққыз** *әстр.* әнисенең исеме кушылган балага шулай эндәшәләр.

**Ақбала** *әстр.* әтисенең исеме кушылган балага шулай эндәшәләр. — Әтийемнең исемен әтийемнең быратының баласына қушып қуйдылар. Ул да *ақбала* була.

Әй, *ақбала, ақбала,*
Ақ бозауны бақ бала...

**Атамац, Аташ** *туб.* атасының исеме кушылган бала.

**Инә, Инәкә, Инәч** *туб.* атамның инәсенең исеме кушылган бала.

**Инә мама** *туб.* инәмнең инәсенең исеме кушылган бала.

**Олата** *төм., туб.* атамның атасының исеме кушылган бала.

**Өннәкә, Өннәш** *төм., туб.* әбисенең исеме кушылган бала.

— Қарт атасы, қарт анасының исемен қушса, ул баланы **Олата** тиде, қыз булса, **Инәкә** тиде.

## ИР БАЛАНЫ СӨННӘТЛӘҮ

**Сөннә** — гарәп телендә: гадәт, йола, гамәл дигән мәгънәне аңлата, ягъни ата-бабадан килә торган гадәт, йола, риваять.

**Сөннәтләү** — мөселман культы законлаштырганча, ир балаларның җенес әгъзасы очындагы тирене кисеп алу гадәте.

«Ислам йолалары» китабында: «Сөннәт — пакьлек һәм сафлык билгесе булганлыктан, мөселманнар өчен фарыз, әмма дин күзлегеннән караганда катгый мәҗбүри түгел», — дип аңлатыла.

**Сөннәтче** < сөннәт+-че — сөннәткә утыртучы.

Җирле сөйләшләрдә бу сүзнең түбәндәге вариантлары билгеле.

### Аптал, әптәл

**Аптал, әптәл** (<гар. афтал) *себ.* — сөннәтче.

— Сөннәткә утызту[1] булған, *аптал* киләте мөселман иткәле. *Аптал* сөннәткә утыза тоған ыйы — *төм.*

— *Әптәл* киләте, сөннәткә утыстаты. Пешеренәтләр, чай эчәтләр. Пала-пақралар[2] керәте, алар ақча әпкерәләр.

— Аптал тигән Шәйхелислам әкәмне[3]. Аптал песнең төп тамыртан килә. Қарт атабыс[4], атабыс, әкәпес аптал булыпты. Әле дә чағырған йиргә барам —*төм.*

— Сөннәткә ир баланы аптал утыртқан. Әwәлеге муллалар аптал булып йөргән. Өц айлық паланы та утысқаннар, шәл-

---

[1] сөннәткә утызту — сөннәткә утырту

[2] пала-пақра — бала-чага

[3] әкә — абый

[4] қарт атабыс — бабаебыз

тептә[1] йатқан. Ицкем үлмәгән. Апталның сибеп йибәрә торган тәрүwе[2] пулаты — *тара.*

— Аптал бабай тип әйтәтеләр. Аны өй сайын йөртәтеләр аптал бабайны. Кемнең баласы бар сөннәткә утысқалы, цағырып алатылар ите. Қәсер ицкем йөрөмәйте.

«Менә аптал бабай килеп қуйыпты» тип әйтәтеләр.

«Аптал килепте» тип әсәрләнә башлайтылар ите — *төм.*

### Абдалцы, абдаллауцы

**Абдалцы** [гар. афтал+цы] *срг.* сөннәтче.

— *Абдалцы* бабай килеп йөрде, абдаллатып йөрде. Киләдә, рөхсәт сорый да керә, *абдаллый* иде. Церегән агацның wагын сибәләр иде абдаллатуцы бабайлар. Калын гына сибәләр дә куйалар иде. Шылай *абдалцы сөннәтли иде.*

— *Абдаллауцы* диләр,шылай ат'алар.

«Баланы *абдаллатырга кирәк*» дип ат'алар.

### Баба

**Баба** *әстр.* сөннәтче карт.

— *Баба* килә сөннәт туйда. Балалар қурқадылар:

*Баба* керер ишектән,

Балалар қачар тишектән, — дип әйтәделәр.

### Баба қарт

**Баба қарт** *к.-уф.* сөннәтче бабай.

— *Баба қарт* йөрде өй бөрөнә.

«Қуйан ат бирәм», — тей *баба қарт.* Шулай әйтә сөннәткә утыртқанда.

«*Баба қарт* қасан китерә қуйан ат?» — «Син терелгәс, син йөри башлағас», — тиләр балаға.

— Монда бер *баба қарт* йөргән ийе, сөннәткә утырта торған ыйы. Безнең үзебезнең ум бала асырап әнейебез үлеп китте, биш малайны баба қарт сөннәткә утыртты.

*Баба қартлар* булды алар. Элек *баба қартқа* бер бөтен түгәрәк әпәй бирәләр ийе, хәйерен бирәләр — *к.-уф.*

---

[1] шәлтеп — бишек
[2] тәрү — дару

## Бабачы

**Бабачы** *т.я.-к.т.* сөннәтче карт.

— *Бабачы* Қошман аwылыннан киләдерийе.

«Қошман — малайларға дошман», — дигәннәр. Малайлар қурқып торалар ыйы бабачы килә дийеп. Бабачыға күлмәк бирделәр ийе.

«Бабачы сиңа чалбар кисә», — дип әйтәдерийек.

## Бабачы бабай

**Бабачы бабай** *минз.* сөннәтче карт.

— Элек *бабачы бабай* килеп йөридер ийе, сөннәткә утыртып китәдер ийе ул балаларны.

Менә шишмә безнең бақча эчендә генә. Ул шишмәгә бер *бабачы бабай* киләдер ийе. Ул үзенә бер түбәкәй[1] таш җыйып китәдер ийе шул шишмә башында. Ап-ақ таш ул, бер түбәкәй җыйып аладыр ыйы шул ташны. Шул ташны қырып, имгә җарый дип әйтәләр ийе — *минз.*

## Бабалату

**Бабалату** *нокр.* сөннәткә утырту.

— Қәзер инде бездә бер дә *бабалатмыйлар*. Минем улымны Ғали бабач *бабалатты.*

## Бабаға бирү

**Бабаға бирү** *к.-уф.* сөннәткә утырту.

— Баба қарт килә. *Бабаға бирәләр* дүрт йәшендә. Қайсы кеше баланы өч-дүрт, қайсы алты йәшендә *биргән бабаға*.

**Бабаға бирү** *т.я.-к.т.* сөннәтләү.

— Бабаға бирәсе бар, дигәннәр. Баланы бабаға бирергә тийеш *сыңарлы йәштә:* өчтәме, биштәме, җидедәме. Парсыз, сыңарлаш йәштә бирәләр.

— Малайларны бабаға бирәләр дә инде, ул чағында дару җуқ. Бабаның йанчығында туйыра эчереге буладырыйы, сибәләр ийе шул туйыра эчереген. Бездә *туйыра*, сез аны *имән ағачы* дип әйтәсез.

---

[1] түбәкәй — түбәтәй

Туйыра эчереген уwалар ыйы он кебек иттереп, йә иләктән илиләр, менә шуны сибеп сөннәтлиләр ийе бабалар.

Туйыра безнең урманда бик күп, эчергән туйыралар да күп. Җыгылган туйыра эчери ул. Җыгылмаса, җыгалар да урманда, аның эченнән эчереген кушучлап алалар, киптерәләр дә илиләр аны. Он шикелле була ул, қызыл төстә була. Аны җанчыққа җыйып, җанчық тутырып җөриләр ийе бабачылар, сөннәтләүчеләр. Менә шуның белән, туйыра эчерег белән қутырлый да, тиз генә қубып та төшәдерийе.

— Малайларның муйыннары пешегеп китсә дә шул туйыра эчереген сибәләр ийе.

«Бабаға бирәбез, сине мулла итәбез», — дип әйтәләр ийе.

## Сөннәт баба

**Сөннәт баба** *минз.* дога багышлаганда искә алына.

*Сөннәт бабаларыма*,
Нигезләре таралмыш,
Исемнәре йуғалмыш булған,
Доғаға мохтаж булып йатқан
Әрwахларыбызға дип бағышладым.

## Сөннәт паба

**Сөннәт паба** *тара.* сөннәтче карт.

— Пала сықтаса *сөннәт паба* паланы маңлайыннан йышып-йышып уқыйты үсенекенцә. Пала йоқлап китәте.

## Сөннәткә утырту

**Сөннәткә утырту** *к.-уф.:*

— Сөннәткә утыртып йөри бер баба қарт.

«Кемнәрнең уланнары бар, сөннәткә утыртабыз», — дип.

Баласы бар кеше кертте баба қартны, сөннәткә утыртты баласын. Хәзер бал'нискә баралар қый.

Баба қартның даруы булмады, ул ағас сереген йөретте. Шуны сибеп сығып китә. Аны иләп қуйған була ағас сереген. Сийә қушып китә, беткәнсе шуны сибеп тор, дип. Йарады микә, килеште микә wы, нәстә булғандыр. Килешмәсә йөретмәс ийе инде, килешкәндер қый.

### Сөннәткә утысту

**Сөннәткә утысту** *төм.* сөннәткә утырту.

— Элеке саманта унике йәшкәцә *утыса* тоған ыйы *сөннәткә.* Аптал *утыса* тоған. Қулы йеңел була тоған.

— Балаларға қалтацықлар тегеп пирәтләр. Ақца *пирәтләр сөннәткә утысқанта.* Үсенә әйбер алатлар ул ақцаға.

— Қәсер аптал килмәйте ғуй, аптал йуқ кәсер. Песнеңке ике малайыпысны *утысты* аптал. Қотағайым белән апкердек тә *утыстық.* Апталға әйттем, оллы паланы да *утысың*, тидем.

### Сөннәт салу

**Сөннәт салу** *том.* сөннәткә утырту.

### Сөннәт салучы

**Сөннәт салучы** *том.* сөннәткә утыртучы.

— Сөннәт салдылар малайларға. *Сөннәт салучы* бабай чапан кигән, башында кәпәч.

**Себер диалектларында** сөннәтче картның — **апталның** тавыш чыгарып барабан сугуы турында мәгълүматлар сакланган.

### Тип, төмбер күнәк

**Тип, төмбер күнәк** *төм.* барабан формасындагы әйбер. Аптал аны үзе белән йөрткән, дөпелдәтеп тавыш чыгарган, баланың игътибарын шуңа юнәлдергән.

— Апталның үсенеңке *тип* булған, иләк шикелле нимә. Төп–төп–төп суғаты сөннәткә утысқан wақыт. Имән ағачтан пулған ул *тип.* Қәтерләп йөрткәннәр мендәргә генә утысқаннар аптал бабайны.

— *Төмбер күнәк* тотқан аптал паланы алдаштырғалы. Сөннәткә утысқан.

— Пала йыламасын тип тубалны шаңғыртатып суғаты, пала шуны ишетеп, сығытын[1] қуйыпты, сөннәткә утыстуны пелмәй қалаты. Шуның патнусына ақца ташлай тоған ыйы. Уқымышлы аптал булған. Тубалына ақца ташлай тоған ыйы.

— Қарт аптал пала йыламасын тип патнусны суға тоған шықыртатып. Аптал сөннәткә утыса тоған ыйы.

---

[1] сығыт — елау

— Апталлар Иртеш йақтан киләтеләр ите. Апталнықы суға торған *тип* була тоған ите. Сөннәт туйда мин Туқтасын атлы паласына партым. Қарындық тартқан шикелле түгәрәк нимә булаты апталнықы, аптал суға тоған төп-төп итеп.

## ИР БАЛАНЫ СӨННӘТКӘ УТЫРТУ УҢАЕ БЕЛӘН УЗДЫРЫЛА ТОРГАН МӘҖЛЕСЛӘР

### Пике keләве

**Пике keләве** *тмн.* пәке keләве, сөннәткә утырту уңае белән уздырыла торган мәҗлес.

— Атна кич көнне *пике keләвенә* килделәр ат'икам[1], ан'икам[2].

### Сөннәт қатымы, сөннәт қатым қуцасы

**Сөннәт қатымы** *тара.* баланы сөннәткә утырту хөрмәтенә уздырыла торган дини мәҗлес.

— Паланы сөннәткә утыртқан сун *сөннәт қатымы* пулаты.

**Сөннәт қатымын уқыту** *тара.* баланы сөннәткә утырту хөрмәтенә уздырыла торган дини мәҗлестә коръән укыту.

— *Сөннәт қатымын уқытабыс*, күрешеләр керәте. Мулла уқыйты туwаларын. Пашлықлар ийылышып утыратылар, цай эцәтеләр. Кем ақца, кем пүләк алып киләте.

**Сөннәт қатым қуцасын уғыту** *тара.* баланы сөннәткә утырту уңае белән уздырыла торган мәҗлестә коръән укыту.

— *Сөннәтнеке қатым қуцасын уғытқалы* кәрәк. Пала тис саwайаты, таса пулаты.

— *Сөннәтнеке қатым қуцасы* ике пулаты. Аш тайарлап утысатылар, кийем-китә алып килмиләр, ақца ғына пирәтеләр.

### Сөннәт keләве

**Сөннәт keләве** *кузн.* баланы сөннәткә утырту уңае белән уздырыла торган мәҗлес. — *Сөннәт keләве* бик хыват[3] була иде, олымның улы тугачтын *сөннәт keләве* йидык.

---

[1] ат'икам — әткәм

[2] ан'икам — әнкәм

[3] хыват — куәтле, көчле

### Сөннәт қотлоқ, сөннәт ақца

**Сөннәт қотлоқ** *тара.* баланы сөннәткә утырту уңае белән котлап бүләкләр һәм акча алып килү.

— *Сөннәт қотлоққа* керәтеләр, кем ишетә, кем күрешеләре, туған-тоқомнары. Паланықы паш оцона пер тарилкә утысып қуйатылар. Кем ақца, кем күкәй, кем перәннек қуйаты. Мин пиш паламны та утысқан сөннәткә, *сөннәт қотлоққа* күп керәтеләр.

— Паланықы йанындағы өстәлгә кем күпме ақца ташлый, сөннәт ақца тип.

### Сөннәт қалта, сөннәт қалтацық

**Сөннәт қалта, сөннәт қалтацық** *төм.* сөннәткә утыртылган балага бүләк итеп тегелгән янчык, аңа хәл белергә кергән кешеләр, малайны котлап акча салганнар.

— Әwәле сөннәткә утысқан малайға чуқлап-чуқлап қалта теккәннәр, қалтацық тибес. Сөннәт қотлоққа кергән геше шул қалтаға ақча салып чығып китеп утырғаннар. Сөннәт қалтаны малай муйынына элеп қуйып утырған төсәлә башлағач. Кергән бер кеше ақчаны сөннәт қалтаға төшереп утырған. Сөннәткә утысқан малайға күп ақца ийылған.

— Сөннәт қалтасы булатоған ите. Аның қалтасында ақца сала тоғаннар ите. Шалай сөннәт қалта тегеп қуйатығаннар ите көйәсләп. Пала шал қалтаны ошлап утыраты, кергән бер кеше шал сөннәт қалтаға ақца салаты, сөннәт туй тип керәтеләр — *төм.*

### Сөннәт бар'амы

**Сөннәт бар'амы** *срг.* ир баланы сөннәтләү хөрмәтенә уздырыла торган мәҗлес.

— Абдалцы килә, оланның пипийенең башын гына кисеп ал'андыра, сөннәтли. Имән цереге сибә. Сөннәт бар'амы дир, аш пешерәсең, цай куйасың, күрешеләрне йәшәсең, хайырын бирәсең. Элек беркемгә белгертмәгән сөннәт бар'амын — *срг.*

### Сөннәт туй

**Сөннәт туй — әстерхан сөйләшендә:**

**Сөннәт туй** — көрәшле туй дигәннәр, ул да инде тимә бер кешедә түгел, аwылның байы ғына йасаған көрәшле сөннәт туйны.

— Минем балама алты йәш булғанда бер йылқы[1] суйып *сөннәт туй* йасадық. «Хушаwаз[2] әйтеңез, әwи[3] әйтеңез» дип утырадылар кимперләр. Менә шул *сөннәт туйында* җырладылар, хушаwаз да әйттеләр, әwи дә әйттеләр. Қайнанам бар иде, *сөннәт туй* йасадық.

— Әзилдә *сөннәт туйда майдан йасағаннар*. Анда инде *атчабышлар, көрәшүләр* булған.

— Баланы *сөннәткә утызғанда* килгән туған-тохомнар бер шунтайға[4] ақча салады, шуңа қарап бала йылаwын онотады. Ақчаға қызығып китәде. Бөтен-туған қәрдәш балаға кийемнәр аладылар.

— *Сөннәт туйға* өлкән үгез суйып, атлар суйып, турамчылар[5] турап қуйа түрдә утырған халықларға, мәлбәкләргә[6] салып қуйа.

— *Сөннәт туйда* ақча чәчәләр. Баланы сөннәтләмәс борон кийендерәләр, күрсәтәләр. Сөннәтләнгән балалар тәрәзәнең төбендә тораддар тәрәзәгә қағып. Ишекләрен қағып торадылар, ау-ау қычқырып. Бала алданып қала аларға қарап, кискәнен белми қала.

— *Сөннәт туйда* көрәшле, ат йарыш белән була. Туған-тохом килә. Хәйерле булсын йаси.

— Баланы *сөннәткә биргәндә* атақлы көрәш дип әйткәннәр, далаға чығып көрәшкәннәр. Бәйге дип әйтәләр, башқа аwыллардан көрәшчеләр җыйылған. Қайсы қуй биргән, қайсы қара мал (сыер) биргән. «Алтын қабақ ачабыз» дигәннәр. Баған[7] башына манит тағып, шул манитқа мылтықтан атқаннар. Атларға төрле линталар таққан, бизәгән атларны. Баланы арбаға утыртып қыдыртып[8] йырлашып баралар арбада. Шул көнне баланы сөннәтлиләр. Ул көрәштә қара мал[9] аламы, қуй аламы, муллаға

---

[1] йылқы — ат
[2] хушаwаз — җыр
[3] әwи — җырлап, көйләп әйтелә торган теләкләр
[4] шунтай — букча
[5] турамчы — ит
[6] мәлбәк — тәлинкә
[7] баған — багана
[8] қыдыртып — чабышып
[9] қара мал — сыер

биргәннәр, үзенә йуқ. Қайсы йақ җиңә, шул йақның мулласына биргәннәр. Чит аwылларға да хәбәр биреп чақыра йөргәннәр.

## Сөннәт туй

**Сөннәт туй** *себ.* баланы сөннәткә утырту хөрмәтенә уздырыла торган мәҗлес. Уйын, көрәшләр, ат чабышлар була.

— Унике йәшкәцә сөннәткә утысқаннар. Қалық йийылаты, атын цаптыраты, кешене көрәштерәте. Шулай атақлы туй қылған.

— Сөннәт туйда ат цаптырғаннар, атқа линте бәйләгәннәр. Аңа көмеш теккәннәр. Сөннәт туй пороннан қалған нәстә.

— Кеше йүгерткәннәр. Йүгергәннәргә йүлте[1] биргәннәр, бүләк. Сарық суйалар, аш пешеренәләр. Сөннәт туйына дип қартларны чақыралар.

— Сөннәт туйда бала уйнату булған. Қалық йийылып утырған, тақталар тесеп қуйған. Баланы күтәреп уйнайты. Әрбер кеше баланы уйнатып ақча элеп утыраты. Көрәш булаты. Қучқар[2] суйа, нийәтлек[3] суйа.

— Сөннәткә утыссалар сөннәт туйы булатоған ите. Кем қуй, кем тере қас күтәреп керәте.

Минең қайнанамның килентәшен ирем әйтәте:

«Әйнәм тере қас күтәреп кергән мине сөннәткә утысқанта», — тиде. Әйнәм тип әйтәте инәсенең килентәшен — *төм.*

## Сөннәт туй, сөннәт қатымы

**Сөннәт туй, сөннәт қатымы** *төм.* баланы сөннәткә утырту хөрмәтенә уздырыла торган дини мәҗлес.

— Бөтен аwылны цақырып қорән уқытқан, *сөннәт қатымы.* Қатым қуча тигән. Қунақларны сатқац[4] малайны сөннәтләгән. Сөннәтче аптал утырткан сөннәткә.

— *Сөннәт қатымы* тип қатым уқыталар.

«Исәнлеккә-саулыққа» — тип.

---

[1] йүлте — бүләк

[2] қучқар — тәкә

[3] нийәтлек — корбан итеп суела торган хайван

[4] сатқац — озаткач

**Сөннәт туй, сөннәт қатымқуча** *тара.* баланы сөннәткә утырту хөрмәтенә уздырыла торган дини мәҗлес.

— *Сөннәт туй* йасыйлар, қатымқуча уғыталар, өстәл тайарлыйлар. Ике *қатымқуча* уғыйлар сөннәт туйда.

**Сөннәт қатымқуча ниятләүләре** *тара.*

Илаһи нийәт қылтым
Бу қатымқучаның доғаларын уқымаққа,
Тән wә җан сәләмәтлегенә,
Дөнйа wә ахирәт өчен
Қабул иткәй идең,
Қоръән нуры белән нурландырғай идең.

Фатиха сүрәсе йете мәртәбә уқыла, ихлас сүрәсен уқыйбыс, салаwат уқыла.

*Сөннәт қатымқучада* теләкләр теләп уқыйбыс, қуйлар суйатылар.

## Сөннәт теләү

**Сөннәт теләү** *төм.* баланы сөннәткә утырту уңае белән үткәрелә торган дини мәҗлес.

— *Сөннәт теләүне* абтал баба килгәц усқаратылар, қоръән уқытадылар, қатым. Баwырсақлар, туғацлар, шәңкәләр қылатылар, қунақлар цақыратылар.

Аwылға аптал бабай киләте балаларны сөннәткә утысқалы. Баланы сөннәткә утыса, сөннәт теләү йасайтылар. Сөннәт теләү тип қуй суйатылар, кәртүк шәңкә[1], туғац[2], қоймақлар пешерәтеләр.

## Өйәр қыцқыру

**Өйәр қыцқыру** *туб.* сөннәт туйда акча җыю.

— «Өйәр, өйәр, менә сиңә шал хәдәрле», — тип ақца салатылар. Иләк сынлы саwыт ошлап қуйатылар, шанта әргем ақца сала тоған ите. Аптал йийып алаты сөннәт туйда ақцаны. Ул аны сөннәткә утысқан балаға бирәте.

---

[1] кәртүк шәңкә — бәрәңге пәрәмәче
[2] туғац — күмәч

## БАЛАНЫҢ ҚЫРЫҚ КӨНЕ

Балага кырык көн тулу һәртөрле тылсымлы, серле йолалар белән үткәрелгән. Гомумән, кырыгы тулганчы баланы ялгыз калдырырга кушмаганнар. Төрки халыкларда кырык саны төгәл сан гына белдермичә, әйберләрнең күп булуын да күрсәткән булса кирәк.

Борынгы төрки-шаманнар тормышында, кырык, дини сүз буларак, зур роль уйнаган һәм ул тора-бара динилек мәгънәсен югалткан, тик күплек төшенчәсен белдерүче булып кына калган. Халык авыз иҗатында һәм фразеологиядә кырык (күп, бик күп төшенчәсенә беркетелгән килеш) сүзе бик күп кулланылып килә: *кырык юлбасар, кырык көнлек туй, кырык кыз* һ.б.

Татар теленең себер һәм әстерхан төбәгендәге сөйләшләрендә баланың кырыгын үткәрү йолалары бигрәк тә кызыклы борынгылыклар белән үрелеп бара. Биредә *кырык* сүзе белән бәйле ашамлыклар, йола үтәү предметлары да искә алына.

### Қырығы, кырқы

**Қырығы** *каз.ар., минз.* балага кырык көн булу.

— Қырығы тулмайынчы бер үdeн қалдырмыйлар баланы. Қалдырыш түгел ийе берүdeн.

«Җен алмаштыра», — дип.

— «Қырығына хәтле баланы ташламағыd, өстенә бер тимер қашық булса да қуйығыd», — диделәр.

— Баланың *қырығы* тулғанчы бишегенә қадақмы, пычақмы, қайчымы қуйалар.

«Җен алмаштырмасын өченгә» — *минз.*

**Қырқы** *әстр.* балага кырык көн булу.

— *Қырқына* чийен[1] баланы сақламаға қуша. Җен алыштырмасын.

— Баланың бишегенә пычақ салады, қайчы салады, қоран салады. Җен алыштырмасын дип салады.

[1] чийен — кадәр

— *Қырқына* тийен[1] бала йуwындырған суны да үсеп торған тирәк төпләренә түгә булғаннар, йә бер дә айақ басмый торған җирләргә чоқыр қазып күмә булғаннар.

## Қырқы тулу көне

**Қырқы тулу көне** *этн.* балага кырык көн булгач, төрле ырымнар, йолалар үтәү, юындыру һ.б.

— Баланың *қырқы тулу кене* ул бер қуаныч булған. Ул көнне су йылытып, балаға қырық қашық су әзерләгәннәр. Ул суға сары йарма[2], тары йарма салып қойондырғаннар, салаwат әйтеп. Шул қырық қашық су белән қойондырып алған.

## Қырқыннан чығу

**Қырқыннан чығу** *этн.* балага кырык көн тулып китү.

— Қырықламасын қойған, йуындырған мамайны ыриза иткәннәр. Шулай итеп *бала қырқыннан чыққан.*

— *Қырқыннан чыққанчы* бәбәй туған хатын-қызны аш-суға җибәртмиләр. Қырқыннан чыққанчы қазан-айақ астырма җарамайды.

## Қырықламасын қойу

**Қырықламасын қойу** *этн.* баланың кырык көнендә төрле йолаларны башкару: *қырық баwырсақ, қырық қашық су, қырық көн, қырық айақ, қырықламасын қойған айақ* һ.б. искә алына.

## Қырық қашық су

**Қырық қашық су** *этн.* балага кырык көн булгач, ырымлап, кырык кашык су белән юалар.

— Қырықламасын қойғанда қырық қашық су белән чайқандыралар баланы.

— Қырқында килеп йуwындырады мамай. Қырық қашық су белән, тоз салып, йарма салып йуwындыра.

— Баланы қырқында қырқ қашық су белән қойондыра, йарма суы белән қойондыра, тәненә бер зат чықмасын.

---

[1] тийен — кадәр

[2] сары йарма — тары ярмасы

— Қырықламасын қырқ көннән суң қойабыз, алдан җуындырып алады, ана сун қырқ қашық су белән баланы башына қойоп чайқандырады.

### Қырық айақ су

**Қырық айақ су** *этр.* балага кырык көн булгач, ырымлап кырык аяк су белән юалар.

— Қырық көнгә қадәр мамай[1] йуындырған баланы. Қырық көне тулғач инде анарға қырық айақ, йә қырық қашық су белән йуwындырғаннар.

### Қырықламасын қойған айақ

**Қырықламасын қойған айақ** *этр.* баланың кырыгы тулган көнне юындырганда су коеп тору өчен файдаланылган савыт. Аны изге, тылсымлы дип әйтеп, үлгәч юганда су салып тору өчен дип җыеп куялар.

— Җанға айақтан қойа суны қырқламасына, қырқ қат қойа. «Қырқламасын қойған айақ йахшы айақ, үземә торсон, үзем үлгәндә ул айақ белән су қойарсыз өстемә», — дип алып қуйа қырқламасын қойған айақты.

### Қырық уймақ су

**Қырық уймақ су** *этр.* баланың кырык көнендә пешерелгән вак күмәчләр. Бер күмәчне, ырымлап, этнең муенына тагып җибәрәләр.

— Қырық көннең кал'акайы диде. Кал'акай пешерә дә пирбуй кигән көйләген дә, кал'акайны да этнең муйынына тағып җибәрә. «Баланың эт ақылы китсен».

### Қырық баwырсақ

**Қырық баwырсақ** *этр.* баланың кырыгы тулган көнендә пешерелгән бавырсаклар. Аны балаларга өләштерәләр.

— Қырқына йуwындырмаға килгәндә кендек мамама дип қайнанам қырық баwырсақ пешерә торған иде, шул қырық баwырсақны мамам балаларға өләштерә торған иде урамға чығарып. Балабыз қырықыннан чықты дигән зат инде бу.

---

[1] мамай — әби

## Қырық көне

**Қырық көнендә көйләгән талға элеп қуйу** *себ.* баланың күлмәген талга элеп кую.

— Балалары тормаса, үлеп утырса, көйләген талға элеп қуйаты қырық көнентә — *туб.*

## Қырық туқац

**Қырық туқац** *том.* баланың кырыгы тулган көнне пешерелә торган күмәчләр, алар кырык булырга тиеш.

— Қырықлары булған, *қырық туқац* пешергән. Әрбер нәстә қырығар. Кеше сайын берәр туқац.

## Қырық бутқа

**Қырық бутқа** *төм.* баланың кырыгы тулган көнне пешерелә торган ботка. Мәҗлес ясап туганнарын, күршеләрен чакыралар.

— Қырықы цыққанта балаға *қырық бутқа* пешерәтләр. Ашарлық булса, нинтәй йарма да йарай.

— *Қырық бутқа* тип бутқа пешереп мамалар[1] цағыратлар ыйы элек. Қырықы көнентә пешерәтләр, манныймы, көрөс бутқамы[2], питай йарма бутқамы[3]. Қул тирмәнентә[4] тартып. Шал қул тирмәнебес әле дә исән. Шаннан йарма тартып, *қырық бутқа* пешереп ашадық. Күрше-тирәдәге қортқайақларны, инәлек әбине[5] цағыратлар *қырық бутқаға. Қырық бутқада* туқац та, шәңкә тә булаты, баwырсақлар булаты.

## Қырық теләү

**Қырық теләү** *төм.* баланың кырыгын үткәрү мәҗлесе.

— *Қырық теләүне* өц балацығыма да усқардық. Қырық бутқасын бешереп, инәлек қортқайақны[6] цағырдық цай эцкәле.

---

[1] мамалар — әбиләр
[2] көрөс бутқа — дөге боткасы
[3] питай йарма бутқа — бодай ярмасы боткасы
[4] қул тирмәне — кул тегермәне
[5] инәлек әби — кендек әбисе
[6] инәлек қортқайақ — кендек әбисе

## Қырық кеше

**Қырық кеше** *төм.* баланың кырыгы тулу хөрмәтенә чакырылган кунаклар. Алар кырык булырга тиеш.

— Қырықлары булған. Қырық туқац пешергән, қырық шабала[1] әсерләгән. Әрбер нәстә қырығар. Әрбер туғаннары киләте. Қырыққа тулсын кеше.

## Қырықлау

**Қырықлау** *том.*, *төм.* баланың кырыгын үткәрү, йолалар үтәү.

— Қырықлауга туқац пешерә wағырақ қына итеп кеше сайын берәр — *төм.*

— Қырығында қырықтайлар, башыннан қозоқ[2] қойатлар мамасы йә инәсе. Баланың қырығы дип көлешеп чәй эчәләр. Қоръән уқыта тоғаннар, қартлар йерә тегән. Айда ун көн булса қырықтайлар, кәнфит қойатлар — *том.*

## Қырық шабала су белән қырықлау

**Қырық шабала су** *төм.* кырык кашык су. Баланың кырыгы тулган көнне ырымлап юындыру.

— Баланың қырығы булса, инәлек қортқайақ қырықлый баланы. *Қырық шабала су* белән йуwындыра. Қатым[3] булаты.

— *Қырық шабала су* белән башыннан чайқайсың аны.

«Осон ғомерле булсын, киң әүләтле булсын», — дип. Пүләк менән баралар қырықлауға.

## Қырығы йитү, қырығыннан чығу

— Қырығы йитсә малай берас қатығып китә, көлә башлый. Қырығына хәтле малайны кешегә күрсәтергә йарамый, аны инде чаршау қорып йоқлатасың. Қырығына хәтле бик сақлағалы кирәк — *төм.*

---

[1] қырық шабала — кырык кашык
[2] қозоқ — кедр чикләвеге
[3] қатым — дини мәҗлес

## Эт көйләге, эт күләге

**Эт көйләге** *себ.*, **эт күләге** *эстр.* баланың кырыгы тулганчы кигән күлмәге. Кырыгы тулган көнне аны салдырып, эт муенына бәйләп җибәрәләр.

— Қырығы цыққынцы кийескән көйләкте эткә кийесеп йибәргән, *эт көйләк* тип, этнең пашына эләте. Аннан сун кигән көйләген олоғайғанцы кийескән тә йуып салып қуйған, тағын бала тапқац, тағын кийескәле. Мин йетте ир бала асыраған — *себ.*

— Балаға қырқ көн тулғанда туғач пешерәт, туғачты, күләкте эттең муйнына бәйләп җибәрәт. «Эт ақылы китсен», — дип.

— Қырқламасын қойа, җуындыра, шул җуындырғанда салған күлмәгенә түгәрәк кал'акай пешереп, уртасын тишеп, этнең муйынына бәйләп җибәрде. Баланың начар, эт ақылы китәде, җаман қолоқлары китәде — *эстр.*

— Қырық көн тулғаннан соң эт ақылы китсен дип иң беренче кигән күлмәген ала баланың, түгәрәк кал'акай пешерә. Шул кал'акайны күлмәк белән этнең муйынына бәйләп җибәрә. «Қырқыннан чықты, эт ақылы китсен», — дип тағып җибәрә. Кендек абасы[1] баланы җуwындыра.

«Баласы начар кешенең ата-анасын
ат өстендә торса да эт тешли», — ди.

Ул инде эт тешләми, менә синең балаң начар, ғадәте менә ничек дип әйтсә, шуны эт қабу дип санағаннар — *эстр.*

## Кочок күлмәге

**Кочок күлмәге** *влгг.* баланың кырыгы тулганчы кигән күлмәк. Аны серле, тылсымлы көчкә ия дип, им-томнарда файдаланганнар.

— Кочок күлмәге дип әтәләр, олан тугач кырыгына чике кигезәләр. Күлмәкне печәләр, изүе ачык. Шуны кигезәләр оланга, кочок күлмәге дип.

— Шыны, кочок күлмәген әнийем сакли иде. Ун олан әнийем туды. Олан аурый башласа, шыл кочок күлмәген оланның күкрәгенә куйа иде. Сандыгында саклады кочок күлмәген.

[1] кендек абасы — кендек әбисе

## БАЛАНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЧӘЧЕН АЛУ

### Қарын чәче

**Қарын чәче** — баланың туганда ук булган беренче чәче. Аны кадерләп җыеп куйганнар.

**Тау ягы сөйләшендә:**

— Баланың чәчен алабыз да әйтәбез:

Эзләгәндә анық бул,
Сорағанда танық бул, дибез.

— Беренче чәчен бөтү[1] йасап таққаннар баланың үзенә, хаситәгә таққаннар. Күзсенсә чәчен чайқап эчергәннәр — *т.я.-трх.*

**Әстерхан сөйләшендә:**

— Бала туғандағы *қарын чәчен* қырығы чыққанда аласың **да қағазға салып бәйләп қуйасың**. *Қарын чәчен* йуғатырға қушмыйлар бездә.

— Пирбуй *қарын чәчен*, анадин туған қарын чәчен алып, ақ чеперәккә төйнәп, **бишек башына асып қуйалар иде**.

### Қарын сәсе

**Урта Урал — к.-уф. сөйләшендә:**

— Иң элеке *қарын сәсе* белән бергә төшкән кендеген дә җыйып қуйдылар. Иң элеке қарын сәсен бәрмәделәр.

— *Қарын сәсен* алдылар баланықы иң элеке қарын сәсен. Аны бөтү итеп тақтылар.

### Қарын цац, қарын чәч

**Тубыл-Иртыш диалектында:**

— Пороңқы кеше *қарын цацны* ташламаған, сантықта сақлайты.

— Қырық көн тулғац алып қуйатлар цацын. Қырық көнлек цацны алмаса, баланың башы аwырулы булаты. Қалдырыға йарамайты цацны. Цацын алып, арғалық йегенә[2] қыстыратылар ақ цеберәккә бөреп.

---

[1] бөтү — бөти

[2] арғалық йеге — матча ярыгы

— Мамай ақ чеперәккә урап салып қуйады беренче қарын чәчен. Бала аwырып китсә, берничә бөртек чачын алып, йандырып иснәтә, даwа булады — *туб.*

**Бараба диалектында:**

— Баланың қырығы чыққанчы чәчен алып, кендеге менән бергә сәңгелчәккә[1] баwына тегеп қуйаты. Аны йуғалтырға йарамый.

**Волгоград сөйләшендә (мишәр диалекты):**

— Кырыгында оланның карын чәчен алалар, чәчен йандырып им итәләр. Чәчен йандыралар чашкыга салып, чашкы кыругында оланны йөретәләр.

«Адәм йанми, чәч йана.
Төрле бәлә-казалардан оланны сакла».

Әби-бабай йоласы, мин шыларга ышанам.

## БАЛАНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЧӘЧЕН АЛУЧЫЛАР

### Чәч анасы, чәч әни

**Чәч анасы, чәч әни** *кас., миш.д.* баланың беренче чәчен алучы хатын-кыз.

— *Чәч анасы* беренче чәчен ала, чәч әни ди бала анарға — *кас.*

— Бала тугач чәче белән торса бик йылавык була. Туган чәче белән тормасын, чәчен кыркырга кирәк. Йегетнең сеңлесеннән, атасының радн'асыннан кыркыталар. Анарга бүләк бирергә кирәк. Аны *чәч әни* әйтәләр. Йөзег үтә генә кисәләр чәчне. Менә мин үзем *чәч әни* булдым, ике күз темәләрем, багып та туйа алмим ыланнарымны — *кузн.*

### Чәчи бабам

**Чәчи бабам** *бараба.* баланың беренче чәчен алучы ир кеше.

— *Чәчи бабам* этидән олосы, әкәсе.

---

[1] сәңгелчәк — бишек

### Чәч инәм

**Чәч инәм** *бараба.* баланың беренче чәчен алган ирнең хатыны.

— Чәчинәм — чәчи бабамның пичәсе.

### Зур әтисе

**Зур әтисе** *әстр.* баланың беренче чәчен алучы ир кеше.

— Қырқында йуwындырыр алдыннан қырық көнлек чәчен алғаннар. Зур әтисе ала ул баланың чәчен. Ул кеше кечкенә йәштә булса да *зур әтисе* дип әйткәннәр.

[Ырым]: Баланың чәчен сакаллы-мыеклы кешедән алдыралар — *әстр.:*

— «Сақаллы-мыйықлы кеше алсын чәчне, чәче қуйы булып чықсын», — диләр. Қарт кешедән алдыралар ырым итеп. «Қарт булсын, аның җәшен бирсен», — диләр.

— Баланың чәчен алдырырға нәғашенә китәте, анасының энесенә. Кийетен алып барады. Нәғаше қарын чәчен алады қырықыннан чыққан сун. Қарт кешедән алдырады, сақаллы кешедән.

— Қырқына чыққанда ағама киләм, нәғыш йортона. Нәғыш мал әйтә. Қуй йә бозау бирә, чәчен ала.

— Беренче чәчен алуға йақын кешесенә әйтә, аңарға чәч алған өчен нийазын бирә — *әстр.*

**Тырнакны, чәчне ташлау** — *себ.:*

— Тырнақны, цацны урнаштырғалы кирәк. Мин утқа тығамын.

Сыуға салсаң сыу қуwа,
Утқа салсаң ут қуwа — *төм.*

## БАЛАГА ТЕШ ЧЫГУ

### Теш әни, теш анасы

**Теш әни, теш анасы** *миш.д., кас.* балага теш чыкканын беренче күргән хатын-кыз.

— Баланың беренче тешен 'эм 'үри, ул *теш әни* була. *Теш анасы* баштин айа' бүли' ала, айа''ийеме, 'үли'лир 'итери. Туйында бер'енчи' 'аплай — *кас.*

— Тешен беренче чыкканын кем күрсә, анарга *теш әни* әйтәләр, падарка бирәләр анарга — *кузн.*

— Кызга кичен муча йагалар. *Теш анасы* чәчен үрә — *тмн.*

### Теш тәтә

**Теш тәтә** *кас.* балага теш чыкканын беренче булып күргән хатын-кызга эндәшү сүзе.

— *Теш тәтәм* дип әйтәбез, йа'ын итеп, әни итеп йөрибез, аш'а-туй'а ча'ырабыз.

## КЕРӘШЕННӘРДӘ (ХРИСТИАН ДИНЕНДӘГЕ ТАТАРЛАРДА) БАЛАНЫ ЧУКЫНДЫРУ ЙОЛАСЫН ҮТӘҮЧЕ КЕШЕЛӘР

### Урсәни, урсанай, урсәти

**Урсәни, урсанай, урсәти** < урыс әни, урыс әти; ягъни баланы чукындырганда «әни», «әти» итеп билгеләп куелган кешеләргә бала шулай эндәшергә тиеш. (Кыскартып: **урсай, урсанай** дип тә әйтелә).

— *Урсанайларымны* бик җақын итеп җөрийем, көн дә кереп чығамын — *каз.ар.-крш.*

### Җәш инә, җәш әни, җәшей

**Җәш инә, җәш әти, җәшей** — нагайбәк һәм бакалы керәшеннәре сөйләшендә: баланы чукындырганда «әни» итеп билгеләп куелган хатын-кыз.

### Җәш әти

**Җәш әти** — нагайбәк һәм бакалы керәшеннәре сөйләшендә: баланы чукындырганда «әти» итеп билгеләп куелган ир кеше.

### Әни тута, ызур әни

**Әни тута, ызур әни** — Алабуга һәм Мамадыш районы керәшеннәре сөйләшендә: баланы чукындырганда «әни» итеп билгеләп куелган хатын-кыз.

## Әти ағай, ызур әти

**Әти ағай, ызур әти** — Алабуга һәм Мамадыш районы керәшеннәре сөйләшендә: баланы чукындырганда «әти» итеп билгеләп куелган ир кеше.

— Бала тыуғачын бер атна арасыннан, ун көннәнме чуқындырырлар ийы. Баланы чиркәүгә чуқындырырға алып баралар, бер чиләк белән сыу алалар. Зур қазан булыр ыйы, шул қазанға сыу салырлар ыйы. Чиркәүдә иман уқып, баланың өстенә сыу қойоп алғачын, *җәш атаның* қулына җурғанны җәйеп торорлар ыйы, китереп салырлар ыйы баланы. Алар *җәш инә, җәш ата* булып қалыр ыйы — *нгб.-крш.*

## Крусан'н'у, крусат'т'у

**Тау ягы керәшеннәре сөйләшендә:**

**Крусан'н'у** < рус. крест + тат. ан'н'у — әни.

**Крусат'т'у** < рус. крест + тат. ат'т'у — әти.

## Кум, кума

**Кум, кума** *[рус.] крш.* баланың үз әти-әниләре һәм чукындырганда катнашкан «әти-әниләр» бер-берсенә кум, кума булалар.

— Марҗа *кума,* мунчада үзең генә чабындыңмы? Ибан үзенең *кумы* Бәчкә белән сүз көрәштерә — *т.кам.-крш.*

— Кечтинәдә *кум-кумалар* булып ыру-тамыр килә — *каз.ар.-крш.*

— Бала туа бит инде, менә *кум* итеп куйалар берәүне, кемне җарата. Чиркәүгә барып бала чукындырып кайталар. Кемне *кум* итийек? Менә шуны итийек. Үзеңнең туганнарыңнан була — *т.кам.-крш.*

## Кумакайым

**Кумакайым** *крш.* яратып, иркәләп эндәшү формасы.

*Кумакайым*, сиңа ниләр бирийем
Әллә бүләгемне бүлимме.
Бүләгемне бүлсәм миннәр бүләрмен
Җаным җарып бирсәм үләрмен.

### Куман'н'у, кумат'т'у

**Тау ягы керәшеннәре сөйләшендә:**

**Куман'н'у** < рус. кум + тат. ан'н'у — әни.

**Кумат'т'у** < рус. кум + тат. ат'т'у — әти.

— Мин *куман'н'у* булдым, чукындырас диләр, канушнига киттем дә ат җигеп кат'т'ым (Ырым Тәрбит). Чаг. удмурт телендә шул ук мәгънәдә: кирос дядя 'крестный отец', кирос-нэнэ 'крестная мать'.

## БАЛАНЫҢ ТӘПИ ЙӨРЕП КИТҮЕ

**Тәпи** — әд.телдә: 1. балалар аягы. Мәрьям әле ул чакта ялан тәпи йөгерә торган унике-унөч яшьлек үсмер иде. Ш. Камал.; 2. сөйләм телендә: гомумән аяк. Тәпиеңне юрганыңа карап сузасың. Мәкаль. — Тыпыр-тыпыр биергә авыртамы тәпиең? Җыр.

**Тәпи басу** — егылмыйча ике аякка басып тору (балалар турында). Айлар үтәр, син үсәрсең, улым, Йөрергә дип тәпи басарсың. С. Хәким. Бигрәк тере безнең улыбыз, хәзер инде тәпи баса, әйбергә тотынып атлый. Н. Фәттах.

**Тәпи йөрү** — ике аякка басып йөрү (балалар турында). Күкрәк сөтеннән аерылып, бәрәңгегә, ипигә ияләшкәч, [бала] анасының чабуына ябышып тәпи йөри башлады. К. Нәҗми. **Тәпигә китү** — ике аякка басып йөри башлау (балалар турында). Балалары — тәпили алганнары тәпиләп, тәпигә китмәгәне шуышып — аның тирәсенә җыелганнар. Ф. Хөсни.

**Тәпиләү** — атлау. **Тәпи-тәпи** — аякка басып. — Үсәргә кирәк, йөрергә, тизрәк йөрергә. Тәпи-тәпи! А. Гыйләҗев.

### Тапийын кытлау

**Тапийын кытлау** *нокр.* баланың тәпи йөреп китүен котлау.

— Җанагабыз[1] кызына тапийын котлап бирмага кул'мак алдым. Нәсел-тамыр[2] ни кэ булса да китерэ әйбер тапийын

[1] җанага — иренең энесе

[2] нәсел-тамыр — нәсел-ыру

котлап. «Тапи тапкан» дип тапийын кытлап бүлэк бирэбез. Мин ике ирнең алты балаларын үстердем — *нокр.*

### Пәпә саплау

**Пәпә саплау** *т.я.-трх.* тәпи йөрү башлау.

— *Пәпә саплый* бала унынчы айда. Менә бу малай йәш тулғ*анда пәпә сапла*ды. Ипи керәгенә утыртып пичкә тығып алалар *пәпә сапламаған* баланы.

## БАЛА СӨЙГӘНДӘ ӘЙТЕЛӘ ТОРГАН СҮЗЛғР

### Үчтеки

**Үчти-үчти, үчтеки** — баланы сикертеп сөйгәндә әйтелә торган сүзләр. — Әнә, улым, абый килгән, үчти-үчти, малай актыгы. Г. Афзал. Үзем Сәлимне үбәм, үчтеки итәм. Һавага ыргытып тотып алам. Ул кычкырып көлә, түшәмгә сикерә, очып китәргә итә. М. Әмир.

Үчти-үчти, үчтеки
Үсмәгәнгә кечтеки.
Үсәр әле зур булыр,
Бик матур бер кыз булыр.

### Чәбәк-чәбәк

**Чәбәк-чәбәк.** «Чәбәк-чәбәк» дигән сүзләр әйтеп кечкенә балаларның кул учларын бер-берсенә сугудан гыйбарәт уен. — Чәбәк-чәбәк эткәсе, Бийетеп тора әнкәсе. Җыр. — Чәбәк-чәбәк чәптеки, түбән очның Әптеки (балаларның кулын чәбәк иткәндә әйтелә).

**Себер диалектларында:**

Баланы сөйгәндә, тәпи йөри башлаганда әйтелә торган сүзләр, такмаклар.

Әткәсенең ней сүзе,
Атқа суғар ғамчысы[1].

[1] ғамчы — камчы

Әнкәсенең ней сүзе
Мақмал[1] бечәр[2] ғайчысы[3].

Қараңғы өйдә чырағы[4],
Қар йауғанда көрәге.

Төп-төп йөгерсен
Тегәнәк моңа төймәсен.
Күп йаманнар күрмәсен
Күсе моңа төймәсен (күз тимәсен).

Төпер-төпер йөгерсен
Йенцеләре[5] түгелсен.

Йеңкәләре[6] чүпләсен дә
Кәбәценә[7] күкләсен.
Күгәл үртәк[8] қақ итәр,
Минем улым тақ итәр — *төм.*

«Торналар тубық алып килсен,
Қаслар айақ алып килсен», —
тип теләтеләр йасқылық. Атламаған балаға алай әйтәтләр — *туб.*

## КҮЗӘЙЕН, КУСАЙТЫН

Әстерхан һәм себер диалектларында сакланып калган әлеге сүзләр гаилә йолаларына карыйлар.

### Күзәйен

**Күзәйен** *әстр.* гаиләдә берәр кешесе ерак юлдан кайтса, мәсәлән, армиядә хезмәт итеп кайтса, яки тоткында булып кайтса, бала туса һ.б. очракларда якыннарын, күршеләрен чакырып, уздырыла торган мәҗлес.

---

[1] мақмал — бәрхет
[2] бечә — кисә
[3] ғайчы — кайчы
[4] чырақ — чыра, яктылык
[5] йенце — энҗе
[6] йеңкә — җиңгә
[7] кәбәц — түбәтәй
[8] күгәл үртәк — кыр үрдәге

— Күзәйен йоласында кара-каршы әйтелә торган котлау-теләк сүзләре дә кызыклы.

**Күзегез әйнепте, күзегез әйнегән;**
**Зағыннан күзәйен булсын.**

**Бәби туу йоласына багышланган күзәйен** әстерхан өлкәсе Киләче авылында язып алынды:

— Менә берәүнең хатыны бәбәйли:

«Күзегез әйнепте, нәрәситәгез бар икән», — дип туғаннары *күзәйенгә* баралар.

«Хәйерле булсын», — дип баралар инде.

«Хәйерле булсын, бәбәйегез бар икән, бәхетле бала булсын, тәүфикъле булсын, атайинәсенә мәрхәмәтле булсын», — дип әйтәделәр. Шатлык, қуаныч.

**Малай хәрби хезмәттән кайту уңае белән үткәрелә торган күзәйен** (әстерхан сөйләшендә). Кара-каршы әйтелә торган котлау-теләк сүзләре:

**Күзегез әйнепте, күзен айныпты, күзен айыныпты.**
**Айында бул, зағыннан күзәйен булсын.**

— Әрмийәдән қайтқанда иң беренче кем килеп әйтсә, «балаң қайтты», — дип, аға сөйөнче бирәләр, күзәйендә аны чақырып алалар, кийет бирәләр пирбуй килеп әйткән кешегә. Қоран уқытадылар. Менә шуны күзәйен дип әйтәделәр. Менә мин ақча чәчәм: «Балам исән-аман қайтқан», — дийеп.

«Күзен айынытты», — дип әйтеп керәделәр. Ул әйтәде:

«Айында бул», — дип. Балаң қайтып, күзеңә күренде ғуй — *әстр.*

**Күзәйен коран** *әстр.* дини мәҗлес.

**Күзәйендә мулла коръән укый:**

— Менә инде әрмийәдән, салдаттан малайы қайтса күзәйен була. Мулланы чақыралар, мулла қорән уқый. Баланың исән-сау қайтқанлығына қуанып бөтен туған-тоқомнарын җыйады. Менә бүген сәғать икегә чақырып китте әле безне күзәйенгә, бер йақынныбызның малайы қайтты.

— Күзәйен коран уқытабыз. Бозау суйып, чатыр қороп күзәйен коран уқыттық.

Күзәйен туйында ашын салады, қәрдәшләрен җыйады. Әрмийәдән қайтайақта күзәйен, китәйәктә.

«Қәйерле сәфәр булсын,аман барып сау қайтсын», — дип тәстерхан җәйәделәр.

— Йегет әрмийәдән қайтқанда күзәйен булып йата. Қуй суйатылар. Китәйақта да шулай күзәйен була. Қөрән уқытабыз. Йақын туғаннары килә йатады. Затларын алып киләләр, қоры қул килмиләр — *эстр.*

**Күзәйендә аракы куелмый.**

**Пылау, пилмән, турамша** (ит белән токмач) пешерәләр:

— Менә әрмийәдән қайтып килде инде, утырып йасин, қоран уқыта, күзәйен дип әйтә, арақы булмый иде. Менә сәғәт икегә күзәйенгә барабыз, бөтен халық киләде. Күп кеше булса пылау пешерәде, инде әз кеше булса пилмән пешерәме, турамша пешерәме. Турамша дип әйтәде итне пешереп турап, қамыр белән аралаштырып. Пылау була дип уйлыйм. Пылау бөтенесенә җитәде. Қабақ сорағаннар ыйы пылауға, қорән ашына. Килмәсләр инде. Күзәйен диде. Күзәйенгә барғач ишектән керәсең менә.

**Күзәйенгә бару — зур савап диләр:**

Менә синең малайың әрмийәдән килгән булса, мин синең туғаныңмы, болай кешеме, күзәйенгә барырға кирәк. Бездә әйтәләр менә:

«Алтмыш чақырымнан килгән кешегә алтмыш йәшәрлек қарт барыр», — диде. Шул хәтле зур саwап менә күзәйенгә бару. Анда чәйләр эчәсең. Син бармаға тийеш, ул зур саwап.

**Күзәйен теләкләре:**

— Күзәйен менә бездә булды, балам қайтты, арақысыз күзәйен уздырдым.

«Күзен айныпты», — диделәр. «И, тәтәм, күзен айныпты».

«Рәхмәт, айында бул», — диде.

«Синең балаңа да йуш булсын», — диделәр.

— Менә ишектән керүгә «Әссәламәғаләйкем» дисен. Тегеләр сәлам биреп қаршы ала. «Аллаға шөкер, малайығыз әрмийәдән қайтқан, күзегез әйнегән».

«Тәүфиқле, бәхетле, шәфқатле бала булсын, алдағы көндә ислам динендә йәшәмәгә барыбызға бергә нәсиб итеп, аллаһы тәғалә үзенә бер тиңдәш табып, озын ғомер итәргә нәсиб итсен. Йарабби ходайым».

«И җан аллам, бер аллам шушы теләгән теләкләребез қабул булсын иде, амин».

Шулай дип керә кергәндә.

«Күзегез әйнепте», — диде. «Күзегез әйнегән», — диде, кем кереп бара ишектән.

— Менә берәү тотқында булып өйенә, туғаннары йанына қайтып килгән. Күзәйен дип баралар шунда.

— Әрмийәдән малайы килсә инде:

«Зағыннан күзәйен булсын, аман-исән қайтты», — дисең. Өй ийәсе әйтәде:

«Рәхмәт, сау булың. Сезгә дә шундый күзәйеннәр йуш булсын», — диде.

## ҚУСАЙТЫН, КҮСӘЙТЕН

**Қусайтын** сүзе себер диалектларында түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

1. Бәби туу уңае белән уздырыла торган мәҗлес.

2. Берәр кеше ерак юлгы чыгып китсә, яки юлдан кайтса, егет армиягә китсә һәм әйләнеп кайтса үткәрелә торган йолалар, мәҗлесләр.

### Кусайтын цай, куцайтын аш

— *Кусайтын* цай булаты. Әйбәт ашлар пешүле булаты. Бүләк ошлап керәсең йаңа туған балаға. Баwырсақлар, бәрәмешләр пешерәбес, *қусайтын* аш тип әйтеләте.

«Қотлы булсын палацық», —

тип керәбес. Ул әйтәте:

«Сескә дә йылашсын,
Сеснең дә балаларығысның балалары булсын», —

тип — *төм.*

— «Син еңеләйепсең» тип, пер нимә ошлап кусайтынға керәтеләр ите.

«Күсең йарыпты, қотлы булсын» тип өмер теләп, икмәк ошлап керәтеләр кусайтынға.

Бер-беренә әйтәтеләр «күсе йарыпты» тип. Масайып, шатланып, икмәк ошлап керәтеләр.

«Ꝗотлы булсын», — тип (*Ишмәт?*).

## Күсәйтен ашлары

— Күсәйтен цайға ꝗуй суйалар.

**Баwырсак** *себ.* бавырсак.

**Көлцә** *себ.* көлчә.

**Кәреш** *себ.* кипкән балык.

**Табаклы аш** *себ.* коймак.

**Туꝗац** *себ.* күмәч.

**Шәңꝗә** *себ.* шәңгә.

— Күсәйтен цайға әрмийәдән килгәнсаꝗ малайны пөтөн аwыл керәте. Килүwенә ꝗуй суйапыс, әсерләнеп паwырсаꝗлар пешереп ꝗуйапыс. Көлцәләр, ашлар пешеренәпес.

— Кеме тукац, кеме балан шәңкә, кеме ꝗабаꝗ бәлеш алып барғалы тейеш.

## Осату кусайтын

**Осату кусайтын** *төм.* озату мәҗлесе.

— Әрмийәгә йегет китсә тә кусайтын ꝗылабыс.

«Осату кусайтын» тип ашлар пешереп, аꝗца ошлап керәбес.

— Кусайтынга парсан пәтер[1] аппарасын, ике пәтер.

«Хәйерле йул пулсын», — тиләр.

— Кусайтын цәйенә кергәнтә күрше-күлән аш тотып керәте, паwырсаꝗ, кәреш тотып керәте.

— Элек кусайтын булған бер араꝗысыс. Перәү ꝗоймаꝗ пешереп апкерәте, перәү көлцә, перәү **табаꝗлы аш**[2]. Цай утыртатылар кусайтын тип. Суғыштан килгән кешегә бигрәк тә табаꝗлы аш пешереп керәтеләр.

«Исән-сау йөреп ꝗайтꝗан икән», — тип.

## Агац, агац цыраꝗ

**Агац, агац цыраꝗ** *себ.* агач, чыра. Малай хәрби хезмәткә киткән көнне утынлыктан берничә агач яки чыра алып куялар.

---

[1] пәтер — төче күмәч

[2] табаꝗлы аш — коймак

Аларның берничәсен малай исән-сау әйләнеп кайткан көнне ягарга дип җыеп куялар.

— Кусайтында киләтләр цәй эцкәле, күрешкәле. Өц агацны керетәсең, саласың. Йегет әрмийәдән қайтса, ул өц утынны кусайтында йағасың. Ике йыл йөриме, йыл йарыммы, ул утын йататы. Йийып қуйатлар.

«Хәйерле йул пулсын», — тип.

Күсәйтенгә цай қайнатқалы ике ағац цырақ. Перәwен йийып қуйасың күсәйтенгә.

### Қасқақ, цырақ

**Қасқақ** *себ.* йомычка. Аны аргалыкка, ягъни матчага кыстырып куялар.

— Кусайтын цәйе үткәргәнгә қасқақ йақтыра. Аны малай әрмийәгә киткәндә арғалыққа[1] қыстырып қуйаты. Ул теләк теләп тораты.

Қасқақ әпкергән пуласың. Перенце килгән көнне үк ул қасқақны йағасың, цәй қайнатасың. Аны киптергәле салып қуйапыс. Қасқақны цәй эцкәле алып керәләр. Ике қасқақны пересен утқа салабыс, перәwен алып қуйапыс. Инте қасқақларны әсерләп қуйтым ғуй. Қәбәр килте.

— Әрмийәгә киткәндә қасқақ тийеп утын чабарлықтан қасқақ алып керәтләр, аны арғалық башына қыстыратлар. Килгәч тә аны йағатлар утқа, кусайтын чәйе эчәтләр.

### Ике пүләнә утын

**Ике пүләнә утын** *себ.* ике утын агачы.

— Менә минем туғанымныңқы паласы киттеме, мин әпкерәм ике пүләнә утын. Палам килгенце салып қуйам, үсем йағырым. Аны йийып қуйасың. Пала әрмийәтән килеп қуйтымы, кусайтынға йағып қуйасың утыннарны.

Әрмийәтән килсә кусайтын қыласың.

«Палам исән-аман йөреп килте, ыспай килте», —

тип. Ул кусайтын тип әйтәпес.

---

[1] арғалық — матча

## ЕГЕТНЕ ХӘРБИ ХЕЗМӘТКӘ ОЗАТКАНДА ҮТӘЛӘ ТОРГАН ЙОЛАЛАР

### Цәйнәмәсен алып қалу

**Цәйнәмә** *себ.* бер кисәк икмәк, тешләп ашаганнан калган кисәк.

— Ир бала әрмийәгә китсә, цәйнәмәсен алып қаласың.

— Икмәкне цайнатып, бер кисәк алып қаласың. Аны сухари қылып йийып қуйасың әрмийәтән қайтуға. Исән-аман йөреп килсә, цәйнәмәсен үсенә ашатасың.

### Цырақ тотып керү

**Цырақ** *түб.* чыра, йомычка.

— Малайны осатқан цақта бер цырақ алып керәтеләр, аны арғалыққа қыстырып қуйатылар. Ул цырақны йағып цай утысалар малай килгәц.

«Алты йәшәр йултан қайтса,
Алтмыш йәшәр йөгереп керер», — ти.

Пөтен аwыл килгән кусайтынға, тату булғаннар.

### Кесәсенә туфрак салып җибәрү

— Кесәсенә туфрақ салып йибәрәсең кецкенә қалтацыққа[1]. «Үсеңнең туфырағың белән йөре, үсеңнең туфырағыңа қайтып бас», — дип — *төм.*

### Қорманнық йасап озату

**Қорманнық йасап осату** *себ.* корбан чалып дини мәҗлес ясап, хәрби хезмәткә озату.

— Мин қорманнықны атап усдырам. Минем балаларым барысы да қорманнықлы. Менә вынугымны[2] әрмийәгә осаттым, ул да қорманнықлы. Әрберебестә қасаннар бар. Ул қасаннарны алып төшәбес күл итәккә[3]. Малайлар ат йигеп утын алып киләтләр. Қорманныққа қуй суйабыс.

---

[1] қалтацық — янчык

[2] вынук [<рус.] — оник

[3] күл итәк — күл буе

«Тәүбиқле булып қайтсын, күрешкәле насип булсын», — дип қорманнық йасап осатам — *төм.*

### Теләк уғыту

**Теләк уғыту** *туб.* дини мәҗлес үткәрү.

— Теләк уғыттық, палабыс әрмийәгә китепте.

### Әпәй сындыру

**Әпәй сындыру** *к.-уф.* егетнең баш очында ипи сындыру. Ул ипине мич өстенә куялар.

— Йегет әрмийәгә киткәндә йегетнең баш очонда әпәй сындырасың да мич башына қуйасың. Ул килгәнче торсон дип артабан. Торадыр да инде сун мич түбәдә. Өч малайны әрмийәгә йибәрдем, өчесенә дә шулай қыйландым.

### Әпәй тешләтеп қалу

**Әпәй тешләтеп қалу** *эстр.* ипи каптырып, калган ипине җыеп кую.

— Әрмийәгә китәйәк балаларға әпәй тешләтеп алып қалалар иде.

«Ыризық тарта ул», — дийеп. Ул әпәйне бәйләп җыйып қуйа. Ыризық кетәде аның қайтқанын.

**Ипи тешләтеп қалу** *каз.ар.-лш.:*

— Ипи тешләтеп алып қалдыру ыйы. Өч малайымның да тешләткән ипийе морҗа өстендә торды үзе қайтқанчық. Исән-сау ғына қайттылар. Ипи үзенә тарта ул. Өч малайым да аwылда.

### Цәйнәмәсен алып қалу

**Цәйнәмә** *себ.* бер кисәк икмәк; тешләп ашаганнан калган кисәк.

— Ир бала әрмийәгә китсә, цәйнәмәсен алып қаласың.

— Икмәкне цайнатып бер кисәк алып қаласың. Аны сухари қылып йийып қуйасың әрмийәтән қайтуға. Исән-аман[1] йөреп килсә, цәйнәмәсен үсенә ашатасың.

---

[1] исән-аман — исән-сау

## Арыш икмәгенең башын кисеп алып куйу

— Арыш икмәгенең башын кисеп матча башына қуйғаннар, ул анда малай әрмийәдән қайтқанчы торған — *каз.ар.-крш.*

— Арыш икмәгенең башын кисеп тәре бабай[1] алдына қуйалар, ул анда малай әрмийәдән килгинче тора — *т.я.-крш.*

## Кисәген алып калу

**Кисәген алып калу** *влгг.* икмәк кисәген егеткә каптырып, калганын ул кайтканчы җыеп кую.

— Солдатка затканда дывалык йазып бирәләр, кисәк каптыралар, икмәк кисәген. Арты белән чыгып китә. Кибеп тора ул килгенчек шул кисәге. Кат'ып килгәч үзенә каптыралар.

## Озату боткасы

**Озату боткасы** *т.я.-крш.* егетне хәрби хезмәткә озату хөрмәтенә пешерелгән ботка, озатучылар мәҗлескә киләләр.

— Китәсе көнне аш хәстәрлиләр, кунаклар, туганнар килә, озату боткасын китереп куйалар. Анда күз йасап май салып куйалар уртасына — *т.я.-крш.*

## Саубуллашу җыры

**Саубуллашу җыры** *т.я.-крш.* хәрби хезмәткә китүче егетләрнең өйдән чыгып киткәндә җырлый торган җырлары.

— Кунаклар ботка ашамаллы утыргис малай саубуллашу җырын җырлап җибәрә:

Боткалар да пешкән, майлар сипкән,
Ашис килми, туганнар, нишлим сын.
Атлар гына җиккән, капка ачкан,
Китәс килми айырылып, нишлим сын.

Ишектән лә чыктым мин тайылдым,
Әти–әни, сездән үк айырылдым.
Капкадан ла чыктым мин тайылдым,
Бар туганнар сездән үк айырылдым.

---

[1] тәре бабай — тәре

Угалҗадан[1] чыктым мин, тайылдым,
Бар аwылдашлардан ук айырылдым.

Тәрәзәне ачтым, мин сызгырдым,
Болондагы печәннәр кипсен дип,
Болондагы печәннәр ай киптинде,
Безгә китәргә wакытлар җиттинде — *т.я.–крш.*

### Кул биреп саубуллаша, кулҗаулыклар селки

— Йегет җырлап бетерә, кул биреп саубуллаша, әти-әниләрен үбә.

Саубуллаша, кулы белән селгеләрен, кулҗаулыкларын селки-селки, әти-әниләрен үбә — *т.я.-крш.*

— Салдатка китәсе җегет җорттан-җортка җөрөп кулҗаулыкларын җиган, селгеләр. Селгеләр, җаулыкларын дугаларга эләләр, урамда селкеп җөргәннәр. Сөйгән кызлары кулҗаулыклары чигеп бирәләр — *т.я.-крш.*

— Тирмән буйына солдат озатырға чығу ыйы. Атларға қулҗаулықлар элеп, қулларындағыны селкеп-селкеп саубуллашалар ыйы. Мәктәпкә җырлап килеп керәләр җегетләр, уқытучылары белән, уқучылар белән саубуллашалар — *каз.ар.–лш.*

### Кояш уңаена өч тапкыр әйләндерәләр, бәхиллиләр

Җырлап бетерә дә, өстәл тирәли өч тапкыр әйләндерәләр кийаш унгайына, ата-аналары, әби-бабалары бахиллиләр.

«Исән-сау әйләнеп кайт, салдатка китмәгән җегет — җегет тегел, исәпле тегел ул диләр, синең бурычың» — диләр.

Шылай итеп озаталар, җылап калалар — *т.я.-крш.*

### Кояш чыгышына таба озаталар. Салдат озату җырын җырлыйлар

— Кулҗаулыкларын, селгеләрен селкеп койаш чыгышына таба салдат зату җырларын җырлап озаталар — *т.я.-крш.*

Кара урманнарны чыккан чакта
Калды камчыларым кайырылып.

[1] угалҗа [рус] – почмак, чат

Калмады камчыларым, ай, кайырылып.
Калды туган илем айырылып — *т.я.-крш.*

### Қазақ озату

**Қазақ озату** *нгб.-крш.* хәрби хезмәткә, казак хезмәтенә китүчеләрне озату.

Қазақ китә озатыйық
Қомайаққа[1] җиткенче.
Таңнар атыр, чулпан қалқыр
Без айырылып киткенче.

## БАЛА ТУУ ҺӘМ БАЛА ҮСТЕРҮ БЕЛӘН БӘЙЛЕ МАГИК ЙОЛАЛАР, ИМ-ТОМНАР

### Авырлы хатынның «саклану» ырымнары:

— Қорсақлы кешене йалғыз бер өйдә қалдырырға йарамый. Қорсақлы хатын йалғыз йатса, йанына пычақ алып йатсын, бала йуғала йалғыз йатса — *әстр.*

— Күзәңкедән[2] атлама, көчөккә, мышыққа[3] айағың белән типмә, гырыжлы[4] бала туар — *әстр.*

### Авырлы хатынның авыры төшмәсен өчен:

Әстерхан сөйләшендә авырлы булуны *буйаwыр* < *буй* + *аwыр* дип әйтү дә бар. Авыры төшү куркынычы булганда итәкне җеп белән тегеп, йозак белән бикләп кую ырымы язып алынды, ягъни *тегү* — беркетү, тоташтыру, ә *йозак* — юлны бикләү, ябып кую мәгънәләре белән туры килә.

— Хәдичә дус әйем[5] имче, қарый инде безне. Мин аурағанны[6] ишетеп килгән, мин буй аwыр[7], балам төшә, дим. Дус әйем,

[1] қомайақ — комлык, яр буе
[2] күзәңке — кисәү агачы
[3] мышық [рус.] — песи
[4] гырыж [рус. грыжа+лы] — бүсерле
[5] дус әйем — әнисенең дусы, ахирәтенә эндәшү сүзе
[6] аураған — авырган
[7] буй аwыр — авырлы

үләм инде дим. Туктап тор ди. Затымны сыйпалады, укыды. Миңә әйтә:

«Бер озын җеп бирегез», — ди, «бер йозак бирегез», — ди.

Озын ғына җеп бирделәр, йозак та бирделәр.

Бу минем итәгемне алып, эре-эре итеп тегеп чыкты да теге йозакны алып шарт итеп бикләп куйды.

«Дус әйем, бу ни зат?[1]» — дим.

«Булды ди, балаң төшми хәзер», — ди.

Ул инде шарт итеп бикләп куйа бала төшмәсен өчен. Эчемне тотты да:

«Иншалла, балаң кыбырдап әйләнә», — ди. Шулай итеп бала кыбырдый башлады. Дус әйем шулай им итте, ул әйемнең дусы инде.

### Кыз бала күрем күрмәсә имләү:

**Күрем** — җенси яктан өлгергән хатын-кызларда була торган менструация, айлык.

— Мин кыԁ булып үскәндә күрем күрмичә чирләдем. Миңа инде үԁем буйы кыԁыл җепләр ағыԁдылар суларға — *минз.*

### Гаиләдә бала булмаса ырымлау:

— Берәүнең баласы йук. Ул мәчет кач'агын[2] алып ишегенә куйган була. Әтәләр шуны алып ыргыт, дип. Алып ыргыта, бала була — *мәл.*

— Сорап алалар икән бала булмаса, таң атканда чыгып сорилар икән, сорап алган балабыз, дип әйтә. Атый икән нәрсә булса да — *м.-кар.*

**Бала тапмаган кешегә әйтәделәр:**

«Диңгез кичмәгә кирәк», — дип. «Кайнанам әйткән иде, диңгез кичмәгә кирәк», — диләр — *эстр.*

### Бала тудыручы хатын озак азапланса ырым итү:

— Бала тумый (тудыра алмый) бер хатын. Берәү керә ишектән, күлмәк чабуын тидерә, айагы йиңел булса, файда бирә — *хвл.*

---

[1] бу ни зат — бу ни булды

[2] кач'ак [рус.] — ишек яки тәрәзә яңагы

— Бала аркылы килсә мәчетнең ишеген барып төшерәләр, тупсадан алып төшерәләр, бала туа — *мәл.*

### Бала тиз тусын дип (ырым):

— Итәкне йиалтерәтеп керәбез улан асыраған[1] өйгә кергәндә: «Үз баласын үзе алсын», — дип әйтәбез. Тиз тыусын йәнәсе бала, мәрхәмәтле булсын — *к.-уф.*

— Ыштаныңны салдыралар да шуңан атлатып кертәләр, җиңел нәнәйләсен, дип.

Ирнең шалбарын идәнгә салып атлатталар, улан тиз туwа.

— Ишкән толомнарын чыбыттыралар аwырлы қатынға җиңел булсын, дип — *к.-уф.*

### Бала түрәгәндә урын алыштыру

**Бала түрәгәндә урын алыштыру** *кузн.* бәбәй тудырганда урын алыштыру, ягъни икенче урынга (башка авылга яки башка өйгә) күчеп бәбәйләү.

— Бала түрәгәндә[2] урнысын алыштырыр әтәләр, барып кайадыр түрәргә кирәк. Мустлар[3], сулар аша узып түрәргә кирәк, урын алыштырырга. Сулар уз, урын алыштыр, бала исән-аман[4] үсәр — *кузн.*

### Қырық қорақ, қорамыш

Бала озын гомерле булсын дип, күз тиюдән, җен-пәриләрдән саклау өчен дип, төрле төстәге тукымалардан теркәп тегелгән киемнәр кидерү аерым төбәкләрдә әле дә искә алына.

**Қорақ** < қор+а+қ — әстерхан сөйләшендә корама; төрле тукымалардан теркәлгән әйбер.

**Қырық қорақ** *әстр.* ырымлап, карт кешеләрдән төрле тукыма кисәкләре җыйнап тегелгән корама.

**Қырық қорақтан күләк, күлмәк** *әстр.:*

— Бала үлеп барса, тормаса қырық қорақтан күлмәк кигезә. Менә берәүнең баласы туа бирә, үлә бирә. Шунарға төрле

---

[1] улан асыраған — бала тудырган
[2] бала түрәү — бала тудыру
[3] муст [рус.] — күпер
[4] исән-аман — исән-имин

җирдән, ирле хатыннарның күлмәгеннән кисәкләп алып күлмәк теккәннәр, торсон дип. Шул ғадәт булған. Қырық қорақтан қул белән тегеп кигезәләр икән. Қарт абалардан[1] алалар қырық қорақ.

«Әби кебек қарт булсын,
шуларның йәшен бирсен,
шуларның йулын бирсен,
торсон, шулар кебек булсын,
қыз булсын, ул булсын», —

дип, шундый кешеләрнекеннән, қарт кешеләрнекеннән ырымлап, йурап, җыйнап, қырық қорақтан күлмәк тегеп кигезгәннәр. Қырық буламы инде, артық буламы шунда.

Қормаған[2] балаға шулай қырық қорақтан тегеп кигезсәләр қорар, торор дигәннәр.

**Қырық қорақ җыйнау** *эстр.* өй саен кереп, тукыма кисәкләре сорап алу, корама ясау.

— Үзләре мал белән далада җөргән, балалары үлә биргән. Қырық қорақ җыйнаған.

«Қорақ сурап килсәләр, бирмәңез, без үзебез қорақ җинаған», — диде.

Қорақ җинаған кеше башқа кешегә қорақ бирмиде бездә.

— Маған[3] әйтте абам:

«Кем дә кем қорақ сурап килсә, син бирә күрмә, без үзебез қорақ җинаған», — диде.

**Қырық өйдән қырық кисәк мата**[4] *эстр.* төрле өйгә кереп, кием тегү өчен ырымлап җыйналган тукыма.

— Балаң туа, ә қормый[5]. Бала туып та қормаса, қырық өйдән қырық мата җыйнап, қырық қорақ җыйнап, матадан күләк[6] тегәде. Шул бала қорады. Қулы ман тегәде төрле-төрле матадан.

---

[1] аба — әби
[2] қормаған — тормаган
[3] маған — миңа
[4] мата — тукыма
[5] қормый — тормый
[6] күләк — күлмәк

— Қырық қорақтан теккән күләкне төрле җептән ишкән дә бәйләп қуйған, сәдәп қадамайды. Җарамайды сәдәп қадарға. Ыштанын да төрле матадан қуйады. Бала қорады.

## Қорамыш

**Қорамыш** < кор + а + мыш *эстр.* төрле тукыма кисәкләреннән теркәп тегелгән күлмәк яки юрган, көрпә. Корамыштан тегелгән әйбер яки кием күз тиюдән, җен-пәридән саклый, бала озын гомерле була, дип ышанганнар.

**Қорамыш йурғаны** *эстр.* корамыш тукыма белән тышланган юрган.

— Қорамыш йурғанын йапқаннар бала йөткерсә.

**Қорамыш кигезү** *эстр.* корамыш тукымадан тегелгән кием кидерү.

— Күз тимәстән чеперәкләрдән қорамыш тегеп кигезә, тақийасына[1] йылтырақ[2] қуйалар, манитлар[3] қуйалар күз тимәскә.

**Җиде төрле ситсыдан күлмәк кийертү:**

— Җиде төрле ситсыдан күлмәк тегеп кийертә балаға, тормаған балаға. Шулай иткәч тора, үлми, ишеткәнем бар — *каз.ар.-дөб.*

— Туа да үлә кайсының бәбәйе, йеде төрле читсыдан күлмәк йасайлар, йәнә бәбәй торсон, аны йалгаштырып йасайлар йеде төрледән — *нокр.*

**Қарт кешенең киеменә чолгау:**

— Сигезән, тугызан йәшлек әбинең киеменә чыргарга ыланны, озын үмерле була — *лмб.*

## Бала үлеп барса ырымлау

**Көйләген талға элеп қуйалар** *себ.* баланың күлмәген талга элеп куялар.

— Балалары тормаса, үлеп утырса, көйләген талға элеп қуйаты қырық көнентә — *себ.*

[1] тақийа — баланың баш киеме
[2] йылтырақ — ялтыравык
[3] манит [рус. монета] — тәңкәле акча

**Баланы утынлыкка куеп торалар:**

— Оланнары бер дә тормай. Утынлыкка салма кушканнар бәбәйне. Йакын кешесе керткән, мына бәбәй таптым, дип. Ул оллары тордо аларның — *нокр.*

**Соңгылыкны баланың киеменә тегеп куялар:**

— Менә берәүнең баласы тормый, үлә. Бала туғанда төшкән җулдашын[1] алып киптереп қуйғаннар да шуны әз генә кисәген алып, балаға тегеп қуйғаннар. Өлкәннәр ырымы — *эстр.*

## Нийәтлек суйу, теләү суйу

**Нийәтлек суйу**¯*себ.* — нәзер әйтеп корбан сую.

— Исән-сау бәбәйләдем, исән-сау торсон. Нийәтлек суй дым. Бөтен халықны ашаттылар бер зур сарық суйып.

— Нийәтлеккә сарық суйалар. Мулладан буwазлаталар. Тиресен, йонын, башын, айақларын буwазлаган кешегә бирәсең. Кереп қорән уқый өйдә. Хәйер бирәсең. Нийәтлек суйдырып ашатасың. Итен йәтим-йетемнәргә өләшәсең — *том.*

— Аwыру-сырхау балаға нийәтлек суйалар. Сарық суйып кеше сайын өләп йөриләр. Үзем дә былтыр ғына өләдем.

— Нийәтлек итен үзең ашасаң, шул хақны хәйер итеп биргәле — *туб.*

**Теләү суйу** *том.:*

— Нийәтлек суйабыз әргем, аурымасқа, сысламасқа. Алла тәғалә қәwеф-қәтәрдән саклағалы тип теләү суйаты. Йөргән йирләрдә тыныч йөресен, тошманнар қулына қалмасын тип, нийәтлек теләү суйғалы тейеш — *том.*

## Баланы «җен алыштырмасын өчен» ырымнар

Бала бишегенә «җен-пәридән, шайтаннардан саклану өчен» төрле әйберләр кую

Бишеккә төрле әйберләр: **дага, кайчы, пычак** һ.б. салалар. **Тимер** — мәҗүсилек карашларында явыз рухлардан саклану, арыну өчен ышанычлы әйбер дип санала (Юсупов, 1967, 33 б.).

---

[1] җулдаш — соңгылык

**[Баланы пәри алыштырмасын өчен]:**

— Саулықсыс баланы бишектә пәри алыштырып киткән дип әйтәләр. Бишеккә доғалық, китап, пыцақ алып қуйатлар.

— Сәңгелчәккә[1] қайчы, тубалық[2] элеп қуйганнар. Үсем белә қалтым. Қырық көн сақлағаннар баланы —*туб.*

— Пер йеңгәсе ағасынықы сөйләйте. Баланы қуйынымтан суwырып алты та уша пич алдында төннектән алып чығып китәм дигәндә баланы алып қалганнар. Уғынып[3] алғаннар да баланы қалдырғаннар. Йен-шайтан алған диләр — *том.*

— Бер кеше дә булмадисә, берәй нимә[4] қуйалар. Йә пычақ, йә қайчы қуйалар — *к.-уф.*

— Элек пычақ салып йоқлатқаннар:

«Шайтаннар килмәскә» — *минз.*

— Қырқы тулғанчы баланы жалғыз қалдырырға қушмыйлар, пычақмы, қайчымы қуйалар жанына, «җен алмаштырмасын», — диләр — *каз.ар.-дөб.*

— Оланны жаңгыз салса, пычақ қуйып китә жанына, «усаллар, шайтаннар килмәсен», — дип — *перм.*

**Дага салу** *нокр.:*

— Бишеккә мәләкәй[5] астына дағалар салалар бабайға[6]:

«Шайтаннар кермәсен».

**Тәңкәле муенса салу** *к.-уф.:*

— Зур буйынсаны[7] баланың өстенә йабып қуйып чығар ыйық. Тәңкәле була қый буйынса:

«Шайтаннар алмаштырмасын».

**Бишеккә айу тырнағы салу** *том., туб.:*

— Айу тырнағы салып қуйалар иде бишеккә бала астына. Зур айу тырнағы, қайан алғаннардыр. Ул баланы сақлый инде аwырудан, шайтаннардан.

---

[1] сәңгелчәк — бишек
[2] тубалық — догалык
[3] уғынып — укып
[4] берәй нимә — берәр нәрсә
[5] мәләкәй — мендәр
[6] бабай — бәбәй
[7] буйынса — муенса

— Бер айу тотқаннар иде, айуны китерделәр аwылға.

«Айуның тырнағын алырға кирәк», — дип қычқырышалар — *том.*

— Айу тырнақны шәлтеп паwына[1], түрт паwына да тағып қуйатлар.

«Йел–шайтаннар килмәй».

— Атып айуны алып қайтатылар, айуның тырнағын алатылар, шәлтеп баwына элеп қуйатылар. Аны икене алатылар, шәлтепнеке асты йағына баwына элеп қуйатылар.

«Йел[2] килмәйте».

**Бишеккә «шайтан агач» — шайтан тайагы (чертополох) салу** *глз.:*

— Бишеккә баш астыга шайтан агач салгаладылар бәләкәч астыга.

«Олан йанга шайтаннар йабышмасын».

Оланны киптерә йабышса ки.

— Өй байы[3] бәбәйне куркытмасын дип, шайтан тайагын, кыйбудыны[4] бишек башка, бәләкәй астыга салгаладылар.

**Бишек турысына идәнгә винек** (<рус. веник) — **себерке кую** — *волгоград сөйләшендә*:

— Бишеккә дывалыклар куйабыз. Ә тышка чыксак, бала йалгыз калса, бишек турысына идәнгә винек куйа идек. Идән себерә торган винекне куйабыз.

Винекне бишек турысына куйганда **бисмилла әйтмичә** генә куйалар. Бала йанына җен килсә, винекне күреп, бала турында оныта, винекнең сабакларын саный башлый икән — *влгг.*

**Бишеккә артыш салу** *нокр., глз., к.-уф.*:

— Бишеккә бәләкәй астыга артыш салалар, бишек йанына элеп салалар.

«Зәхмәт килмәсен».

---

[1] шәлтеп паwы — бишек бавы

[2] йел — җен

[3] өй байы — йорт иясе

[4] кыйбуды [удм.] — шайтан тайагы үләне

— Артышның нәзек кенә чыбыгын, миләшнең нәзек кенә чыбыгын салып куйалар бишеккә төпкә.

«Шайтаннар килмәс өчен».

Куруб[1] кебек бишекне сәнчеккә элде дәген артыш чыбыкълары, миләш чыбыкълары салды да йөргәк[2] җәйеп куйдылар — *к.-уф.*

### Бишеккә китап, бөти, догалыклар салу

**Җакшы сүз салу** *минз.* дини китаптан язып алынган догалы язулар салу.

— Бәллүгә[3] җакшы сүз[4] салдылар әбиләр.

**Изге китап салу** *глз.* дини китап салу.

— Бишеккә бәләкәй астыға изге китап салғаладылар.

«Җен-зәхмәт килмәс өчен».

— Бала йанына қоръән-китап салалар, беләгенә көмеш тәңкә бәйләп қуйалар.

«Шайтан алмаштырмасын».
Бишеккә әптийәк салалар — *әстр.*

**Доғалықлар, доғалы бөтү салу** *глз.:*

**Бөтү** — әд. бөти. Борынгы төрки телдә **бит** — язу, **битиг** — язылган әйбер, СС **битик** — хат, язу (Махмутова, 1982, 27), *миш.д.* **бетег** — хат, язу; **бетек** *чст.* бөти.

—Бишеккә мәләкәй астына догалы бөтү йасап салалар — *глз.*

— Бишеккә йастык астына **дывалыклар** куйабыз — *кузн.*

— Бишеккә дывалык салалар.

«Шайтаннар булмасын.
Бала йакшы гына,
Тыныч кына йокласын.
Шайтан алыштырмасын» — *влгг.*

---

[1] куруб [рус. короб] — бишек
[2] йөргәк — бала чүпрәге
[3] бәллү — бишек
[4] җакшы сүз — дога сүзләре

## БАЛАНЫҢ ИСЕМЕ БЕЛӘН БӘЙЛЕ ЫРЫМНАР

### Миң боздыру, исемен алыштыру

**Миң боздыру** *глз.* балада миң булса икенче исем бирү.

— Миң була кайсы балада. Миңне боздоралар. Исемен әйтеп боздорасы була. Әтэсин бэш айга, алты айга. Аны энде эсиме белин әйтмисин, бозган эсими белин әйтисин. Кайсының бетэ миңе, кайсының уңала[1]. Бозган исемне морйадан кычкыралар: «**Минниса, Минсылу**» дип өч кат кычкыралар пич алдында барып. Тотмаган йаңа кашыкны бер әбигэ бирилир. Сүзгэ кирсенеп[2] аwыртына кайсы бала.

— Миңе бар дип **Миннекан, Минсапа** исемнәре салгаладылар, кызларга **Минзифа, Минниса, Минсылу** исемнәре салгалаганнар. Икенче исем салгалаганнар. Морйа[3] ачып морйадан кычкыргалаганнар: «Бу оланның исеме **Минниса** булсын».

— Берсе малайым тәненә козол койолды. Бүре тимерәү, дилэр. Чиргэ керешсэ исемен алыштыралар.

Исем алыштыргалап йөрделәр. Миң булган дип исемен алыштырып бактылар. Өммөҗийан исемен **Минҗийан** дип алыштырдылар. Күзе уңгайланган.

Нәҗметдин исемен **Миннекан** дип алыштырдык. Ни ки белән дә эрәнҗегән булган. Бөтенесенекен исемнәрен алыштырганнар. Сигез бала күргәннәр[4], икесебез тере.

— Йылак олан булса *исемен алыштыралар*. Минем малайым Шәйкулла, исемен алыштырып кашык төшөрделәр морйадан Минкәт итеп. Гөлзәминәгә Минзифа дип исем салдырдым[5].

### Ырымлы исемнәр кушу

**Балтабай, Қодайбиргән** *эстр.:*

— Қайсы кеше баласы тормағанда кендеген балта белән чаптырған, атын Балтабай қуйған, Қодайбиргән дигән, алладан аманат булған.

---

[1] уңала — төзәлә
[2] сүзгә кирсенү — сүздән күз тию
[3] морйа — морҗа
[4] бала күрү — бала тудыру
[5] исем салу — исем кушу

**Биктимер** *әстр.:*

— Баласы тормый иде менә күрше қатынның. Ул минем балалар үскән бишегебезне дә алды, безнең балалар өстеннән кийемнәрен дә алып үзенең баласын урый иде, минем дә балам торсын дип. Торды шул баласы, **Биктимер** дип исем қуйдылар. Әле дә бар шул малай.

**Сатыбал, Сатыбалдым, Сатый** — явыз рухларны, җен-шайтаннарны алдалау өчен баланы икенче кешегә юри генә «сатып бирү» яки «сатып алу» һәм шуңа бәйләнешле исемнәр бирү татар халкының күпчелек төркемнәрендә булган.

**Әстерхан сөйләшендә** ***Сатыбал, Сатыбалдым*** **исемнәре**:

— Бала туғанда тормаса ырлап китәде баланы. Өйдә тушwады ғуй. Үзең йатасың, белмисең. Аннан суң ул баланы үзең сатып аласың икән бала тормағанда. Сатып алғанда ырымлап чәй бирәде, май бирәде, ақча бирәде. Атын инде **Сатыбал** қуйған.

— Мамайның[1] баласы үлә биргән, җиде көннән артық тормаған. Шул wахытта анарға әйтәләр: «Сатыб ал балаңны». Бала туwа, қайнар килеш иренең қулына салалар, сатулашалар икән. Мамай сорый хақ, ире аны бирми. Килешәләр. Кендег аты[2] «Сатыбалдым» қуштыралар. Дуwа[3] йазып муйынына тумар[4] эләләр.

**Себер диалектларында:**

— Берәүнең баласы тормый, нараситалай[5] үлеп китә. Ул баласын *икенче қатынға сатқан*. Синең малайларың әйбәт үсеп утыра. Ул туwа қылып алған. Ул бала арақы эчмәсен. Тәүфикле булғалы тийеш.

— *Баланы сатып алдым*. Тәрәзәдән әбилек[6] бирде. Үзе уқына. Ишектән үзем алдым.

Йедегә йелдермәсен,
Алтыға алдырмасын.

---

[1] мамай — әби
[2] кендег аты — бала тугач та бирелгән исем
[3] дуwа — дога
[4] тумар — бөти
[5] нараситалай — кечкенә көенчә
[6] әбилек — кендек әбисе

Минең шикелле қарт булсын,
Бәхетле булсын, тәүфикле булсын,

Шул әбилеккә теләкләр теләп йатам, хәйер бирәм, көйнәк[1] алып бирәм.

**К.-уф. (Урта Урал) сөйләшендә:**

— Бала үлсә тыуғаны берсе, аймақ[2] балалы кешегә сатып бирделәр. Кемнең баласы күп, кемнең баласы тора, шу[w] кешегә саттылар баланы. Аныңа ақса бирделәр торор өсөн. Арта[3] бала үлмей. Аймақ балалы кешегә саттылар, шунда қатышып китә йәнә аймақ бала йанында. Берәүнең баласы үлеп тордо, бер дә тормады. Үзе қараса да анықы малайы дип йөрөттеләр аны.

— Аймақ балалы кешегә сатып биргән булалар баланы. Абзыйның балалары күб ийе, җизнәйнең баласы үлеп барды. Шул баланы сатып биргәч кенә исән қалды тутай белән җизнәйнең баласы. Арта тутай үлеп қуйды, малай өч йәш булып қалды.

— Әнейем аwырайақлы[4] булған, бала табарға кәрәк бит инде. Килгәннәр өйгә, этейемән тәрәзәдән сураған мин тыуғас: балағызны сатасызмы? Хәзер дә торам, гомерем бар, җитмеш туғыздамын хәзер — *к.-уф.*

**Пермь сөйләшендә:**

— Оланнары күп кешегә сатқаннар. Ақча бирәләр, әйбер бирәләр. Зәйет бабайға сатқаннар, шуннан сун ғына торған оланнары, туғызау булған. Оланнар тормағач мин дә сатып бирдем, қодағыйнықы биш малай, аға саттым — *перм.*

**Казан арты-дөбъяз сөйләшендә:**

— Тәрәзәдән сатып ала икән анасы, тормағанға сатып бирә икән. Мин дүртенсе бала булған, тәрәзәдән сатып алдық әбидән дийер, өс баласы үлгән әнинең — *каз.ар.-дөб.*

---

[1] көйнәк — күлмәк
[2] аймақ — күп
[3] арта — аннан соң
[4] аwырайақлы — авырлы

## БАЛАНЫҢ ТӘПИ ЙӨРЕП КИТҮЕ БЕЛӘН БӘЙЛЕ ЫРЫМНАР

Баланың тәпи йөреп китүе белән бәйле булган ырымнар татар халкының барлык төркемнәрендә дә күзәтелә. Бала озак тәпи йөреп китә алмаса, яки тәпи йөри башлаган вакытта, аның аягын җеп яки бау белән «тышаулап» (ягъни бәйләп), шуны кисеп җибәрә торган булганнар. Ул ырым нәкъ шулай атала да: **айақ баwын кисү, тышау кисү.**

### Тышауланған бала, тышаулы бала

**Тышауланған бала** *әстр.*, **тышаулы бала** *к.-уф.* аягына йөреп китә алмаган бала.

— Тышауланған баланы икенде-ахшам арасында, сыйырлар қайтып торғанда урамның уртасында қалдыра.

«Ни зат итәсең?»[1]

«Менә Әлфийә тышауланған, йөреп китә алмый, тышаwын кисәм», — ди. Тағын сорый ул кеше: «Ни зат итәсең?»

Ул wахытта кичке маллар қайтып торған wахыт була, шул тышауны кисәләр. Шуннан инде, бер тышауланып, бер йөреп торған бала, алланың қодрәте, элекке ырымдыр инде, йөреп китә. Үзем шулай чығарып тышаwын кискән идем, йөреде дә китте балам — *әстр.*

«Тышаулы бу бала, — диләр, — тышаwы бар», — диләр. «Айағын тышыйбыз да кисәбез», — диләр.

Тышау кебек итеп бәйлиләр дә кисәләр. Ар таба[2] сөрөлми[3] бала, йығылмый — *к.-уф.*

### Айақ баwын кисү

**Айақ баwын кисү** *әстр.:*

— Бала тәпән-тәпән итеп йөргесе килеп йөреп китә алмаганда үзенең қардәшен чақырып айақ баwын кистерә. Айағын бәйләттерә дә, кисәйәк кеше ни зат әйтә, үзенең сүзләре бар, қачы белән кисә торған ыйы. Шул бала йөреп китә торған ыйы.

---

[1] ни зат итәсең — ни эшлисең

[2] ар таба — аннан соң

[3] сөрөлми — сөртенми

Бау кискән кешене ыризалаттыралар ыйы, бүләк бирә торғаннар ыйы.

## Тышау кисү

**Тышау кисү** *кузн., мәл.* бала озак тәпи йөрмәсә, анын аягын бау белән «тышаулап», шуны кисеп җибәрү.

— Баланы озак тәпи йеремәсә, тышаулилар үзен салам белән, аннан кетү килгәндә тышауны кисәләр. «Кисәм тышауны, тиз генә йөре, тиз генә йогор», и йогортып алып кереп китәләр үзен. Тышау кискәннең пычагын кетү килгән йулның икенче йагына чыгарып куйалар урамга, кайан кетү килә. Кайа синең пычагың, соң йогортып чыгарасын урамның теге йагына — *кузн.*

— Ат тышаулаган кебек тышаули да кисеп йибәрә, ад'а, тәпи йере, дип — *мәл.*

— Бала атларга азаплана, үзе атлап китә алмый. Әнкәсе тотып тора. Син барасың җакын гына, тегәрҗеп белән ике айагын бергә бәйли дә куйа. Әнкәсе тотып тора. Мин чакырам баланы күчтәнәч белән. Ул килеп алырга азаплана, киләлми. Мин барып тиз генә кисәм дә әтәм:

«Айагың җиңгел булсын,
Чаwып кит», — дим.

Ул **тышау кисү** була.

— Сыйырлар кетүдән кат'кан wакытта ыланны бастырасың, йеп белән бәлисең айакларын да кисеп йибәрәләр — *влгг.*

— Тышау кисү кемгә дә йари. Бала айагыннан йөрми. Тышаули да йеп белән выт' кисә качы белән. бетә, олан йөреп китә. Мин тышау кисмәдем, йәшли йөреп китте оланнарым.

— Менә оланы йөреп йатканда йыгылган да курыкан, йөреп китми хазер. Мин ат'ам:

«Тышаула да үзең кис, уртадан».

«Бәреп йибәр тышаwын көн туwыш йакка[1]». Чын да йөреп китте. Әле оланнар тиз йөри.

— Айак арасыннан йомырка да каталаттым[2].

«Йомырка кебек каталап йөрсен».

— Кетү чыккан wакытта кетүгә каршы кисәсен. Тегеннән мал килә, син чыгарып бастырасың үзен дә кисәсең тышаwын.

---

[1] көн туwыш йак — кояш чыккан як

[2] каталату [< рус. ката(ть)+лату] — тәгәрәтү

— Олан йөри алмый, тышауланып[1] тора. Чыгарып кетүгә бастыра да тышавын кисә эч кен эрәттән. Йаз[2] булса кетүгә чыгара, кыш булса бусагага бастыра — *мәл.*

**Тышау кисү** *к.-уф.:*

— Улан тәпәй йөрмәсә тышаулыйлар сыйырларны тышаған кебек. Шуны тышап[3] шуны белә имниләр сөрнегеп[4] йөрсә.

Тышау бәйлийең дә сөрлегеп йөргән баланың тышаwын кисәң, қайсы белән кисәң.

«Тышаулы булған, тышауланған, тышаwын кисәм», — дип әйтәң дә кисәң. Булыша ул арта, айақ нығый. Қамыт айақлы була қайсы бала. Қәйнәм[5] шулай эшләде, баланың айағы төзәлде. Тышаwын кисәргә кәрәк, диләр дә кисәләр.

Баланың йөрүwе насар булса, айағ араға салам салып, шуны кисәләр, тышаwын кисәбез, дип. Анысы бар. Саламны салаң да қайсы белән кисәң, «Тышаwын кисәм», — дип. Бер балам шулай булды.

— Бала йөргәндә айағы сөрөнде[6] исә йүкә бауны тискәре йаққа таба ишәң дә айағын бәйләп қуйаң. Пысақ белән кисәң ары таба, сөрөнмәскә, бала йығылмасқа.

**Тышау кисү** *том.* бала озак тәпи йөреп китә алмаса, аның аягын бау белән «тышаулап», шуны кисеп җибәрү.

— Айағын тышау бау белән бәйләп бер әби кисеп йибәрә. Шуңан йөреп китүчән булғаннар. Мин тоғасын пелмәйем.

— Айаққа озақ йөремәсә сыйырлар қайтқанда көтү қаршына чығарасың да тышаулыйсың бау белән. Сыйыр қайтқанда аны тишеп җибәрәсең. Шуннан ул үзе йөгереп китә.

— Көтү қайтқанда баланы алып чықты, пычақ алып чықты. Бала дүрт айақланып йөри.

Берәү өч тапқыр сорый: «Ни кисәсең?»

«Тышау кисәм», — ди.

Көтү қайтып йата. Шулай иткәч айаққа йөреп китә ди.

---

[1] тышауланып — йөреп китә алмыйча

[2] йаз — җәй

[3] тышап — тышаулап

[4] сөрнегеп — сөрлегеп

[5] қәйнә — кайнана

[6] сөрөнде — сөрлекте

**Шау кисү** *каз.ар.-дөб., каз.ар.-лш.* тышау кисү ырымы.

— Айагын җүкә бау белән бәйлисең дә шау-шау-шау, шаwын кисәм, дип кисәсең, шаулап-шаулап шау кисәсең. Кисәбез шул балалар җөри башлаганда, шаwын кисәбез.

«Баланың шаwын кисәм, шаwын кисәм», — дип кисәләр айаг арасыннан , «ишәдрүк» дип әйтәләр шаwын кисkәндә. Әнә, әнә атлый дип қарап торадырыйыг инде — *каз.ар.-дөб.*

— Бала айаққа җөрми әле дип, әни бер җүкә алды да, айагына чалды да кисеп җибәрде пычақ белән, ике айагын бәйләде алдан, аннан кисеп җибәрде — *каз.ар.-лш.*

### Баланың тәпи йөреп китүе белән бәйле башка ырымнар

**Айаг эзеннән туфрак алу** *баст.* бозу, сихерләү.

— Айагы сырхаулады қызымның тәпи йөргәндә. Аны бозом иткәннәр, айаг эзеннән туфыраг алганнар, айагын заиб иткәннәр. Артыннан кем дә булса килсә, айақ эзен тетеп-тетеп җибәр, шулай қыланмасын.

**Айақ эзе** *әстр.:*

— Теге кешенең айақ эзе дип бераз гына туфрақ алып сала. Теге кеше киткәч үк чыгып ала иде, айақ эзе дип. Шул туфрақны суга салып, марлыдан сөзә иде дә баланың башына, арқасына йага иде, аwызына да тамыза иде. Мин шулай балалар күп булгач күрә қалдым.

**Тизрәк тәпи йөреп китсен дип:**

— Җалан айақ килешкә җиргә қырық бер тапқыр бастырырга, бала тәпи йөреп китә — *каз.ар-дөб.*

— Бала айаққа йөрмәгән. Ат чаwып килгән йиргә чыгарган да утыртқан баланы, торган да йүгергән имеш ди, ишеткәнем бар — *к.-уф.*

**Себер диалектларында:**

**Бала тәпи йөри башлаганда баш очында ипи сындыру.**
**Баланың баш очында икмәк сындыру** *тара.:*

— Йылы ипейне мейестән алып, шуны баш оцонда сындыра. Бала тизерәк йөреп китсен өчен. Башыннан ипейләр сындыра шулай.

— Баланың баш очында сындырылған икмәкнең йартысын кендек әби, йартысын ата-ана аwыз итәргә тийеш.

— Кендек әби ипи сындырғанда әйтә:

Йөгереп-йөгереп йитә алсын,
Йөгерекләрне йитә алсын,
Атлыларны йитә алсын,
Йәйәүлене уза алсын,
Йөгерек булсын, ут булсын,
Тәгәрәгән туп булсын — *тара.*

**Баланың айағы имгәнсә:**

— Қара атның буғын алып киләтеләр эстәп. Аны парлантырып өс ай ат буғы парына утыртатылар. Айағы төсәлеп қуйаты — *туб.*

**Күпкәк имләү** *мәл.* рахит имләү.

— Балага күпкәк булса баланың айагына тибәргә кирәк. Игезәк бала тудырган кеше тула ойок кийеп баланың айагына барып тибә.

**Пәпә саплау** *т.я.-трх.* тәпи йөри башлау.

— Пәпә саплый бала унынчы айда. Менә бу малай йәш тулғанда пәпә саплады. Ипи керәгенә утыртып пичкә тығып алалар пәпә сапламаған баланы.

## БАЛА ЕЛАГАНДА ИМЛӘҮ

Җирле сөйләшләрдә елак баланы түбәндәгечә атап йөртүләр бар:

**йылаwық бала** *эстр.*,
**йылақ олан** *глз.*,
**сықтақ бала** *к.-уф.*,
**тондоқсыз бала** *перм., к.-уф.*

Тынычсыз, елак балаларны имләүгә җирле сөйләшләрдә түбәндәге мисаллар табылды:

**Казан арты-дөбъяз сөйләшендә:** бала елак булганда чәршәмбе көнне тегәрҗеп биргәннәр.

— Бик қаты йылаған балаға безнең әниләр болай итә торғаллар ыйы. Әwәле тегәрҗеп җерләү барыйы. Шул **тегәрҗепнең**

**бер басмасы** дип сөйләшә торғалларыйы. Бер **басмасында утыз бөртек** булған инде ул. Шул бөртекне бишеккә элеп қуйғаллар да чәршәмбе көнне, кем керә, бишектән шуңа алып кергән бер кешегә бирә торғалларыйы. Менә тушылай[1] адарынған ыйым, бала җылады, тушыны бирәбез дип кем керә, шул тегәрҗепне бирә торғалларыйы — *каз.ар.-дөб.*

**Әстерхан сөйләшендә:** пич суынгач, баланы көрәккә утыртып пичкә тыгып алганнар; ишек-бишек бауларын чайкап баланың колак артына сөрткәннәр.

«Йылаwык булмасын» дип:

— Пич суынғач инде баланы **көрәккә утыртып пичкә тығып** алған булалар инде, «йылаwық[2] булмасын», — дип.

— **Ишек-бишек бауларын чайқап**, баланың қолақ артларына сөртәләр бала йылаwық булса. Қалғанын сибеп җибәрәләр.

**Нократ сөйләшендә:** төнге унике сәгатьтә ай яктысына алып чыгалар; суга артыш салып коендыралар.

— Йеде айға чақлы йылады. Тенне унике сәттә айға чығардым. «Ай қайта, кен қайта», — дип әйтеп. Т'ит'ик[3] бала нәкәс[4] йылақ булғалады.

— Суға артыш салып қойондырам мин баланы, сабыр була.

**Себер диалектларында бала сықтаса (еласа):**

**Бишек астына тимер әйбер куялар;**

**Бишек астына артыш төтәтәләр:**

— Цәңгелцәк[5] астына бер тимер саласың, артыш ағацын цәңгелцәк астына салып төтәтәсең[6]. Пала сықтаса туқтап китәте — *төм.*

**Тәрәзә өлгеләрен юып балага сөртәләр:**

— Пала йоқламый, йылый. Минең қәйнәм[7] тәрәсәнең йете өлгесен қулы белән сөртеп, паланың қулларын, айақларын сөртә. Пала йоқлап китә. Пороңкылар име.

---

[1] тушылай — шушылай
[2] йылаwық — елак
[3] т'ит'ик — кечкенә
[4] нәкәс — бик
[5] цәңгелцәк — бишек
[6] төтәтә — төтен чыгара
[7] қәйнә — кайнана

**Баланы икмәк көрәгенә бәйләп җылы мичкә тыгып алалар.**

**Йылағын өтәләр;**

**йылағын ҡурҡыталар:**

— Баланы икмәк көрәгенә бәйлиләр, өч тапҡыр мичкә тығып алылар:

Йылағыңны өтәм,
Йылағыңны өркетәм.
Каф, каф, тфү (Өч тапкыр әйтәләр) — *тара.*

Бишекне атка суга торган чыбыркы белән урап куялар:

— Пәпә[1] үлцәшеп[2] сыҡтап китәте. Атны суғатҡан[3] цыбыртҡы[4] булаты. Шәлтепне[5] урап ҡуйатлар цыбыртҡы белән. Сыҡтаған баланы алай имләйтеләр — *туб.*

## Төн ботҡа

**Төн ботҡа** *перм.* бала елак булганда, нәзер әйтеп ботка пешереп багана башына чыгарып куела торган ботка. Ботка янына җиде кашык куйганнар.

— Төн ботҡа утыртам, тондоҡсыз[6] булды шул бала тип ботҡа утыртам, җите ҡалағын[7] ҡуйам. Төн ботҡа тип җылаҡ бала өчен тип, ыстулба[8] башҡа утыртып ҡуйаты элек, тондоҡлы булырға тип — *перм.*

## Төн сәдәкәсе

**Төн сәдәкәсе** *мәл., кузн., влгг.* бала яхшы йокласын очен дип бирелә торган сәдәкә.

— Бала йыласа, йокламаса, кичкырын төн сәдәкәсе кертәләр, йәшми-тынми бирәләрдә чыгып китәләр — *мәл.*

— Йылаwык бала булса, сәдәкә бирәләр төнгә каршы — *кузн.*

---

[1] пәпә — кечкенә бала
[2] үлцәшеп — ярсып
[3] суғатҡан — суга торган
[4] цыбыртҡы — чыбыркы
[5] шәлтеп — бишек
[6] тондоҡсыз — тынычсыз
[7] ҡалаҡ — кашык
[8] ыстулба [рус. столб] — багана

— Бала йылый. Киләләр. Йлаwык балалар була.

«Төн сәдәкәсе бирегез», — димен.

Төн сәдәкәсе шул була. Бер тотылмаган касәгә он сал, шул нараситәнең кулын онга бастыр, он өстенә сәдәкә куй. Керт күршегә. Бер зат та әйтмә, кит. Ул төн сәдәкәсе була. Анарга укилар. Шуннан сың бала йыламый башлый — *влгт.*

**Бала астын йүwешләтсә** *к.-уф.:*

— Қамыттан сығаралар ыйы, атның қамытынан сығаралар.

Суйған малның талағын пешереп ашаталар. Бала сийеп йатса, астын йүwешләтсә шулай итәләр.

**Балага «кирелчәк» булса** *хвл.:*

— Кирелчәк була ыланга. Ыланны сокага атландыралар. Кирелә, сузыла ылан, аны кочокка, сока кочокка[1] атландыралар.

Айда кайтса, син дә кат
Кирелчәк бусан син дә кат
Эч кат атландыра кочокка — *мәл.*

## КУРЫККАН БАЛАНЫ ИМЛӘҮ

### Қот қойу

**Қот** (ТТАС) — 1. Борынгы ышанулар буенча тәннән аерылып китә ала дип уйланылган җан; рух. Бишенче көнне аның күзгә күренмәс күбәләк булып янында гына очып йөргән коты кире авызына керде. Үлем белән яшәү арасында тартыш төгәлләнде. Н. Фәттах. 2. Нур, ямь, матурлык. Баласыз өйдә кот юк. Әйтем. 3. Бәхет, уңыш. Кунак килсә, кот килә. Әйтем.

**Қот қойу** — куркып чирләгәндә имләү. Кургашын эретеп, аны авырган кешенең баш өстендә бер сулы савытка салалар. Имеш, нәрсәдән курыкса, шуның сурәте төшәргә тиеш. Шуннан соң кеше терелә, янәсе.

**Қот алыну, қот очу (чыгу), қот қалмау** — бик нык курку, шүрләү. Каты куркудан була торган авыруны халыкта шулай **қот очу, қот чығу** дип йөрткәннәр. Очкан котны кире кайтару өчен төрки халыкларның күбесенә мәгълүм булган куркулык койу (кот койу, кот өндәү) йоласы башкарылган.

---

[1] сока кочок — ана эт

## Ҡото осу

**Ҡото осу** *к.-уф.* коты очу, курку.

— Эттән йә кешедән ҡурыҡтисә, баланың ҡото оса. Йоҡлағанда сискәнә, саташа. Ҡот ҡойдоралар.

## Ҡоты йарылу

**Ҡоты йарылу** *себ.* коты очу, курку.

— Ҡоты йарылаты бала-баҡраның[1], ҡот ҡойатылар — *төм.*

— Ҡоты йарылған кешенең йөрәге йарылаты. Туwасын биреп[2] ҡот ҡойатылар. Йөрәктәйен[3] пулып төшәте, кешенең ҡоты ҡайтаты — *туб.*

## Ҡот ҡойусы

**Ҡот ҡойусы әбей** *к.-уф.*,

**Ҡот ҡойатҡан мамай** *төм.* куркып авырганда кот коеп кешене имләүче.

«Ҡотым кил, ҡотым кил», —

дип саҡыра ҡот ҡойусы әбей — *к.-уф.*

## Ҡот теле

**Ҡот теле** *т.кам.-крш.* кот кою вакытында әйтелә торган сүзләр, рифмалашкан такмаклар.

— Ҡот телләре бар. Бик ҡурҡа ҡайсы бала, чырылдап ҡычҡырып күгәрә. Пышҡылтап ҡына ҡот теле әйтәм:

«Ишектән дә кер ҡоты,
Тишектән дә кер ҡоты.
Энҗе кебек тезелеп кер,
Җепәк кебек сузылып кер,
Ҡаз күк ҡаңғылтап кер,
Үрдәк күк баҡылтап кер», —

дип өч тапҡыр ҡолағына өрәсең. Шуннан бала ҡурыҡмый торған була.

---

[1] бала-баҡра — бала-чага
[2] туwасын биреп — догасын укып
[3] йөрәктәйен — йөрәк кебек

## Себер диалектларында қот қойу

**Тубыл–иртыш диалектында:**

— Қот қойған қурыққанға. Нейдән қурыққаны төшкән сурәт булып. Нейдән қурыққанны пелгәле қойғаннар. Йығылып қурыққанмы, перәй нимәтән[1] қурыққанмы.

— Қурықса қот қойаты. Нейдән қурықты, шул төшәте. Эттән қурықса — эт төшәте, сыйырдан қурықса — сыйыр төшәте, кешедән қурықса — кеше төшәте.

«Әпел-кәпел-кәпел,
Қот цықсын, қот керсен».

Әwәле қортқайақлар[2] муллийе[3] ғуй, уғынып утырғаннар.

— Қурыққанда қот қойатылар. Қурғашынны ереткәннәр. Қурғашын қайнап чыққач, суға қойғаннар. Нейдән қурыққан, анда төшкән. Сурәте төшкән нейдән қурыққан.

«Әперек, опырық,
Қурық цықсын,
Қот керсен».

**Қотны қат–қат қойалар:**

— Сине бөргәндереп утыратылар. Қара қурғашны бешем майға еретә дә табада, аны еретеп шул қурғашны қойатылар. Башыңнан аша табаққа қойадылар. Нидән қурықса, шул төшә. Аны қот төшкенце еретеп қойоп утыратылар. Аны қат-қат қойалар. Нидән қурықса, шул килеп төшә. Аны йөрәгең урынына килеп төшкенце қойоп барып утырасың. Ул йөрәкне пер йеп белән йөрәк йағына тегеп қуйатылар кийеменә.

— Пер қортқайақ қот қойопты. Перенцедә эт төшепте, үсебеснең этләр төшепте, игенцедә су төшепте. Инәсе белән атасы машина йуғалы төшкәннәр, қысцығацлары[4] суға төшкән дә киткән йөгереп. Инәсе су төшеп алыпты қысцығацны.

«Қурықың цықсын,
Қот керсен», —

тип әпләйтем малайны.

---

[1] перәй нимә — берәр нәрсә
[2] қортқайақ — карчык
[3] муллийе — мулла иде, ягъни дини, укымышлы иде
[4] қысцығац — кызчык

— Қурғашны эретеп, баш өстенә таштабақ[1] қуйып, қурғашны суға қойатылар. Қурыққан сурәте төшәте.

— Қасаннығына[2] ут йағайды да қурғашны эретеп қот қойаты, йөрәктәйен булып төшкәнце қойаты қотны — *туб.*

— Қот қойғанда нәстәдән қурыққан, ул төшә. Өч қабат қойа. Өч қабатында да төшә. Нимәдән қурыққан, ул төшәте. Порон бит бырач булған йуқ, өшкерү. Саwайа. Сәхмәт мәлғун[3] китәте.

**Қотны қырықберне қойа:**

— Қысым уйнағалы цығып китә, керә дә йата. Қот қойтоқ. Қас төште. Қастан қурыққан булған.

Қырықбер қурқулық қойтолар.

«Қот қойтым, қот қойтым», — тип башлап китәте. Шаннан қотылды.

Минең қәйнәм гәпләйте. Қартым үлгәц аwырдым, хәлем йуқ. Қырықбер қот қойдылар. «Йөрәгең йөрәк булып төшмәйте, йарасы қалды», — тиде. Аман йөреп утырам.

**Бараба диалектында қот қойу:**

— Қот қойадылар. Қорғашны эретәде, сыуға қот төшәде. Үлмәк балаға[4] қот көрәк булып төшәде, терелмәк балаға бала булып төшәде.

— Минең чүwәм[5] аwырды, айағына йөрә алмады. Башлық[6] чүwәмне саwайты, қурыққанға қот қойоп. Ул башлықның нәселләре әле дә бар булыр.

Мин қарап утырып торадым ул башлық эшләгәнен. Өчкә қәдәр қойто қорғашны. Чүwәм айағынан басты, йөрде. Чүwәм ул тыуғаным, миннән кечү. Имләмәкне ул башлық беләте.

Үлмәк кешегә қот йә көрәк, йә кәртмә[7] булып та төшә.

Шул қурғашынны чәченә бәйлиләр.

---

[1] таштабақ — тәлинкә

[2] қасаннық — казан асты, учак

[3] сәхмәт мәлғун — зәхмәт, җен

[4] үлмәк бала — үләсе бала

[5] чүwәм — сеңлем

[6] башлық — карчык

[7] кәртмә — чардуган

«Әп йөрәк тә йат йөрәк,
Ат башыдай таш йөрәк,
Им бол, том бол,
Мин имче түгел, мин томчы түгел».

Алай имнәп йаталар.

**Том диалетында қот қойу:**

— Эт талап қурықты ынугым[1]. Қурғаш эретәм, қот қойам.

«Име-томы бу булсын,
Әүлийәләрнең, әмбийәләрнең име булсын», —

дип башына су утыртасың да суға қойоп йибәрәсең. Ул өч қатар кирәк. Қурқуwы килеп төшә ди. Аны бик Шәмшенур белә.

«Ай да қайта,
Көн дә қайта,
Қот булсаң — син дә қайт», —

дип йақ-йағына өшкереп қойам. Қалған су белән битләрен, қулларын йуwам. Аны кеше йөремәгән йиргә түгәм. Қурыққаннары бис төшә инде сурәтләр булып. Өч көн қойарға кирәк қотны.

Кеше булып та, йәнлек булып та төшә икән. Кем нимәдән қурыққан, бетә икән. Бер уқымыш мамай бар ыйы.

## Қус-қот қойу

**Қус-қот қойу** *туб.* утлы күмерне суга салып кот кою йоласын башкару.

— Қус-қот қойатылар. Қус-қотны йақшы дип әйтәләр **күмер қотын**. Күмер — ғүмерне сақлый. Уң иңбашына утызып қойа.

— Қот қойған wақытта қурата[2] бер кем булмасын. Күмерне ике иңбашыннан туғыс пуwынға қойа ул. Икенце, өценце көнне тағы қойа.

Өценце көнне өстенә кигән кийемнәрен утқа ташлайты.

«Инте йулыңа кит».

---

[1] ынук [рус. внук] — онык
[2] қура — ишегалды

— Күмер, сыу апчығасың туғыс күпшек[1] белән сосоп. Йаңа табақ, йаңа чиләк. Күмерне башыннан қойаты.

«Минем қулларым түгел,
Йете күсәлләрнең қуллары,
Әүлийаларның қуллары».

Йөрәген әпләйсең[2] әкертен генә.

«Қотың килсен,
Қурықың цықсын», — тип.

Ул циләк белән табақны ике йул уртасына ташлыйсың.

### Қурғаш қот қойу

**Қурғаш қот қойу** *к.-уф.:*

— Қотны қойабыз аны. Аныңа қурғаш кирәк. Хәзер қурғаш тәңкәләр йуғ инде.

Қурғашны эретәләр, чынайақ тышын[3] баш түбәсенә утыр-талар, шунда қайнаған қурғашны қойалар. Нәрсәдән қурықса, шул төшә ти. Сурәтенә қарап өшкерәләр. Шуның сыwы белән йуwындыралар да ул қурғашны муйнына тағып қуйалар.

«Қотым кил, қотым кил», —
дип йаулық болғап сақыралар.

Қурғаш төшкән сыwын ике мәртәбә йоттырам:

«Име-томы шул булсын», — дип.

**Қурғашны баланың муйынына тағу** *к.-уф.:*

— Әлеге қурғашны алып, тишеге булса йеп белән тағып, тишеге булмаса тишеп, баланың муйынына тағалар.

Муйынына әлеге қурғашны таққач, ул шунда йөри. Бала аны қулы белән тотарға тийеш түгел.

Икенче кеше аны алып бәрергә тейеш, чүплеккә чығарып салырға тейеш.

«Аның тәнендә сиңа урын йуқ,
Қайан килдең, шунда кит.
Урының чүплектә», —
дип әйтәң дә бәрәң.

---

[1] күпшек — чүмеч
[2] әпләйсең — сыйпыйсың
[3] чынайақ тышы — чынаяк тәлинкәсе

### Қот суwы

**Қот суwы** *к.-уф., бараба.* кот койган су.

— Қот суwын әзерәк кенә эчерәң дә түгәң. Нишләтәң аны? Қот осса шулай итәләр. Әле дә бар ул — *к.-уф.*

— Минең исемгә дә қот қойдолар. Қорқып аурадым. Йөрәгемне күргәзделәр бер әбигә.

«Қот қойабыз. Қот суwы эчергәле кәрәк сийа», — тиде.

Башымға йаулық салып, қурғашны қайнатып, чаңнауны[1] баш түбәгә утыртып су өстенә қурғашны қойады. Аның суwын эчерделәр.

### Қоты төшү

**Қоты төшү** *к.-уф.* кургашны эретеп суга салгач, нинди дә булса сурәт рәвешенә килү.

— Элгәре тимер сүмес була торған ыйы, мунса сүмесе[2] дип йөртәләр. Қойоп эшләнгән сүмес була торғаныйы. Шуныңа таңсыуны[3] салып, эрегән қурғашны салып җибәрәләр. Нинди булып төшә ул қурғаш. Қоты төшмәсә, килешмәде дий торғаннар ыйы. Қайсысы биг әйбәт төшә килешеп китсә. Ул килешмәсә, бис сәселеп төшә дип әйтәләр әбиләр. «Баланың қоты төшмәде әле», — диләр.

### Қот чақыру

**Қот чақыру** — кот кою йоласын үтәгәндә рифмалашкан ырым сүзләрен әйтү, котны чакыру.

**Қот чақыру** *каз.ар.-дөб.:*

— Бала қурықса, чәршәмбе көнне суына доға уқып өрә, қотын чақыра:

«Кер, қотым, кер қотым,
Ишектән дә кер, қотым,
Тишектән дә кер, қотым.

Қайан чықсаң, шуннан кер,
Қаз күк қақылдап кил,

---

[1] чаңнау — чүмеч
[2] мунса сүмесе — мунча чүмече
[3] таңсыу — таң суы

Энҗе күк тезелеп кил,
Йефәк күк сузылып кил,
Җирән ат күк йарсып кил.

Қайдан чықтың — шуннан кер.
Кер, қотым, кер, қотым» —

дип белгән сүрәләрне уқып суға өрәсең инде.

— Чәршәмбе йомырқасын тозсыз ғына пешереп, қырық-бергә бүлеп, шуны ашата торғаныйы: «Кер, қотым, кер, қотым», — дип чақырып.

**Қот чақыру** *перм.:*

— Қәртнәйнеке[1] қәйнәсе[2] үлгән. Чолан ишекне ачқан да җибәргән икә, ақ кәпенгә[3] төргән, үгә килгәнне күргән. Артаа төшенә кергән қый, син мийән[4] қурықтың, сандық төптә ақ қурғаш бар, ақ қурғашны алып қот қойдыр, ул қойған қурғашны алып йанына тақ, артаа төзәлерсең, дигән. Ул қотны қойған, шуны йанына таққан.

— Миңке малайнықы өч айлық чағында қоты алынды, йылый да йылый, туқтамый, қалтыранып тора йы. Әни әйтә: «Килен, оланның қоты алынған, мулла бабайға бар», — ти. Қурғаш алып барасың. Шул қурғашны эретә мичтә, мөрҗәләрне ача, олан җата. Бер савытқа қурғашны төшерә суға. Нәрсәдән қурықса, шул барлыққа килә қурғаштан.

«Кил қотым, кил қотым,
Күгәрчендәй гөрләп кил,
Қыр қазыдай тезелеп кил,
Ақ җыландай сузылып кил», — ти.

Мөгешләрдән[5] қычқырасың, тәрәзәдән қычқырасың, мөрҗәдән қычқырасың. Сақаллы урыс бабай сурәте төште. Улан шуңан қурыққан булған. Аңан сун қоты алынғаны бетте.

---

[1] қәртнәй — әби, әтинең яки әнинең әнисе
[2] қәйнә — кайнана
[3] кәпен — кәфен
[4] мийән — миннән
[5] мөгеш — почмак

Ақ қурғаш була, ақ тастимал[1] җабасың, мөрҗәне ачасың:

«Қотым кил, қотым кил,
Җылы баwырларыман чықма инде.
Кил қотым, кил қотым,
Җылы баwырларыма, җылы эчләремә кер», — ди.

Ул кемнән қурықса, шул қурғаш шуғары[2] ушап төшә, нимәдән қурықса.

Ишекне дә ачалар, төндөкне дә ачалар, учағ аwызнықын да ачалар, шунда чақыралар, буйнына ап-ақ сөлге салалар:

Кил қотым, сылу қотым,
Қайан керден, шуннан чық,
Ишектән чықсаң, ишектән кер,
Төндөктән чықсаң, төндөктән кер,
Баланың йөрәген йарсытма.

Шул қотны судан алып күкрәгенә тегәләр, баланың аwыртынуы, қурқуы басылғач, алып қуйалар.

**Қот чақыру** *нокр.:*

— Қурқып қала ич ол-қыз. Иттәнме[3] қурқа. Усал итләр була, чып-чын ул. Қурғашынны эретәсин, аласин да баш эстенә саласин. Кем аwырта иде, беттегесе тешә кургашка. Пирбуйын эч қат белисин инде, кечтик[4] чақта қойалар, чүмечкә, суық суға эссе қурғашны қойасин. Җен кебек тә төшә, ит булып, песәй булып та төшә.

«Қоты қорый, қоты қорый
Қайт қоты, қайт қоты», —

дип әйтеп тора.

**Қот чақыру** *к.-уф.:*

— Қотны қойам үзем. Элек тәрәзәдән тәрәзәгә йөреп сығасың:

«Қоты осқан, қоты осқан,
Тәрәзәдән сықсаң — тәрәзәдән қайт».

---

[1] тастимал — тастымал
[2] шуғары — шуңа
[3] ит — эт
[4] кечтик — кечкенә

Мискә киләсең дә этисенең исеме белән әйтергә кәрәк баланың. Ул сиксән йәшлек әбиләргә дә булыша қот қойу.

Мис[1] йанына барып әйтәсең, ишекне әз генә асып, ишектән өс мәртәбә әйтәсең:

«Ишектән очсаң — ишектән қайт,
Мистән очсаң — мистән қайт», — дип.

Сыуны табаға салаң, чима қаптан[2] чиманы чийаң[3] қурғашны эретеп, шул сыwық сыуға салаң сүмес белән. Баланың йөрәге төшсен, йөрәк фурмысы төшсен. Шул төшкәнсе қойаң сыуға. Қурғашын эрегәнсе сақыраң инде баланың қотларын тастымал тотоп.

«Кил қотом, кил қотом,
Тәрәзәдән сықсаң, тәрәзәдән кил,
Ишектән сықсаң, төндөктән кил,
Менә Wәзимнең қото осқан,
Қото кил, кото кил», —

дип сақыраң қотны.

Артаба қылыхуалла уқып, сыуға салаң қотны. Шул қурғаш төшә белеки генә булып, йоп-йомро, ыспайы булып, йөрәкле булып төшә.

Қоты нығ осса, қурғаш бер дә җыйыла алмый, сәселеп тик тора. Әйбәт булдисә, килештисә, ыспайы булып төшә йоп-йомро булып.

Қотны аны сақырырға кәрәк.

Кер қотом, кер қотом,
Тәрәзәдән сықсаң — тәрәзәдән кер,
Ишектән сықсаң — ишектән кер,
Төндөктән сықсаң — төндөктән кер,
Кер қотом, кер қотом,

дип сақырам.

Табаны тотаң баш түбәсендә, тастымал йабып башына. Табадағы сыуға сүместә эретеп қурғашны салып җибәрәң.

---

[1] мис — мич
[2] чима қап — шырпы кабы
[3] чима чийа — шырпы сыза

Нәрсәдән қурықа, рәсеме төшә қурғаштан. Шуны баланың буйынына тағып қуйалар.

— Инәйем қот қойа торғаныйы, мин күрми қалдым. Мин килдем Гөлчичкә әбигә, әйдәле қот қойоң балаға дип. Қурқып қалған ыйы балам. Үзем дә қойарға-нитәргә беләм инде, бөтә белмәсәм дә.

Қотом кил, қотом кил,
Тәрәзәдән сықсаң, тәрәзәдән кер,
Ишектән сықсаң, ишектән кер,
Мөрҗәдән сықсаң, мөрҗәдән кер, —

дип әйтеп өстөннән қойасың сыуға. Эрегән қурғашны қойасың. Башқасын белмим.

**Кот чакыру** *миш.д.* (темников сөйләше):

— Куркынган кешегә кот кийалар, кот чакыралар:

«Кил котым, кил котым,
Бийек тауның башыннан,
Йефәк кебек сузылып кил,
Энҗе кебек тезелеп кил,
Көмеш кебек йалтырап кил».

## КУРКУЛЫК

**Куркулык** ТТАС — куркудан яки курку тудырган авырулардан дәва итеп кургаштан коела торган кот.

### Куркулык кою

**Қурқулық қойу** *минз.* нәрсәдән дә булса курыккан кешене имләү.

— Қурқулық қойғаннар. Қурғашны эретеп суға сала, шуның сурәте төшә. Шул сурәтен пичкә йағалар. Айақлы булып төшкән сыман итә, хайwан сыман булып төшә, қолақлы булып та төшә.

**Үрмәкүч ойалары** да эчерәләр ийе қурыққанға.

Балалар қурықса, табаны әйбәтләп утта қыздырасың, қурғаш тәңкәне шуңар саласың. Шул тәңкә эри. Эргәчен суға саласың да аттан қурықсаң — ат төшә, мәчедән қурықса — мәче төшә, эттән қурықса — эт төшә. Менә шушы Тансийәмне

минем гел қурқулық қойып қына үстердем. Җәмәй қатыны белә ат җигә торған ыйық та китә торғаныйық — *т.кам.–крш.*

**Қурқулық қойу** *каз.ар., т.я., нокр.:*

— Қурқулық қойарға кирәк туғыз даға белән, йә қурғашын белән. Һич булмаса қойған балаwыз белән. Туғыз дағаны туғыз төшкә қуйып қурқулық қойасың. Иң элек баш түбәсенә, андары ике айаққа, туғыз дағаны шулай эшлисең — *каз.ар.–дөб.*

— Матча турысына утыртасың баланы қурықса, қурқулық қойасың. Қурғашны эретәсең дә су эченә қойасың.

> «Қурқуны үзеңә ал,
> Саулығымны үземә бир, йарлықа» — *каз.ар.–мам.*

— Қурқулықны элгәре қурғашыннан қойғаннар, кече атна, дүшәмбе көнне қойалар — *т.я.–трх.*

— Қурқа қала ич ол-қыз, иттәнме қурқа, усал итләр бар, қазданмы қурқа. Қурғашны аласин, эретәсин, аласин да баш өстенә қуйып эссе қурғашны қойасин, беттегесе тешә. Җен кебек тә тешә. Эч қат қойалар — *нокр.*

— Қурғашын қойдоқ иттән қурықса, ничек табасы итнең йонон. Ит йонон утап китергән. Эретәсе қурғашынны, сөлге саласин баш эстенә, қурғашынны суға қойамин, эретәмин. Қурыққанны қурғашын бетерә. Әйтеп өшкерәсе қурғашын қойған суны, битен йуасы — *нокр.*

**Куркулык кийу** *чст.:*

— Кургашны эретеп су эценә кыйа, баш түбәсенә куйып. Кургаш терле сурәтләр белән төшә. Аннары шуны бишек бегәлцәсенә элеп куйа.

— Куркулык койдырганнар кургаштан. Нәрсәдән курыкса, шыл төшә тырган булган. Нацар гына йеп белән beлә genә бәли тырган булганнар ул кургашны. Үзе эзелеп тешәргә икән. Нацар гына шакмак йебе белән бәләп куйа да үзе тешеп шыннан йугала ди. Аннан инде терелә тырган булган.

**Куркулык кийу** *т.я.–крш.*

— Куркулыкны эретәләр дә, куркып чирләгән кешенең алдында суга тамызалар. Нийәрсәдән курыкса, шул төшә. Аны нәзек кенә җеп белән бәйләп муйнына астыралар. Шул эзелеп төшкистән курку китә ди.

## Қурқылдый қойу

**Қурқылдый қойу** *әстр.* куркулык кою.

— Қурқылдый қойу диләр. Өстенә ақ зат йабалар.

— Бусағаға атландырып утырталар. Қурғашынны эретәләр. Өч кәрәм қойа. Йатқызып та қойа.

«Ни зат қойасың балам?»

«Қурқылдый қойам», — ди.

## Қурқылдық қойу

**Қурқылдық қойу** *әстр.* куркылдык кою.

— Қурықсаң қурғашын эретәләр. Берәү сорап тора.

«Бу кешегә ни зат булған, ни қойасың?»

«Бу кеше қурыққан, қурқылдық қойам», — ди.

Қурғашынны суға қойа, шыр итеп чәчелеп китә. Икенче көнне тағын сорый:

«Ни зат қойасың?»

«Менә Туқтамыш қурыққан, қурқылдық қойам», — ди.

Берәү сорый, берәү эшли. Өченчесендә қурыққан зат төшә. Аны ала да муйнына таға җеп белән. Үзе төшкәнче йөри, шуннан бетә.

## Қурықлық қойу

**Қурықлық қойу** *әстр.* куркулык кою.

— Бала қурықса, қурыққан балаға қурықлық қойадылар. Уқып, өшкереп, шуннан инде бала саwығады. Менә Балшикәр мамай[1] қойа торған иде. Баламның арқасын эт тешләде, бу қурықты. Шуннан соң қурғашыннан қурықлық қойды, этнең сурәте дә төште. Қурғашынны эретә, суны табаққа салып, баланың баштүбәсенә қуйып, шул қурғашынны суға сала. Суда шуның сурәте төшә.

— Қурғашын белән қурықлық қойдырады. Менә үзем дә уттан қурықтым әле, қурықлығымны қойдорайым дип йөрийем.

— Менә қызымның баласы йағаға[2] суға барғанда йығылып қулын сындырды, қурықты. Қурықлық қойдорма кеше тап диләр. Таптым, килеште.

---

[1] мамай — әби

[2] йаға — елга

— Қурғашынны эретеп, шумақай[1] белән суға қурықлық қойатылар қыйблаға таба қарап. Әдәмнән қурықты — әдәм төшәте. Мин үзем қурықлық қойам.

«Им булсын, қарағым[2]», — дип қойам.

### Қурқынды қойу

**Қурқынды қойу** *әстр.* куркулык кою.

— Қурқынды белән имнәгәннәр бала қурықса. Қурғашынны эретеп қойалар салқын суға. Бала нәрсәдән қурқынды, шуның сурәте чыға икән. Менә эт қабамы[3], бақадан йә йыланнан қурқамы.

Өч мәртәбә қойасың өч көн:

«Қайан килдең, шунда кит,
Аwыру булсаң, салып кит,
Сау булсаң, салып кит», —

дип әйтәсең. Өч мәртәбә әйтәсең барын да.

### Куркындыктан башыру

**Куркындыктан башыру** *м.-кар.* курыккан кешене имләү.

— Куркындыктан башыру инде шул, бер кара әрбигә ипиләр, җарма, тыз, бакыр бәйләп ыргыталар икән. Җул айырмаларына ыргыталар икән.

### Куркыныч салу

**Куркыныч салу** *т.я.-крш.* куркулык кою.

— Бала курыкса куркыныч салган. Кургашынны ереткән дә башына куйып суга салган.

«Нидән курыккан, шул төш», — дип ереткәннәр кургашынны.

— Ул кургашынны беләгенә бәйләп җибәргән. Шал кургашын өзелеп төшеп җугала бала кулыннан. Шал җугалгистан куркынычы чыга аннары.

Куркыныч салмалы әбиләрне эндәшкән, шалар җанына алып барган.

---

[1] шумақай — чүмеч
[2] қарағым — иркәләп әйтү
[3] эт қаба — эт тешли

## Қурғыц доғасы

**Қурғыц доғасы** *себ.* куркулык койганда укыла торган дога.

— Им-томчылар булаты, қурғыц доғасы уқыйтлар.

> Ләхәүлә wәләхүwәтә,
> Алла тәгәлә, бу баланың
> Қотын кергес эценә,
> Қурғыцын ал үсеңә, —

тип уғынып, белгәннәрен әйтәте — *төм.*

## Курку кийу

**Курку кийу** *срг.* куркулык кою.

— Олан нәрсәдән булса курыкса курку кийалар иде. Шынди кургашын була, самаwырдан эргән кургашын. Шуны эретәләр, ыланның башына дустыган белән су тоталар. Шуны кийалар суга.

«Ни кийасын? — Курку кийам».

«Ни кийасын? — Курку кийам».

Нәрсәдән куркынган, шул сипат анда тешә. Мацыданмы куркынган, коцоктанмы, шул сипат төшә. Курку киганда оланны бусагага утыртып кийа, түндәккә утыртып. Суда күренә — *срг.*

**Курку кийу** *кузн.* куркулык кою.

— Балаwыз белән курку кийасың. Урта бусагага утыртасың да, догасын укып курку кийасың. Нәрсә чыга. Минем малайыма җылан чыкты. Балаwызны эретәм дә салкын суга салам. Шул төшкән әйберне муйнына тагып куйа, йөргәндә үзе төшөп кала. Матча турысына утыртып кийам, өйнең урта бусагасына утыртып кийам.

**Курку кийу** *влгг.* куркулык кою.

— Курыкканга кургашынны эретәләр дә шыны кийалар бер чашкага.

«Ни кийасын?»

«Курку кийам».

Йанында бер кеше кычкырып сорап тора өч кат, син әтеп торасың. Ул кургашын инде кеше нәрсәдән курыккан булса, шул булып төшә. Аннан аны бун'ына тага йеп белән, элеп берике көн йөретә, аннан ул үзе йезелеп төшә.

## КҮЗЕГҮ, КҮЗ ТИЮ

**Күзегү, күз тийү** — берәр кеше карашының, күзенең магик тәэсире нәтиҗәсендә авыру, бәхетсезлек барлыкка килү (ТТАС, 289).

**Күзегү күз тийүне** имләүгә караган лексика һәм им-том сүзләре, им-том әйберләре һәм имләү хәрәкәте атамалары җирле сөйләшләрдә бик күп һәм гаять кызыклы.

### Күзегү

**Күзегү** *әстр.* күз тию.

— Күзеккән дип мамайга[1] күрсәтәде. Йегерме тийен ақчаны пычақның очына салып, кендеге өстендә әйләндереп торады. Маңлайына сызады қан чығарғанчы. Башларына төрле сәдәпләр асады, тумар[2] тағады, таң суwы алады.

**Күзегү** *глз.* күз тию.

— Бала йыласа ки, артыш белән төсниләр. Күзеккән дип.

### Күсләгән

**Күсләгән** *себ.* күзе төшкән, күз тидергән.

«Күсләгәннең күсе цықсын,
Телләгәннең теле шешсен,
Минем қулым түгел,
Фатыйма апалар, Ғайшә апалар қулы», —

тип, цеперәк[3] белән басып цығасың башларына.

### Күссенү

**Күссенү** *себ.* күз тию.

— Бала йоқламый, йылый. Минең қәйнәм[5] тәрәсәнең йете өлгесен қулы белән сөртеп, баланың қулларын, айақларын сөртә, бала йоқлап китә.

---

[1] мамай — карчык
[2] тумар — бөти
[3] циперәк — чүпрәк
[4] қәйнә — кайнана

— Қунақлар килсә бала күссенә, йоқламый. Табақ-са-wытлар йуған суны қулы белән битенә сөртә. Бала йоқлап китә.

### Күз доғасы, кус туwалық

**Күз доғасы** *к.-уф.*, **кус туwалық** *себ.* күз авыртканда яки күз тигәннән имләгәндә әйтелә торган дога, им-томнар.

— Күз доғасын уқып өшкерә күз тигән баланы — *к.-уф.*

— Кус туwалықларны сөт белән йастылар ғыйлем қортқа-йақлар. Урыс күсе тисә, кус туwалықны сөткә салып эцертәләр.

— Күн белән тышлаған туwалық йазып бирделәр ғыйлем қортқайақлар.

### Күз печәне, күз үләне

**Күз печәне, күз үләне** *к.-уф.* күз тигәннән им-том итү үләне.

**Күз печәннек** *к.-уф.* күз тигәннән им-том итү үләне үсә торган җир.

— Имин көнне җыйалар күз печәннектән печәнне.

**Күз печәне беләң төтәсләү** *к.-уф.* күз тиюдән имли торган үләнне яндырып төснәү, төтен чыгарып имләү.

— Күз печәне дигән үләнне таудан җыйалар. Монда тауда үләннәр күп. **Әремнәр, таш әремнәре, күз печәннәре** җыйған-нар қаладан килеп.

**Күз үләне** бик йахшы күз тигәндә, шул ғына анықы им. Күз үләне менә Арыслан таwында үсә. Ул бик әйбәт, ул тау тулық күз үлән беләң.

**Күз үлән** диләр, арйақта тауда үсә. Ире менә күзенә чы-быртқы тийеп сукырайа йазды. Күз үләне беләң им иттеләр.

Күз үләнен төтәслиләр дә баланы шул күз үләненеке төте-ненә тығалар.

Күз печәне беләң төтәсләгәннәр күз тигән баланы. Төтенен генә искәткәннәр.

### Кус қайтарып өшкерү

**Кус қайтарып өшкерү** *туб.* күз тиюдән өшкерү.

— Қаты кусле кешенең күсе тийә, кус қайтарып өшкерәләр.

## Күз теле

**Күз теле** *глз.* күз тигәннән өшкергәндә, имләгәндә әйтелә торган ырымлы сүзләр. Гадәттә, алар рифмалашкан булалар.

«Алтын бишектә алтын бала,
Алтын балаға күз тимәсен,
Алтын бишекккә тисен.

Көмеш бишектә көмеш бала,
Көмеш балаға күз тимәсен,
Көмеш бишеккә тисен.

Бақыр бишектә бақыр бала,
Бақыр балаға күз тимәсен,
Бақыр бишеккә тисен.

Тимер бишектә тимер бала,
Тимер балаға күз тимәсен,
Тимер бишеккә тисен.

Җиз бишектә җиз бала,
Җиз балаға күз тимәсен,
Җиз бишеккә тисен», —

дип әйтеп өреп қуйамын күз телен әйтеп.

**Күз теле** *к.-уф., крш.:*

— Күз телен әйтеп өшкерәм күз тигәнгә. Пирwуйға әлхәмне[1] уқыйм, анан әбҗәтне[2], анан кылыхуалланы[3] — *к.-уф.*

— Қара диңгездә қара балық,
Қызыл диңгездә қызыл балық.
Қара балықның күзенә қачан күз тийә,
Бу балаға да шунда күз тисен — *т.кам.-крш.*

— Муча ташының өч мөгөшеннән[4] өч ташны алып чайқап, шуның белән җуwындырам — *к.-уф.*

---

[1] әлхәм— дини дога
[2] әбҗәт — дини дога
[3] кылыхуалла — дини дога
[4] мөгөш — почмак

## КАТЫ КҮЗ

### Айу күз, йаматай күз, йаман күз, қаты күз...

**Күзегү, күз тийүләр**, гадәттә, «қаты күзле» кеше караса була, дип ышанганнар. Им-том иткәндә тагын түбәндәге күз сыйфатлары да искә алына:

**айу күсле** *себ.*,
**йаман күз** *крш.*, **йаматай күз** *к.-уф.*, *перм.*,
**йәшел күз, күк күс, күкерт күс** *себ.:*

«Айу күсле булсын,
Йәшел күсле булсын,
Күк күсле булсын,
Күкерт күсле булсын,
Йәшен булып йәшнәсен,
Күк булып күкрәсен» — *себ.*

### Йаман күз

**Йаман күздән өшкерү** *глз.:*

Алтын тауда алтын читән,
Алтын читәндә алтын бағана,
Алтын бағанада алтын қарчыға,
Алтын қарчығаға қачан да қачан күз тисә,
Шул чағында балаға да күз тисен.

Әгүзе бисмилла әйтеп суға өшкереп бирәсин. Йаман күздән өшкерү була, көйсез баланы алай өшкерәләдек.

### Йаматай күз

**Йаматай күз** *к.-уф.* яман күз.

— Йаматай күз тигән булса, өстөнән күлмәген йыртып алып, аwылдан түбән суға ағыздылар.

### Қаты күз

**Қаты күз** *эстр.:*

— Күз тигән булса, шул қаты күзле кешенең кийеменнән бер кисәк кисеп алып, шуны йандырып, шуның белән төтәтәләр.

**Қаты күз** *к.-уф.:*

— Қаты күзле кеше була. Қаты күз тигән диләр. Қоро көнне[1] өшкөрәләр, күлмәген суға ағызалар.

**Қаты күс** *себ.:*

— Қаты күсле кешенең күсе тийә.

## Чағыр күз

**Чағыр күз** *глз.* им-том иткәндә телгә алына.

— Йаман күзләрнең,
Чағыр күзләрнең күзләре төшкән...

## Убыр күзе, җен күзе

**Убыр күзе тийү** *бәр.* каты авырып киткән кешегә карата әйтелә.

— Убыр күзе тигән булса, бер генә қат өшкереп бетми, абыстайға да, күремчегә дә бардық — *бәр.*

**Җен күdе тийү** *минз.* зәхмәт, «җен-пәри кагылу»:

— «Балаға җен күdе тигән», — дип күлмәк күнчегеннән ут төшерерләр ийе, утлы күмер төшерерләр ийе идәнгә өч тапқыр. Шулай қыландыралар аны.

## Йел күс

**Йел күс** *себ.* җен күзе.

— Йел күс тигәнне утлы қаwақ[2] ман қағалар.

— Пала қаты сықтаса йел күс тейде тип күк цеберәккә[3] тос салып, ишекнең, тирәснең тотқаларын сийып-сийып алып[4], баланың битләрен йуwып, ишек цығанағына қойасың. Алай қойу гәрәк.

## Йелле күс

**Йелле күс** *туб.* зәхмәтле, җенле күз.

— Йелле күсле гешеләр була. Йеле күсдән әпқороқлайым[5] мин — *төм.*

---

[1] қоро көн — шимбә көн
[2] утлы қаwақ — утлы ботак
[3] күк цеберәк — күк чүпрәк
[4] сийып-сийып алып — сыйпап-сыйпап алып
[5] әпқороқлый — имли

## Күз уғы

**Күз уғы** *том.* күз нуры, күз карашы.

— Күз уғы шунда қалсын дип, баланың кәпәченә[1] йыланбашлар[2] тегеп қуйдылар. Беренче күз шунарға төшә бит.

**Күз угы** *тмн.* күз карашы.

— Күз угы тигән дип өшкерәләр.

## Минзәлә сөйләшеннән күз тигәндә имләүләр:

[Им-том иткән суны өйнең эчке ягыннан бусага аркылы гына түгәләр]:

— И, бала күзсенде дип, җылый башласа, бер җомороға су салып, **ишек бауларын, бишек бауларын, тәрәзә өлгеләрен чайқап**, шулай итеп баланың башына сөртәләр ийе, чырайларына сөртәләр ийе дә шул суны **тупса арқылы түгәләр** ийе:

«Китсен, бетсен», — дип.

— Күз тигән дип җиде өлгенең тәрәзә парын йуып, бәләкәй генә саwытқа су салып, шул өлгене, ишекнең бу йақ тотқасын да чайқый, теге йақ тотқасын да чайқап аладырыйы да сөрткәлидерийе.

«Бу сабыйға ни булған?»
«Бу сабыйға күз тигән», —

ди, икенче кеше әйтә.

«Туғыз — туфыраққа китсен,
Җиде — җилгә қузғалсын,
Биш — бизеп китсен,
Өч — очып китсен,
Бер — берлексез булсын».

— Қайсыбер кешенең күзе бик қаты була. Күз тигән дип, кемнең күзе тисә, шуның бер әйберен йандырып иснәтә.

— Қайсы кешенең күde қаты була, нық итеп туры қараса бала күзсенә. Шул қаты күзле кешенең кийеменнән бер

[1] кәпәч — түбәтәй
[2] йыланбаш — кабырчык

қыйпылчық қына кисеп алып, шуны йандырып, баланың танаwына искәтә. Килешеп китәдерийе.

— Йәш балаға күз төшә бит. Су аладырыйы да җоморо белән, баланың битен-қулын җуwадырыйы да теге суны **тупса арқылы түгәдерийе** дә саwытны тупсаға ғына қаплыйдырыйы.

— Морҗаларны, ишек тотқаларын, тәрdә парларын сөртеп имләрләр ийе күd тисә. Аны тышқа чықмыйча ғына, **тупса арқылы ғына түгеп қуйарлар ыйы**.

— Тәрdәләрне, ишек тотқаларын чайқап баланың битләренә тигерәләр дә ишек арқылы үdләре чықмыйча ғына түгәләр ийе ул суны. Күd тигәнгә им шул ыйы. Ишег арқылы атып қына бәрә қырыйға.

— Безне үрәттеләр. Пирбай табанына тидер диделәр күз тигәндә қапқа тотқаларын йуған суны.

— Ишек тотқаларын, тәрәзәләрне җуып балаға сөртеп алалар күз тисә.

«Күзе тигән кешенең күзе чықсын,
Күзе тигән кешенең күзе қысылсын»,—

дип әйтә-әйтә ишекне бер ачалар, су сибәләр дә тағы йабалар.

Тупсадан ғына сибәләр ул суны, үзләре чықмыйча ғына.

— Өч кешенең мунчасыннан өч мунча ташы алалар ыйы. Почмағы сайын бер таш алалар. Ул ташларны үdенең мунча ташына қуйа, алар қыза. Шул ташларны суға сала. Атап сала. Кемнең күdе тигән, қатын кешенекеме, җәш кешенекеме, ир кешенекеме. Шатырдап җарыла шул таш. Шуның белән өшкергән.

## К.-уф. (Урта Урал) сөйләшендә күз тигәннән имләүләр:

— Күмер, сыу алалар да күмерне сыуға салалар. Кемнең күзе тигән балаға, кем уйнатқан баланы.

«Ай қайтты, көн қайтты,
Син дә қайт».

Суwын сығарып түгәләр, бала басылып йоқлап китә артаба. Шулай өшкерәләр.

— Қаты күзле кеше була. Шуның күзе тейгән дип уйласа, бидерә белән сыу алып қайтқанда артынан килеп, сыwын урлап

алып, шуны эчерәләр икә шул сыуны. Битен дә йыwалар икә шул сыw белән.

— Күз тийеп көйәнәккә әйләнде қызым. Әней өстөнән күлмәген йыртып алды да аwылдан түбән сыуға ағызды, күлмәген ағызды. Йаматай күз, қаты күз тигән булған.

Бала йарсый, ақ күбеккә төшә. Өч тәрәзәнең буwын алдым, ишек тотқаны йудым, таба тотқычларны йуwыбалдым артаба. Йуған суны өстөнә бөрөктем.

Бер безнең қызға күз тейгән. «Җәмиләнең генә күзе тейгән, алып килең әле», — диде әней. Җәмиләне алып килгәннәр ийе.

«Тейгән ди күз», — дип төкергән ийе, бала сискәнеп китте дә йоқлап та китте шул арада.

— «Шул кешенең күзе тейгән», — дип чүперәген кисеп алып киләләр. Үзе киләлмәсә шулай итәләр. Шуның төтөнен искәтәләр. Бала йоқлап китә.

«Қара кешенең қара күзе тимәсен,
Қоңғыр кешенең қоңғыр күзе тимәсен,
Ай қайтсын, көн қайтсын,
Шушы балаға күз тигән,
Сурық-сурық-сурықсын», —

дийеп өшкөрәбез дә төкөрәбез инде.

— «Қоро көн өстеннән әйберен йыртып ал да өч йул айырмаға чығарып ор, сүләшмә», — диде. Син күр дә мин күр, бетте китте қый.

— Күз тигәндә уқып өшкөреп кенә бетереп булмый. Үзебезчә уқыйбыз да инде, йә ишек тотқасы йуwып алабыз, йә иләк аша өшкерәбез күз тигәндән, бик йақшы була. Қалған суwыбызны, өшкөргәннән қалған сыуны ишекне ачып,«выж» дип сығарып җибәрәбез, бәрәбез ишек аша, үзебез чықмый ғына.

— «Күздән өшкерәбез, күз тигән», — дип әйтәләр ийе имче әбиләр.

— Тәрәзә өлгеләрен сөрткеләп баланы йоқлатайы қайным қарт, уқымышлыйы.

— Мәшкә әйбәт икә, мәшкәне қоротып қуйалар икә мәшкәне. Шул мәшкәне йантыралар, қороғас ни йана инде. Шул мәшкә белән төтәслиләр баланы. Мәшкә дә, миләш ағасы да әйбәт.

### Урта диалектның бәрәңге сөйләшендә күз тигәннән имләүләр:

Җитмеш бер шыршының қабығын қайнат та шуның суы беләп қойондыр:

«Ат аунаған җирдә аунат,
Киртә тамчысын йалат».

### Урта диалектның нократ, глазов сөйләшләрендә күз тигәннән имләүләр:

— Күз тигәч өшкергәләдек. Өстәлнең өч сирәген йуғаладык та, өч эшик тэмирне, өч кучак тимерне. Су бөреккәләдек битенә, укып өшкергәләдек.

«Йаман күзләрнең,
Чагыр күзләрнең күзләре төшкән,
Ай кайта, көн кайта,
Бу да булсын.
Име-томы бу икән,
Бу да булсын», —

дип өшкергәләдек.

Күз тигәнгә артыш агач йиләген[1] кайнатып эчерә.

— Бала йыласа ки артыш белән төсниләр, күзеккән дип.

### Керәшен сөйләшләрендә күз тигәннән имләүләр:

Кара күздән, зәңгәр күздән,
Коңгыр күздән, усал күздән,
Җаман күздән, картлардан, җәшләрдән,
Кемнең күзе тигән, бетсен, китсен,
Үз көйенә кайтсын.

**Изүдән генә утлы күмер ташлый:**

— Күрше әби өчле-тугызлы гына әйтәдерийе дә менә моннан утлы күмер ташлыйдырыйы.

«Җандырам, бетерәм», — дип. Изүдән утлы күмер ташлыйдырыйы.

«Алтын тау, Алтын тауда алтын өй,
Алтын өйдә алтын пич,

[1] артыш агач йиләге — артыш җимеше

Алтын пичтә алтын чүлмәк,
Алтын чүлмәк эчендә алтын үрдәк».

«Кайчан да кайчан күз тигән булса, шул чүлмәк ачылсын», — ди — *т.кам.-крш.*

**Мордва-каратай сөйләшендә күз тигәннән имләү:**

— Күздән инде су башы ала'лар икән, су башы белән җыва'лар икән. Кашык, эстәл пычмакларын, ишек тыткаларын җывып инде, кемеш салып, тары җармалары салып, баланы җывып инде, шул суны бераз эчертеп, тушы җул айырмасына салалар икән.

**Тау ягы сөйләшләрендә күз тигәннән имләүләр:**

Тау ягы-керәшен сөйләшендә **тишекле гөмбә белән имлиләр, «тетем тетерләндерәләр»**.

— «И-и, шал карчык килгән ийе, күзе тигәндер инде, тишекле гөмбә китер әле», — дигәннәр. Гөмбәне ала да тетерә[1], тетем[2] тетерләндерә, чир-чорларны чыгарып җибәрә. Кипкән туйыра гөмбәсе була, пич түбәсенә куйабыз аны.

«И-и, кызыма күз тигән,
Зәңгәр күз, кара күз,
Чык күз, чык күз.
Мин тетерлим,
Ана Агиделнең арйагыннан
Бер лашман карчык килгән,
Шул карчык тетерә.
Башында бер бөртек чәче бар, ди,
Аwызында бер теше бар ди.
Шул карчыкка качан күз тийә,
Минем кызыма шул чакта күз тисен.

Су кебек агып кит,
Көл кебек очып кит, тфү, тфү.

Тишекле гөмбәне кийаш уңгайына әләндерәм, тигезәм. Көлен очыралар.

---

[1] тетерә — төтенләндерә
[2] тетем — төтен

Чык күз, чык күз,
Чык җаман, чык җаман.
Кара җирне темәтсен,
Җәшел җирне каралтсын,

ди, тишекле гөмбә белән тетерә, анчак чыга ул.

Ак күз, кара күз,
Белгән күз, белмәгән күз,
Зәңгәр күз, коныр күз, усал күз.
Чыксын да китсен,
Бала өстендә тормасын.
Мин эшкермим,
Аша Батман карчыгы килгән,
Шал эшкерә, шал чыгара, —

дигән. Тишекле гөмбә белән тетереп тора.

**Тау ягы-тархан сөйләшендә туйыра гөмбәсе, ягъни имән гөмбәсе белән өшкерә:**

Туйыра гөмбәсе белән өшкерә, фәләқ сүрәсе уқыйлар:

«Күз чық, күз чық,
Зәңгәр күз, чық,
Қара күз, чық».

Туйыра гөмбәсен йандырып төсни.

**Мишәр диалекты сөйләшләрендә күз тигәннән имләү:**

— Көпчәк эзендәге иске чабатаны алып кайттым, абыстай әйтте. Күзексә, чабатаны йандырам да көлен балага ышким, диде. Урыс чабатасы кергездем, үлгәндә калдыйы кызым — *чст.*

— Бала күзексә чар комын[1] майга кушып идән астына алып төшәләр дә балага ашаталар. Идән астына кашыгын да калдыралар — *мәл.*

— Кендеге төшә баланың, аны җийып куйалар. Бала күзексә, чайкатып эчерәләр дә койондыралар — *мәл.*

— Бер кеше керде дә: «Бәрәч, бу бала йөри дә мени», — диде. Ул цыгып китүгә, бу бала йыларга тотынды, эце китәргә тотынды.

---

[1] чар комы — тегермән ташы комы

«Адәм күзе агацны пицкә кертә,
Хайwанны казанга кертә,
Адәмне гүргә кертә», —

дигән сүзләр бар. Шул тугыз айлык бала үлде күз тийеп.

Менә кайын үсеп утыра. Карале бу кайынны, ницек матур үскән, ди. Кат'канда карасак, кайын шиңеп төшкән ди. Менә шынди агацны кырытырлык күзләр була, шынди каты күз була — *чст.*

— Бала йыласа да әбигә күтәреп кергәннәр. Әби баланы әнисенә тоттыра, айагын күтәреп әкерен генә баланың эценә тибә.

«Ник тибәсең?»

«Фәлән-фәләнгә күз тигән, шуның өчен тибәм».

Әби доганы укып өшкерә дә бала тынычлап йоклап китә — *чст.*

— Балага күз тисә, анарга кирәк табаклы аш[1] пешерегә, кимак пешерегә. Йә биш кимаклык кына атла, йә йиде кимаклык кына атла камырны, тегели[2] булмасын. Бабай аши инде шул кимакны, табаклы ашны — *кузн.*

**Әстерхан сөйләшендә күз тигәннән имләү:**

— Бер тустақайға[3] су қойоп аласың да ишек тотқаларын тотып чығасың. Шул суны баланың қашына, күз қабақларына, қолақ сыртларына, йөрәк башына, арқа тамырына, қулларына йағып **өч йул уртасына** чығарып түгә, йә ишекнең чығарағына[4] қойасың. Күз тигәннән шулай ошықлыйсың[5].

Имең-томың шул булсын,
Қайдан килсәң, шунда кит.

Қапқаның сыртына түгәбез шул суны, баланың қулларын, айақларын сөртә шул су белән.

---

[1] табаклы аш — им-том өчен пешерелгән ашамлык
[2] тегели — җеп санда, парлы
[3] тустақай — касә
[4] ишек чығарағы — ишек бусагасы
[5] ошықлый — имли

Әwəлдə йəш малай күтəреп қуншыға[1] керсə, тустақай бирəделəр киленгə. Баланың маңлайына сары иай йағадылар. Тустақайның эченə бер зат салып бирəде, күз тимəсен диде.

Себер диалектларында күз тигəнгə им-том итүлəр:

— Күк түберəкне[2] йетегə булү гəрəк, шуны йетегə бүлеп, йетесенə дə əwəл **тоз саласың, күмер саласың**, төйəсең.

«Күслəгəннең күсе цыққан», —

тип түберəкне айағының табанына хəтле басасың. Басып бетергəцен утта йағасың? Цəршəмбе көн гəрəк. Игенце, өценце цəршəмбедə дə гəрəк.

«Әдəмнең күсе йəш ағацны қоротор», — тиде. Паланы сарғайтып үтерəте — *төм.*

Күк цүперəккə тос төйəтелəр, имнəйтелəр. Аны утқа тығатылар. Ул цацырап цықса, тосно цəйнəп йөсенə төкерəтелəр. Төсəлеп китəте. Пырацтан тəре[3] алу йуқ.

— Өц төйөнцек қылып күк цүберəккə тос белəн басайлар, ибенə[4] имнəп цығатлар пөтөн йирен. Аны утқа ататлар. Ул утта шатыртап йанаты қаты күс тисə, цацырап китəте. Минем инəм қортқайақ күк цүперəккə тосно төйөп, аның белəн имнəп-имнəп утқа ататы:

Күс тигəннең күсе цықсын
Тел тигəннең теле цықсын.
Саламтай сарғайсын,
Күмертəй қаралсын.
«Минем йəшемə цық, төсəлеп кит», — ди.

Цəршəмбе көнне иткəннəр им-томны.

— Күс тийүгə күк цүберəккə тосны төйəсен, тəрəс рамнарын, ишек тотқаларын йуwасын, шал сыу белəн баланың маңлайын йышаты.

«Күсең ташқа тисен», —

тип, күк цүперəкне тосы белəн бергə утқа ташлайсын. Ул анта цацырап китсə, анықы күс тигəне қайта ти.

---

[1] қуншы — күрше

[2] түберəк — чүпрəк

[3] тəре — дару

[4] ибенə — бөтен җирен

Йыуған сыуны йулға цығарып цацаты.

— Менә аны әйтмәптем әле. «Син қысу-қысу йөреп йатасың» ти миңа, айағыма күс тиде, сыслап китте.

Иртәнге **нар төкерегем**[1] белән йышып[2] алам айақларымны та әйтәм:

> «Әғусе пилләһи...
> Раббым, сиңа сыйынамын,
> Синең рәхимең, шәпкәтең тисен», —

тип йышып-йышып қуйам. Петеп китәте.

Цәршәмбе көнне им булаты, дигәннәр — *себ.*

— Эре тосны күк цүперәккә төйнәп-төйнәп аны йанып утырған мейескә[3] атасың башыннан өйереп. Ул чарт-чорт йанаты. Сыуға салып балаға йоттыралар. Битләрен, қулларын, айақларын йыwалар.

— Күк түбергә көл салып, өц төйөн төйни. Көл салған төйөнгә wақ қына мәрчен[4] дә салаты, потақлы мәрчен булаты. Өц мәртәбә қыласың. Битенә, башына, айақ йөсенә тийен басаты. Пер қысым үлгән күс тийеп. Имләтә алмый қалтық қортқайаққа.

Им иткән көлне йилгә оцораты.

> «Йил белән оцоп китсен».

Ә тос белән имләсә, тосны утқа ташлап йийаты.

— Әптелмән маманы[5] алып килеп көл бастыратылар. Ыстаканға йылы көлне тутырды, қулйаулық белән өстән бәйләде дә мине урдыққа[6] салып, битемне битйаулық белән бөргәп, белгән айәтләрен уғып, көл басты. Баштан айаққа хәтле басаты, анан әйләндереп арқаға басаты. Ул көлне апцығып быргайты[7] сул йақтан. Шулай қулйаулық бөргәп басаты. Қулйаулықтан қойолмайты ул көл тың[8] иткәч.

---

[1] нар төкереге — беренче, иртәнге төкерек
[2] йышып — сөртеп, ышкып
[3] мейес — мич
[4] мәрчен — мәрҗән
[5] мама — әби
[6] урдық — сәке
[7] быргайты — ташлый иде
[8] тың — тыгыз

Перәүнең күсе тигән ите балама. Мин әле генә йуwып салған итем, перәү кереп таңланып[1] цығып китте.

«Сестән нинтәй сылу бала туwыпты, ыспайлап урап йатқырғансыс», — тип.

Иртәсе менә ике битенә цебешкеләр цықты. **Ай бетсә** — бетәте, **ай туса** — йаңараты битендә.

«Күс тигән» тиделәр. Йәшенәцә асаплантым. Сун минем туғаннарым, апақаларым имләделәр. Бер йәш тулғац үсе бетте.

— Күс тейсә палаға пес тәрәсә өлгеләрен, ишек тотқаларын йуwып, шал су белән баланы йуwыштырасың. Шал суны ишек цығанағына қойасың ти тегәннәр ите, шалай итеп имләй тегәннәр ите — *туб.*

Палаға күс тийәте.

«Алламнан шиба,
Миннән им», —

тип йалап-йалап ташлайтылар өцкәцә төкереп.

«Күсләре ташқа тисен», — тип төкереп қуйатқан ителәр пала асырағанта — *туб.*

— Кеше кереп-цығып йөри тупсатан, цүбе қалаты. Тос, күмер, ишек тупсаның цүпләрен салып имләйсең аны күс тигәнне — *тѳм.*

— Күс тимәсен тип ырымлап қуйасың, начар күсле кеше қарады ти. Тупсаны йуwасың, өшкереп түбәсенә қойасың — *тара.*

### Том диалектында күз тигәннән имләүләр:

— Күз тигәндә мин имним. Йарты чашкы су салам, әз генә тоз салам. Шул су белән, қулымның йөзе белән баланы йуwындырам. Битләрен, қулларын, күкрәген йуwам. Чаршамбы көнне йуwындырам. Қашық очы белән шул суны эчерәм. Имнәп-имнәп қапқаның йә ишекнең чығанағына[2] қойам.

— Күз тигән бала башын артқа тарта да йылый. Сыразы беләсең, балаға күз тигән. Мин ике рәт игезәк туған. Иске кийелгән ойоғымны бирәм. Имгә йарый. Йылаған баланың түшенә урый да йатқыра. Бала йоқлый.

---

[1] таңланып — сокланып

[2] ишек чығанағы — ишек бусагасы

**Мордва-каратай сөйләшендә карыш булу — күз тию:**

— Учук бабага бардык та:

«У, карыш булган икән, малайыгыз үләргә җиткән икән», — дип әйткән. Сүлә'ләп, сулар сипкәләп шул тергезде.

— Күз тигәнне текерәләр. Карышы булган, ир кеше карышы, катын кеше карышы, ди'ләр иде.

## КҮЗ ТИЮДӘН, ЗӘХМӘТТӘН САКЛАНУ ӨЧЕН КУЕЛА ТОРГАН ӘЙБЕРЛӘР

### Бөти

**Бөти** — хорафатларга ышанучыларның төрле бәхетсезлекләрдән, авырулардан, җен-зәхмәттән һ.б. «саклану» өчен тагып йөртелә торган (чүпрәккә өчпочмаклап яки бүтәнчә итеп тегелгән) догалыклары.

**Бөти** — борынгы төрки: **бит** — язу, **битиг** — язылган әйбер; СС — **битик** — хат, язу (Махмутова, 1982, 27); мишәр диалектының *тмн., лмб.* сөйләшләрендә — **бетег** — хат, язу: **бетек** *чст.* бөти: — Күзекмәс өчен бетек тагалар.

Җирле сөйләшләрдә тагын **бөтү** фонетик варианты да бар.

**Бөтү тағу** *к.-уф.:*

— Өс мөгөшләп тегәләр дә **бөтү** дип тағалар баланың муйнына. Анда айателкөрси йазылған була. Баланың күлмәк эсенә дә бөтү тақтылар.

**Баш бөтүwе** *чст.* баш бөтие.

— Баш бөтүwен цәцкә тагалар зәхмәт кагылмасын дип. Ике үрем арасына цәц төбенә куйалар. Күнгә тегәләр, су да, һаwа да керми.

### Дуwа

**Дуwа** [< гар.] *әстр.* дога.

— Күз тимәскә баланың муйнына дуwа йазып эләләр.

### Йалтырақ

**Йалтырақ** *әстр.* ялтыравыклы әйбер.

— Күз тимәскә такийасына йалтырақ қуйалар.

## Йыланбаш, қортбаш

**Йыланбаш, қортбаш** — күз тимәсен дип, кечкенә балаларның башлыгына тагыла торган әкәм-төкәм кабырчыгы.

— Баланың чепчигенә алынға йыланбашлар тегеп қуйалар күз тимәстән — *әстр.*

— Күз тимәскә дип қортбаш бәйлиләр балаға — *минз.*

— Күз тимәстән бәбәй башлығына тегеп қуйғаннар қорт башы, йә булмаса йалтыраwықлы төймә. Қортбаш сырлы-сырлы бик матур була ул — *минз.*

## Қорым

**Қорым тигезү, қорым сөртү** *урт.д., нокр., к.-уф.*:

— Бабай тугач күз тимәскә маңлайына κором тигезә, он сибә:

«Картайгынчы, кыртайгынчы тор», — ди — *нокр.*

— Күз тимәскә дип қором сөртәләр, йә күмер сызалар баланың маңлайына. Қайсысы әйтә:

«Қором аша күз тисә, имләп тә булмый», — дип.

Маңлайына қором сөртеп қуйасың, шуңа күзе төшсөн дийеп — *к.-уф.*

## Пыр

**Пыр** *себ.* корым.

— Маңлайына пыр сөрткән учақтан алып. Қап-қара пыр анықы, күз тимәстән — *төм.*

— Күз тимәсен өцен миралықтан[1] бармақ оцы белән генә алып пыр төртеп қуйатылар мийәсенә, ике қаш арасына төртеп қуйатылар пырны. Күс ул йәш ағацны да қорота игән, йәш баланы ғына түгел.

— Пыр, күмер йышып қуйатлар паланың маңлайына. Кицен апцығып китсәләр, кицен йөретсәләр маңлайына пыр йышатлар:

«Йел-күс тимәскә», — *туб.*

---

[1] миралық — төтен юлы

## Ҡуйан ҡойрығы

**Ҡуйан ҡойрығы** *к.-уф.* күз тимәскә баланың баш киеменә тагалар.

— Элек ҡуйаннар күп булды ҡый, ҡойрыҡларын алып ҡалдылар.

Ул ҡойрыҡны төрле сырға[1], йәшел сырға, бурлатҡа[2] буйарлар ыйы да баланың тупыйларына[3], күлмәкләренә тегәрләр ийе.

— Баланың тупыйларына, йаурын башларына күп итеп тектеләр ул ҡуйан ҡойрыҡларын, суҡлап-суҡлап тектеләр. Күз тимәскә дип тектеләр. Күлмәкләр тегә торғаннар ыйы суҡлар тутырып: «Шуңа күзе төшсен», — дип.

## Ҡуйан ҡолағы

**Ҡуйан ҡолағы** *к.-уф.* күз тимәскә баланың баш киеменә тагалар.

— Ҡуйан ҡолағы да тағабыз уланның[4] тупыйына. Ҡырдағы ҡуйанның тиресен тунағанда ҡуйан ҡолаҡны кисеп алабыз да шулай төрле сырға тығасың. Ҡуйан ҡолаҡны йәшелгә, күк сырға[5] тығабыз, төрлесе була.

— Кейәүләр ҡуйан тота ҡый әле дә. Ыспайы, матур ул ҡуйан ҡолағы. Аҡ көйөнчә дә тегәләр күз тимәскә. Күрткәнең[6] түшенә дә тегеп ҡуйалар матур итеп, әле дә тегәләр. Суҡлы нимә[7], ыспай нимә була.

## Чуҡ, суҡ

**Чуҡ, суҡ тағу** *к.-уф.:*

— Тупыйына бит ҡазның ҡойроғында суғы дип әйтәбез. Менә шуны баланың тупыйларына тегә торғаннар ыйы балаға күз тимәскә.

---

[1] сыр — буяу
[2] бурлат — куе кызыл
[3] тупый — баш киеме
[4] улан — бала
[5] күк сыр — зәңгәр буяу
[6] күрткә [рус. куртка] — өс киеме
[7] суҡлы нимә — чуклы әйбер

## Миләш ағачы

**Миләш ағачы тағу** *урт.д.:*

— Миләш ағачын қуйалар ыйы күз тимәскә. Қулларына бәйләп қуйғаннар белеки генә итеп кисеп миләшнекен.

— Баланың тупыйына миләш ағачы тағып қуйалар. Күз шунда төшеп қала, балаға төшмей, балаға күз тимей. Мин дә қызымныңы беләгенә тағып қуйдым шайтан килмәсен өчен дип — *к.-уф.*

## Пизел агачы

**Пизел** [морд.] *лмб.* миләш.

— Күз тимәстән тизел агачы тага кәпәченә — *лмб.*

## Сәдәп

**Сәдәп тагу** *к.-уф.:*

— Оланнарның тупыйларына нинди ки сәдәпләр, түмәләр салырлар ый күз тимәс өченгә.

## Тумар

**Тумар** *әстр.* бөти.

— Күз тимәскә балаға тумар эләләр.

## Тәңкә

**Тәңкә тегү** *к.-уф.:*

— Қыз бала булса түшенә, күлмәгенә тәңкә тегә торғаннар ыйы, беләгенә бәйлиләр тәңкә, муйынына тағалар көмеш тәңкәне тишеп.

## Хәситә

**Хәситә кидерү** *каз.-ар.* балага тәңкәләр һәм кечкенә бөти тегеп ясалган хәситә кидерсәң, күз тиюдән саклый дип ышанганнар.

— Хәситәне үземнең әбийем тегеп йасар ыйы. Тәңкәләр, миләш аачы, бөти дә қуйа қайсы кеше — *каз.ар.-блт.*

## ТАҢ СУWЫ

**Таң суwы** — нәрсә белән булса да чирләгән, күз тигән, курыккан дип шикләнгән кешеләрне им-том итү өчен таң алдыннан ырымлап алып кайткан су.

### Таң суwы алучы

**Таң суwы алучы әби** *минз.* им-том итү өчен таң алдыннан су алып кайтучы.

— Таң атқан wақытта бидрә[1] белән су алып қайтқан. Өч көн алған таң суwы алучы әби, уқып алған инде.

### Таң суwын алу көннәре

Таң суын алу атнаның билгеле бер көннәрендә, намаз укып, изге күңел белән башкарылса уңышлы була дигәннәр. Мисаллар минзәлә һәм красноуфим сөйләшләреннән китерелә.

— Таң суwын алу қойаш чыққанчы, таң беленгәнче алса әйбәт була. **Чәршәмбе, дүшәмбе** көнне алырға. **Намаз сөннәтен** уқып, фарызын уқығанчы алырға, сөннәт белән фарыз арасында алырға.

— Бигрәк тә ай азағында таба ахырғы чәршәмбедә алалар таң суwын — *минз.*

— Таң суwын **атна кич**, **җомға көнне** алырға җарамый.

— Таң суwын имгә-йомға[2] алғанда қоро көндә[3] алалар — *к.-уф.*

### Таң суwын алып қайту

**Таң суwы алу — минзәлә сөйләшендә:**

— Таң суwы алырға кичтән нийәтләп йатасың. Аллаһы тәғаләнең рәхмәте белән шул таң беленер-беленмәстә торасың, тәһарәтләнеп намазыңны уқыйсың, чиләгеңне алып су буйына чишмәгә төшәсең. Салаwат әйтеп, қыйблаға таба қаратып таң суwын аласың.

---

[1] бидрә — чиләк

[2] имгә-йомға — им-томга

[3] қоро көн — шимбә

«Су анасы җирән чәч,
Мин таң суwы алырға килдем.
Рөхсәт бирәсеңме миңа таң суwы алырға», —
дип әйтәсең.

— Таң суwы алырға нийәтләп йатқаннан соң аллаһы тәғалә үзе эшкәртә. Сиңа таң суwы алырға йарамаса, төшеңдә синең йулыңа арқылы төшәләр. Менә җулдан барған wақытта бер ақсыл-көрән ат килеп, ике айағын җилкәңә қуйа, таң суwы алырға рөхсәт бирми. Син таң суwы алып йатқанда үзеңә зәхмәте қағыла, алырға барырға йарамый.

— Мин бик күп кешеләргә таң суwы алып биргәләдем. Ике рәқәғәт намазымны уқыйм да нийәтемне нийәтлим. Кичтән чиләкләремне алып қуйам йапма йабып өсләренә. Хәдер мин бар белгән доғаларымны уқып шишмәгә төшәм.

«Су анасы сары сақал,
Җир анасы җирән сақал,
Өрөхсәт итегез менә фәлән-фәләннең
Улын йә қызын қойондыру өчен
Таң суwы алырға килдем», —
дип әйтеп чиләгемне қуйам, таң суwы тутырам.

Мин қатқанда **җулның икенче йағыннан әйләнеп қайтам**, кеше очраса да **эндәшмәскә, сөйләшмәскә**. Чиләкнең өсте йабулы инде. Күтәрелеп тә қарамыйчы мин таң суwын алып қайтам.

— Таң алдыннан таң беленә башлағач әғүзе-бисмилланы әйтеп, салаwат әйтеп, таң суwын аласың. Бик күп алдым таң суwын. Баланы җуwындыралар салаwат әйтеп. Береңә-береӊ эндәшмисең таң суwы алғанда.

— Айателкөрси уқып, әғузе-бисмилланңны әйтеп аласың суwыңы. Суwыңы алғач, өстенә тастымал қаплап алып қайтасың да қуйасың. Кемгә нийәтләп барғансың, шуңарға үзең җылытып қойондырасың.

Күзсенгән балаларны шул таң суwы белән җуwындыру ыйы.

«Илаһи нийәт қылдым алланың
ыризалығы өчен таң суwы алмаққа.
Йарабби, шифа булсын», —
дип әйтәм дә таң суwын алып қайтам.

— Таң алдыннан таң беленә башлағач әғүзе-бисмилланы әйтеп, салаwат әйтеп, таң суwын аласың. Бик күп алдым таң суwын. Баланы җуwындыралар салаwат әйтеп. Береңә-береңә эндәшмисең таң суwы алғанда.

— **Күзсенгән балаларны** шул таң суwы белән җуындыру ыйы.

> «Илаһи нийәт қылдым алланың
> ыризалығы өчен таң суwы алмаққа.
> Йарабби, шифа булсын», —

дип әйтәм дә таң суwын алып қайтам.

— **Қоръәннең соңғы өч** сүрәсен уқып, чын күңелдән:

«И аллам, үзең биргән чирне үзең ал», — дисең дә, беттекитте. Шул су белән қойондырасың — *минз.*

**Таң суwы алу — Әстерхан сөйләшендә:**

— Таң суwы ала бер әби. Таң намазын уқып, тәһарәтләнеп төшә Иделгә. Әле җиргә йақты төшмәгән була, қойаш тумаған була. Доғасын уқып ала, шул су белән баланы чайқандыра.

— Өч чәршәмбе таң алдында су алып, шул таң суwында қойондырырға кирәк. Суwын йулға чәчәсең:

«Басылсын», — дип.

— Таң суwын қойаш тумый йатып[1], йағадан[2] алып қайтабыз. Өшкерәбез дә балаға сөртәбез, йуwындырабыз.

**Таң суwы алу — чистай сөйләшендә:**

— Өч көн эрәттән алырга ди таң суwын агым судан. Таң суwы ышандырып калган кеше ике рәкәгәт намаз уки да инде таң аткан wакытта цыгып, салаwат әйтеп, шул суны ала. Тегенәргә бирә дә теге кеше койона шул су белән.

**Таң суwы алу — керәшен сөйләшләрендә:**

— Күзләр, башлар аwыртса:

«Таң суwы белән җу», — диләр.

Таң җарылганда төшәсең дә аласың. Чиләкне агымга түбән таба каратып алырга.

— Менә балаларга күз тийә, таң суwы алу бар. Иртә беләбер кеше торгынчы сәгәт икедән аласың, исеме белә әйтәсең.

---

[1] қойаш тумый йатып — кояш чыкканчы

[2] йаға — елга

«Пәлән кешегә **таң төшкән,**
Таң суwы алырга килдем», —

дип суга үргә таба өч тапкыр алып саласың да, кайтканда да бер дә артыңа карамыйсың, кеше очраса да эндәшмисең.

«Күз тигән, шушының белән бәкиллә», — дип җуwасың шул су белән.

Бер кеше күрмәгәндә генә төшереп саласың — *т.кам.-крш.*

— Таң суwы белән җуwындырганда, әйтеп-әйтеп җуwындыралар:

Сыw буйында сыw җары,
Сыw җарында сыw ташы.
Шул ташны кем исәпләп чыкса,
Әлеге кешегә күз тисен.

Сыw буйында сыw җары,
Сыw җарынды кәбестә башы.
Шул кәбестәне кыйа киттем.
Аның башын кем исәпләп чыкса,
Шул кешегә күз тисен.

Сыw җарында ак җитен,
Бу җагында күк җитен.
Җитен башын кем исәпләп чыкса,
Әлеге кешегә күз тисен.

— Таң суwын кийаш чыкканча су уңгайы алалар. **Кырк та бер кашык** санап, битен җудырыга ыланнар чирләгәчтен, үзесен дә кийындырган. Кырк та бер кашык акайтырга кушалар. Аны су күбекләнеп аккан тыштан алырга кушалар.

**Таңсу алу — Удмуртиядәге глазов сөйләшендә:**

— Бәбәй йыласа ки таңсу алдыралар иде. Кем йылгага, кем шишмиги барып алдыралар иде таңсу.

Ул таңсуны артышлар салып пичтә йылыталар иде дә баланы койондыралар иде мунча кергәндә.

— Таңсуны өч койодан таң атканчы аласы була. Таңсуны укышма белгән кешегә алдырасы булайы. Ни ки чәйнүк белән алгаладылар таңсуны.

«Сабый балалар, күзсенгән балалар өчен, сихерләрне куар өчөн», — дип әйтеп алырга кирәк таңсуны.

**Таңсу алу — к.-уф. (Урта Урал) сөйләшендә:**

— Намаз wахытта, көн[1] тыумас борон бараалар таңсыуға. Йә күз төшә балаға, арта өшкөрәсең, битләрен йыwасың, эчереп тә қуйасың шунда. Бала өшөнеп китсә дә таңсу килешә. Йуғач таңсуны қарағат төбенә салабыз, теләсә қайда күммибез инде аны. Өч йул айырмаға да түгәбез.

### Таңсу белән қот қойу

**Таңсу белән қот қойу — к.-уф. (Урта Урал) сөйләшендә:**

— Йылғадан таңсу алып, шул таңсу белән өшкереп қот қойалар. Қурғашны қыздырабыз, таңсуға салабыз. Қоты очқан булса, **қоты төшә**.

### Тансуға артыш ағач салу

**Тансуға артыш ағач салу — Удмуртиядәге глазов сөйләшендә:**

— Алып қуйар идем таңсуны чишмәкүздән[2]. Ул таңсуға артыш саласин, пички қуйып кайнатасин, мичада аны қойондыралар ул су белән. Таңсуны артыш белән пички тығалар алай.

### Таң суwына мунча ташы салу

**Таң суwына мунча ташы салу — минзәлә сөйләшендә:**

— Бала чирләсә, чиләк белән таң суwы алып қайтырлар ыйы. Шул таң суына **өч кешенең мунчасыннан мунча ташы** алып қыздырып салырлар ыйы. Кеше күрмәсен ул мунча ташын алғанны. Өч кеше мунчасыннан таш алып чығып, қыздырып таң суwына сала, шул су белән қойондыра баланы.

Таң суwына елға яки чишмәдән алынған ташны салу — минзәлә сөйләшендә:

— Таң суларының бик күп әҗере. Таң беленгәндә таң суwы алырға кирәк **салаwат әйтеп.**

«Менә шушы сабыйға шифалық өчөн алам», — дип, су төбеннән бәләкәй генә таш алып саласың суға. Шул ташны саласың да таң суwын алып қайтасың таң беленгәндә. Ул

[1] көн — кояш

[2] чишмәкүз — чишмә

ташны киптерәсең инде судан алып, утта қыздырасың. Шул қызған ташны суға салырға кирәк. Чажнап китә. Шул су белән баланың битен-қулын йуwасың.

### Таң суwын кире илтеп салу

**Таң суwын кире илтеп салу — минзәлә сөйләшендә:**

— Баланы йуwындырғач, таң суwын алған җиренә кире илтеп саласың, чәчмисең, түкмисең аны.

Таң суwын кире илтеп салғанда, бисмилларымны, салаwатларымны әйтеп салам.

«Шифалары насыйп булсын, раббым, рәнҗемә инде», — дип.

### Таңбикә әбей, Таңсыу әбей

**Урта Урал — к.-уф. сөйләшендә:**

— Таң атқан wақытта, Таңбикә әбей белән сөйләшергә кәрәк таң сыwын алырға.

«Таңбикә әбей, таң сыwыңы бир әле.
Рамазан қызы Айсылуға таң сыwы кирәк.
Бездән йаулық, синнән саулық», —

дисен. Таңсыуға бер үзең генә бараң, кеше кәрәкмәй аныңа.

Таңсыу әбей, сыу бир,
Шундый-шундый балаға.
Имгә-йомға сыу кәрәк.
Озон сәсле, зифа буйлы,
Көмеш тешле сыу қызы,
Сыу биреҥ мийа, —

дип сурап алаң сыуны.

### Таңсыубикә

— Таңсуны йылғадан барып алам көн тыумас борон[1]. Қышқыда қодоқтан[2] барып алаң, қодоқ тишәсез қый:

---

[1] көн тыумас борон — кояш чыкканчы
[2] қодоқ — бәке

«Таңсыубикә, мин таң сыwына килдем.
Таң сыwы бир мийа.
Им булсын, шифа булсын», —

дип алаң да сыу белән қот қойам, шул қот сыwы белән йыwындырам — *к.-уф.*

### Сылубикә, Сыусолтан

«Сыу анасы Сылубикә,
Сыу атасы Сыусолтан,
Бу сыуны ыриза булып бирегез,
Мин моны даруга алам» — *нокр.*

## ТОТУ

Тоту сүзенең җирле сөйләшләрдә мифология һәм ырымнар белән бәйле рәвештә «изгеләрне зурламаганда», яки берәр ярамаган эш эшләгәндә явыз рухлар (җен-пәриләр) кагылу, чиргә сабышу мәгънәләрен белдергән очраклары күп.

### Тотом, тотом аwыртуы

**Тотом, тотом аwыртуы** *глз.* нәрсә дә булса «кагылу»: җен, пәри, су иясе һ.б.

— Балыклашма[1] барганда йар буйында моно тота, су ийәсе тота. Тотом аwыртуы бар бит ул — *глз.*

### Йыгылган җирдә тота

— Ка ки булса йыгыласин, тота дип әйтәләр. Тотса баш арткылый ыргытасы була кадаклар, себеркеләр, күмерләр. Алай салгаладылар — *глз.*

### Тотканны бәхилләтү

Куймак пешергән дә капка баганасы төбенә чыгарып салган. «Кем тоткан, шул бәхилләсен», — диләр — *т.я.-крш.*

[1] балыклашма — балык тотарга

## Су тоту

**Су тоту** *к.-уф.:*

— Битеңне йыусаң да чәчеңне йолқып сал, йә күлмәгеңнең җебен сал. Ату сыу тота тиделәр.

Мине тотма, шушыны тот,
Шушыны аша, шушыны эч,
Шушының белә ғомер ит, —

дип салыға қушалар.

— Су тотса үзе буйы тегәрҗепне өзеп алып, шал җепне суга агызган.

«Су ийәсе бәхилләсен».

— Су кизләү башы[1] бик тота диләр. Җатып су эчәсен бит кырда эшләгәндә. Үләм[2] утап салабыз, кийеменнән җеп алып сала.

«Мин эчмәгән,
Аша Батман карчык эчкән», — дип.

— Бала су қойона, су тота диләр, бөтен тәне қабарып чыға, бетчәли. Бер чүперәккә күмер сала да, телсез кеше кебек эндәшми, менгәндә дә, төшкәндә дә сөйләшми, артқа әйләнеп қарамый, су қырыйына сала.

Синнән саулық, миннән җаулық,
Киртә тоттым, қазық қақтым,
Әрләнсен, хурлансын,
Име-томы шул булсын — *бәр.*

## Су тию, судан кагылу

**Су тийү** *т.кам.-крш.:*

— Су тигәнгә тоз-җарма салабыз. Түлке су аға торған ыңғайға салырға кирәк. Су тисә, кешене қутыр баса.

— Су ул бик тийүчән була. Шишмәдән су алғанда җәшел җапрақ өзеп салырға кирәк.

«Җәшел җапрақ шикелле җәшәреп утыр», — дип.

[1] су кизләү башы — чишмә башы
[2] үләм — үлән

**Судан қағылу** *перм.:*

— Мине тотып басмақ[1] баштан ырғыттылар сыуға. Ақырып килеп сықтым қурқып. Өйгә қайтып кергәнсе айақлар-қуллар тыңламый башлады. Сыудан қағылған сийа дип үрәтеп қайтарды бер әбей.

**Суwык тоту** *т.я.-крш.:*

— Мине унбер ай суwык тотты. Әни сорый: «Кызым, син судан курыкмаганмы?» — ди. «И әни, тирмән артында мин баттым иде», — дийәм. Әни торды да җарма алды, он алды, җоморка пешерде, икмәк алды да чыкты тирмән артына. Шунда түгеп кайтты. Иртәгесен бетте дә китте.

### Җир тоту, җирдән тийену

**Җир тоту, җирдән тийену** *к.-уф.* җирдән зәхмәт кагылу.

— Бала аwыртына, саташа җирдән тийенсә. Доға өшкереп бирәләр.

Җир анасы җир булыр,
Сыу анасы сыу булыр.
Мине ашама, мине эчмә,
Мийән бүләк — йаулык,
Сийән бүләк — саулык,
Шушыны аша, шушыны эч , —

дип бер чеперәген илтеп күмәләр.

## ЕГЫЛГАНДА ИМЛӘҮ

### Бала йыгылса имләү

**Бала йыгылса имләү** *глз.:*

— Бала агачка[2] йогона, аwыртма йабыша.

Су газизләре, җир газизләре,
Миндән өмет итүчеләр,
Менә бу ипине ашасыннар,
Суwымны эчсеннәр, —

дип йыгылган йиреңә күмәсең.

---

[1] басмақ — басма

[2] йогона — сөртенә

— Койаш байыгач йыгылса малай, зәхмәт тимәгәйе дип қурқалар.

Җиде җул чатына, кеше күп җөри торган җиргә алып чығалар. Көндез түгел, қойаш байығач чығалар да күлмәк изүеннән җиргә көл түгәләр.

«Қайдан килдең — шунда кит» — *минз.*

— Бала чат-чоқырларда җығылса, имгәнсә, үзе буйлый җеп, җә тотмаған қадақ ташлыйлар. Җармасын, қолмағын шанда барып очырығыз», — диләр.

«Қыйын-азап бирмәгез, менә ташлыйбыз сезгә», — дигәннәр — *т.кам.-крш.*

— Майлы су әтәләр иде. Йыгылган төшкә салалар. Алалар май, колмак, суга салалар йарма, виннек йапырагы. Йыгылган төшен йывындыралар да баш ычына әләндерәләр дә түгәләр эч кат:

«Кайан килдең — ары кит,
бирдән килсәң — бире кит».

Баш аша әләндерәләр. Бусагага берәр тамчы тамыза китә.

«Имең-томың шул булсын» — *тмн.*

## Очықлау

**Очықлау** *әстр.* егылган чакта имләү.

— Бала йығылса — җир алып очықлый. Җир кендеге дип әйтеп тоз суы сала.

Име-йомы шул булсын.
Җил белән килсәң — җилеп кит,
Очық белән килсәң — очып кит, —

дип пычақ очы белән тоз сала. Көн сәте чәршәмбе диләр, чәршәмбе көнне очықлыйлар.

— Очықлау дип өстендәге күлмәкләрен талаға чығарып ташлыйлар, таwық белән әйләндереп ташлыйлар иде. Таwықны бер йәтим кешегә бирәләр — *әстр.*

## Чалпу

Чалпу *каз.ар.-дөб.* егылган җиргә имләп ташлана торган әйбер.

— Чалпу йыгылған җиреңә кирәг ул. Мин Ағыйделгә суға салырға қуштым. Бер сүз әйтмисен, кеше белән сөйләшмисен, салып әйләнеп кергәнче сөйләшергә қушмыйлар — *каз.ар.-дөб.*

## Чалпу догасы

**Чалпу догасы** *каз.ар.-дөб., бәр.* әйбер имләп ташлаганда укыла торган дога.

— Чалпу доғасын бер өс кисәк йазып, туғыз пәри исеменә йазыла: а, гу, ка, ха, хү, сэр, шәр, хә, мә — *каз.ар.-дөб.*

— Җыгылган җиргә чалпу доғасы уқып, тотылмаған җанға қадақны төллә сәғәт уникедә күмәргә — *бәр.*

## Чалпу қурчағы

**Чалпу қурчағы** *каз.ар.-дөб.* егылган җиргә имләп ташлана торган курчак.

— Чалпу курчагы дип әйтәләр имләп салғанны, чалпу қурчағы булмаса йығылган җиреңә қадақ қағарга кирәк. Аwыртқан җиреннән артқа төшерергә қушалар солы бөртеге, сул җилкә аша төшерергә қушалар — *каз.ар.-дөб.*

— Қурчақны имләп ташлыйлар, аwыртқан җире бетмәсә, имли дә ырғыта.

— Сызлаwықлар, чуаллар чыға ис, шул wахытта қурчағ имләп ташлыйбыз, менә сиңа бүләк дип. Чалпуға қадақ та қағарға қушалар, сырхау тиз бетә, ди.

— Җығылған урынға балчықтан кеше җасап күмә, чоқор қазып, чалпу сала — *бәр.*

## Чалпу салу

**Чалпу салу** *каз.ар.-дөб.* егылып берәр җире авыртса, ул урынга әйбер имләп ташлау.

— Чалпулар салабыз бала авырса. Нәни балтаны муйынға асылындырып барадырыйым барған wахытта. Қайтқан wахытта да муйынға асылындырып қайтадырыйым. «Мине тотма, шушны тот» — дип сул йақ иңбашыннан ырғытып қайтадырыйым. Хайван чалған төшкә дә чалпу саладырыйым.

— Җығылалар, җығылғастын аңа чалпу салырға кирәк үзеңнең җығылған җиреңә. Өс бөртек солы сәстем, бер семе-

тем тоз сиптем. Чалпуға кеше басмасын, басса үзе сырхауға әйләнә.

— Чатқа әйбер ташлый. Чат узған чақта җиде җулның чатына ырғыталар, анғар да җасап қуйалар.

— Чалпуны барып җиткәс саласың да җәшми-тынми гына қайтасың боролопи. Ул җақтан қайтырга қушмый торғаныйы әнкәй. «Барған җақтан қайтма, бу җақтан қайт», — ди торғаныйы.

### Чалпулы җир

**Чалпулы җир** *каз.ар.-дөб.* әйберләр имләп ташлаган җир.

— Чалпулы җирләрдән узғанда қарап узығыз, чалпуға бассаң айақ сызлаучан була дип әйтерләр ийе әwәле әбиләр.

### Чарпу салу

**Чарпу салу** *каз.ар.-дөб., әстр.* к. **чалпу салу.**

— Кич қойаш байығач, *койаш чығышына таба қарап чарпу саласың, тоз, җарма, қадақ. И ходайым, бир саулығымны, дип. Артыңа әйләнеп қарамасқа, җиргә тибәргә өч тапкыр.

— Берәү чарпына, шикләнә. Су түккән урынға басса чарпына. Анарға чарпу ташлыйлар. Өстендәге бер қат кийемен шиштерәләр. Таwық суйалар да, таwық қанына буйап кийемнәрен алып китәләр эстипкә, алып китеп бер йамкаға ташлыйлар. Анда ат әйдәүче утыра да чарпу ташлаучы әби утыра. Сүләшергә қушмый әкитеп ташлағанчық, өйгә қайтқанчық. Таwықны бер әбигә бирәләр — *әстр.*

## МӨШКӘШ, МЫЖЫ, НЕЖЕ

### Мөшкәш

**Мөшкәш** *каз.ар.-лш.* эч авыртуы.

— Мөшкәш булса балаға менә болай уқып өшкерә:

Ақ тарыны суырдым,
Кибәгеннән айырдым.
Мөшкәш белән бүсерне
Сабағыннан айырдым.

## Мыжы

**Мыжы** *т.я.-трх.:*

— Мыжыны беләм. Малай җыйырылып-җыйырылып җылый. Мыжы булған, диләр. Ипи көрәгенә қуйа да күмә җанына қуйып ала, мыжы булған, дип. Дүшәмбе, кече атна, атна көнне эшли.

## Неже, неже куыру

**Неже, неже куыру** *мәл., кузн., баст., влгг.:*

— Әпәйләрне алгач ыланны пичкә ата керәккә бәләп, кан'ар пич тегел ул, узган пич. Бер кеше тирәздә йери. «Әби, ни куырасын?» — «Неже куырам, балам». Эч кат сыри. Неже бетә. Әпәй салган кенне куыра, чәршәмбе кенне — *мәл.*

— Олан туа, үсә алми. Нежеле имеш. Пичкә йагалар, әпәй йапкан пич, әпәйне пешереп алалар. Йылы гына пичкә агач керәккә оланны чормап утырта, өч тапкыр тыгып ала. Әбийем шылай эшли булган.

«Кайан килдең,
Ары кит».

— Тәннәренә неже чыга. Агач көрәккә чорнап йылы пичкә тыгалар оланны, сүнгән йылы пичкә. Өч кат сорап торалар йантыктан.

«Ни ковырасың»
«Неже ковырам», — әтә — *влгг.*

— Бала айакларын сузми, тартып чорнисын, ич йук. Ул катын мачы-кочокны тибә йөргән авырлы вакытта. Ыланны пичкә тыгалар, берәү кычкыра тәрәзәдән: «Апа, ни кывырасың? — «Ныжы кывырам». Эч кат әтерге кирәк. Баланы пичкә тыга да чыгара инде — *кузн.*

— Ыланым ныжылы ди, чәршәмбе кенгә квашн'а куйарга кирәк, ди. Ныжылы ылан айакларын тарта апаруга. Элек әпәй пешерәләр ийе, әпәй пиченә, кан'ар пичкә тегел, пичнең жары беткәч ыланны әпәй керәгенә бәли дә пичкә тыга. «Ни кывырасың?» — «Ныжы кывырам». Тыга да чыгара эч кат, чәршәмбе кенне — *кузн.*

— Ныжылы бала була. Агац керәккә бәләп, пицкә тыгалар баланы. — «Ни курасын?» — «Ныжы курам». И шуның белән

бетә. Менә әпәйләр салалар иде выт', әпәйләрне алалар, әпәйләр цыккац керәккә бәлиләр дә оланны пицкә тыгып алалар иде. Шуннан уңайлы була иде — *срг.*

— Йомшаклар чыккач, көрәккә ыланны бәлиләр дә өч тапкыр «Ни ковырасың?» — дип сорыйлар. «Ныжы ковырам» — ди. Ныжыдан кәҗә тәкәсенә дә атландыралар — *хвл.*

— Ныжы булса балага заслун[1] белән баса идек. Шунардан тиз китә иде, чәнчү бетә иде.

Ай кайта, көн кайта
Син дә кайт, ди,
Име-томы шул булсын, ди.

Әни заслун белән баса, ә кайберләре агач кашыкнын тумары[2] белән баса иде — *баст.*

## Осан, очан имләү

**Осан, очан имләү** *каз.ар., минз., крш.:*

— Җылақ балаларға осан тиз була, эсе аwырта. Наскиның олтораға белән имнисең осан булған дип. Қазан мусаласы, мендәр қыры посмағы, җурған посмағы, уқлаулар, ипи қалақлары белән имнисең инде. Исме белән әйтәләр. Сорыйсың, «нәрсә имнисең?»

— Менә фәлән кешегә осан булған, осан имним, диләр. Менә кирегә әйтеп имнәргә кирәк:

Берәү-икәү ... туғыз — туфраққа,
Җиде — җилкенеп җөргән қызларға,
Биш — бишесе биш қалаға, бишесе биш салаға.
Өс — оссон, бетсен, китсен җилгә, қузға[3], дисен,
Бер — бетеп китсен.
Минем кулым түгел, әйшә-патман[4] қулы, —

диләр — *каз.ар.-дөб.*

— Бала җылый, осан булғандыр дип мәсе қойрықлары белән, уқлаулар белән имли торғалларыйы баланы сузып салып.

---

[1] заслун (рус. заслон)— пич капкачы
[2] агач кашыкның тумары — агач кашыкның йомрысы
[3] қуз — ут
[4] әйшә-патман — Гайшә-Фатыйма

Осан булған, қарале ди туғызға қәдәре менеп, туғыздан бергә хәтле саный — *каз.ар.-дөб.*

— Очан дигән чир булдисә Дәрҗә әбейгә керер ийем баламны күтәреп. «Дәрҗә әбей, тағын балам җылый инде, тағын очан булган» дип әйтер ийем. Өшкереп чығарып җибәрер ийе.

Бер, ике-өч ... туғыз — тузып китсен,
Җиде — җилгә кузғалсын,
Биш — бизеп китсен,
Бер — бетеп китсен, ди.
Шуннан бала җоклар ыйы — *т.кам.-крш.*

## Шинә қуыру

**Шинә қуыру** *каз.ар.-дөб.:*

— Бик йылаған балаға шинә була. Баланың айағы көйле булмый, шинәне қуыралар. Қайын тузын җырық бер кисәк итеп имнисең дә шул қайын тузын қуйасың бер табаға. Баланы шул таба турысына қайын тузы парына тотасың, шуның җылысына. Шул тузны алып шуны баланың муйнысына тағасың. «Нәстә имнисең?» «Фәлән балаға шинә булган, шуны имлим», ди. Бала айақланып җөри башлый. Өч мәртәбә қуырырга кирәк, қайын тузын җеп белән муйнына асасың. Чәршәмбе көнгә туры китереп қуырасың.

## Ыҗан суқтыру

**Ыҗан суқтыру** *нокр.:*

— Ыланның эче аwыртa, ыҗаны бар, ыҗанын суқтырып қайтасы баланың, диләр. Баланың қорсағын ача да күмер сала, қара дастымал сала:

Ай қайта, кен қайта,
Йеде алғанда кызың бар,
Йеде алғанда улың бар,
Бетсен, китсен, ди.

## Эч җаны

**Эч җаны** *м.-кар.* эч авыртуы.

— Эч җаны була икән балага, уклау белән баскылилар икән эч җаны булса.

## Эч җанын суқтыру

**Эч җанын суқтыру** *нокр.:*

— Баланың эч җаннарын суғам. Мин эч терле әйбер белән. Қулдастымалы белин, папақ[1] белин, тапычка белин, эч тапқыр суғам мин:

Ай қайта, кен қайта,
Бу да қайтсын.
Мин улымны ашама,
үзеңнекен аша.

Эми кэлен дип чүрәни[2] билән дә өшкерэм. Уқлау башына алам чүрэнине, аның беләп суғасин эч җанны.

Эч җанын орчоқ, қарйақ[3], тотмаған инә беләп суқтыралар белүче қарчықлар — *нокр.*

## КЫЧЫТУ АВЫРУЫН ИМЛӘҮ

### Миңгерәү имләү

**Миңгерәү имләү** *бәр.:*

— Миңгерәү була, қычыта башлый, ул дару итмәсәң дәвәйә, аза башлый.

Әм-әм әмрәмү,
Миң-миң миңрәмү.
Йөзенә қара йақтым,
Ана көчек қурба,
Қайан керсәң, шунда чық.
Ишектән чық, тәрәзәдән чық,
Теллектән чық,
Қайан тишек тапсаң, шуннан чық, —

дип өрәсең.

---

[1] папақ — калфак
[2] чүрәни — үрмәкүч
[3] қарйақ — кайрак

## Тимерәү имләү

**Тимерәү имләү** *нокр.:*

— Баланың тимерәвен күмер белән сызалар, балан белән сызалар, «Әм-әм-әмрәмүн, — тим-тим-тимрәмүн», — дип өшкерә. Аркылы-торкылы сыза тимерәү сәсәген. Име-томы шул булсын, шуны көтеп торган булсын, — дип. Төн йакка күмерен бәрәсе — *нокр.*

— Тимерәү булса кари иде дә безнен әни: «У, балан тимерәве, бик кызыл», — ди, балан сөртергә куша. Акча белән пирәргә[1] кирәк диләр, кемеш акча белән пири иде тимерәүне, кемеш акча җертә иде шулай: «Бетсен, коросын Аннушны тимерәве», — дип эч тапкыр әйтә — *м.-кар.*

## БАЛА ЮТӘЛЛӘГӘНДӘ ЫРЫМНАР

— Йүтәлли дә йүтәлли ылан. Аны берсеннән сырилар, урамда кем очрый. «Күг ыштанлы, күк кийемле бу йүтәлгә ни дару?».

Ул күк күлмәк кигән кеше булсын. Җавапны ни кайтара, шуны эшлисең. Йә күгәрчен каны эчер, йә сир сөте, дийә — *хвл.*

— Пер кеше килеп утырса, ат белән килгән кешегә цыққалы кирәк, сурағалы. Күг атлы кешегә цыққалы кирәк.

Күг ат менгән мәндә,
Күк тун кигән мәндә,
Күк бумага ни дәре[2]?

Ул әйтәде икән — йә сыйырның сөте дәре, йә бер төрле ашамлың — ул дәре, ишмешем пар, сес тә ишмешегес пар булыр — *себ.*

## БАЛА БАШЫН ТОТМАСА

— Ҡуйның муйынын пешерә дә, сөйәкләрен айырминча ашыйлар, элеп куйа төллеккә[3] -*эстр.*

---

[1] пирәү — имләү
[2] дәре — дару
[3] төллек — төнлек

## БАЛАНЫҢ ТӘНЕ БЕТЧӘЛӘСӘ ЫРЫМНАР

**— Қарлығас ойасыннан** балсығ алып шуны зиз иләктән зиде тапқыр иләп өшкерә. Шуны өшкереп, майға изеп, шуны сөртә бите бетсәләсә — *каз.ар.-доб.*

— Челгиләр[1] чыга, гыбасына[2] да челгиләр чыккан иде. Аш мунчаласын ала иде дә шул челгиләрне бәли иде, челгиләр бетә иде — *мәл.*

— Чыбан[3] чыкса, зуррак булса, куш кийарлар белән имләгәннәр, шунда беткән — *мәл.*

## КЫЗАМЫК АВЫРУЫННАН ЫРЫМНАР

— Кызамык чәчәк чыгарса, шул вакытта ат'алар, исән-сау терелсәм, кызыл күлмәк йасап биремен, ди, кызыл әтәч сунармын, ди -*мәл.*

— Кызамык өч көн чыга, өч көн тора, өч көн бетә. Агач табакта гына йывындырам, тимер таз йарами кызамыкка. Бер ун көнгә тартыла — *влгг.*

— Кызамык каста булгалады. Кызамыкны каршы аласы козол әйбер белән, читсамы козол, йаулыкмы козол. Заткан чакта йарма белэн затасы, име-йомы кэтсен, чәчелсен дип. Йарманы кемгә бирәсе, бабачка[4] чыгардым, алмай, бикэчем алды чәй табак белән дә убратны үземэ бирде — *нокр.*

— Кызамыкны йобаталар[5], кызамык анасы була диләр. Тәбиски[6] кашык салалар, кечти ипей йасайлар, ул ипейне салалар, кем йобата, анар була — *нокр.*

— Кайван суйма да, талашма да йарамай кызамыкны йобатканда — *нокр.*

---

[1] челги — бетчә
[2] гыба [рус. губа] — ирен
[3] чыбан — чуан
[4] бабач — бабай, карт
[5] йобату — имнәү
[6] тәбис — савыт

**Қызамық фере** *бәр.* кызамык авыруы.

— Қызамық фере диләр қызамық белән аwырса, үзе буйы қызыл җеп бирәләр ийе.

### САРЫ АВЫРУЫН ИМЛӘҮ

— Сары булса куркыталар. «Мәсә қый минең сары йаулығымны урлап қуйдың», — дим. Ул йылый, йуқ ти, урламадым, ди. Қурқытып әйттем, ул аны белми. Төзәлде қый — *перм.*

— Сарылама (сары) авыруына чәршәмбе көн салған йомырқаның сарысын ашатырға кирәк, сары мәтерүшкә кирәк, чәршәмбе көн сауған сөтнең қатығын ашатырға кирәк — *каз.ар.-дөб.*

### ЗӘҢГЕЛӘ ИМЛӘҮ

**Дәңгелә қачыру** *минз.* яз көне ашарга яраклы үләннәр чыккач, үлән ашаганда әйтелә торган ырым сүзләре.

— Беренче җуа, икенче қуdғалақ, ачы қақы, төче қақы, қымыdлық чыға. Шуларны беренче кабасын да «дәңгелә қач, дәңгелә қач, иске қорсақ, йаңа аш», — дип, иһаһа дин кешнәп қуйасың. Болар дәңгелә қачыру була инде, эчеңдәге чүп-чар чирләреңне себерә дә ырғыта инде.

## БАЛА ТУУ ЙОЛАЛАРЫНА КАРАГАН СҮЗЛӘРНЕҢ ИНДЕКСЫ


аба 102
 икөн аба 93, 107
 кендек абасы 161
абам 64
абдаллату 147
абдаллатырга 147
абдаллауцы 147
абдаллатуцы 147
абдалцы 147
 абдалцы бабай 147
абзый 190
аwызландыру 75
 бабай аwызландыру 77
 бал-май белән аwызландыру 75, 76
 бал белән аwызландыру 75
 бәбәй аwызландыру 75
 май белән аwызландыру 75
аwызлыкландыру 76
аwыр
 буй аwыр 13
 буй аwыр киленчәк 41
аwырайак 13
аwырайаклы 14
 аwырайаклы бицәләр 36
аwырлы 13
аwырту
 тотом аwыртуы 238
аға
